Фәрит Суфияров

# Хисләр ташкыны





Фәрит Суфияров

# Хисләр ташкыны



*ШИГЫРЬЛӘР, ҖЫРЛАР*

Зәйнәб Биишева исемендәге "КИТАП" нәшрияты

УФА · 2009

УДК 821.512.145-1
ББК 84-5 (2 Рос=Тат)
С 88

**Суфияров Ф. С.**
С 88 Хисләр ташкыны: шигырьләр, җырлар. – Уфа: Китап, 2009. — 216 бит.

ISBN 978-5-295-04743-5

Фәрит Суфияровның юбилей уңае белән нәшерләнгән әлеге җыентыгының геройлары — туган ягын, Ватанын сөйгән, җир эшен, игенче һөнәрен үз иткән гади кешеләр. Хезмәт, намус, гаделлек төшенчәләре, яшәү мәгънәсе хакында фәлсәфи уйланулар, күңел матурлыгын данлау авторның иҗатының асылын билгели, шигырьләре укучыны искиткеч табигыйлеге, ихласлыгы белән җәлеп итә.

**УДК 821.512.145-1**
**ТП – 189/09**
**ББК 84-5 (2 Рос=Тат)**
**ISBN 978-5-295-04743-5**
© Суфияров Ф. С., 2009

## АВТОР ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘ

Фәрит Суфияр улы Суфияров Яңавыл районының Исәнбай авылында туып үскән. Урта мәктәпне тәмамлагач, Уфа финанс техникумында белем ала. Төрле оешмаларда финансист-икътисадчы булып эшли.

Педагогия институтын тәмамлап, район гәзитендә әдәби хезмәткәр, мәктәптә директор вазыйфаларын башкара.

1970 елдан Башкортстанның төньяк-көнбатышындагы яшь һәм башлап язучыларны туплаган «Замандаш» әдәби берләшмәсен җитәкли. Хәзерге көндә — Яңавыл язучылар оешмасының җаваплы секретаре.

Шигырьләре вакытлы матбугатта, коллектив җыентыкларда дөнья күрә. Радио-телевидениедә аның сүзләренә язылган җырларны популяр җырчылар башкара.

Авторның иҗаты хакында аның якташы, шагыйрь, Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Рәдиф Тимершин менә нәрсәләр яза: «...Фәрит

Суфияровның шигъри әсәрләре табигатьнең үзе кебек кырыс та, мәрхәмәтле дә. Әйткәндәй, аның байтак шигырьләренең җирлеге, үзәге — табигать күренешләре, табигать тудырган хикмәтләр. Әмма шагыйрьнең максаты — һәркемгә дә таныш күренешләрне шигъри юлга салып тасвирлау гына түгел: я бу күренешләр — аның тойгыларын, рухи халәтен, булмышын ачыклаучы чара, я әдип теге яки бу табигать күренешен тасвирлап, үзенчә, башкалар әйтмәгән фикер бәян итә.

Үзе дә олы тормыш мәктәбе үткән Фәрит Суфияровның лирик геройлары — җир эшен, игенче һөнәрен үз иткән табигать балалары, хезмәт, намус, гаделлек төшенчәләре, яшәү яме һәм күңел матурлыгына мәдхия — Фәрит Суфияров иҗатының асылын билгели».

Республикабыз әдәбиятын һәм сәнгатен үстерүдә күрсәткән хезмәтләре өчен шагыйрь Фәрит Суфияров Башкортстан Республикасының Мактау грамотасына лаек булды, аңа «Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде. Ул — Гали Чокрый, Фатыйх Кәрим исемендәге премияләр лауреаты.



# ШИГЫРЬЛӘР

*Мин тормышны матурларга тудым,*
*Җавап тотам барсы өчен дә.*
*Вакыт чикле, өлгерергә кирәк*
*Кыска гына гомер эчендә.*

## Үз җиремдә

Адашырлык карурманнар да юк,
Пар аккошлар йөзгән күлләр дә.
Туган җиргә чиксез мәхәббәтем,
Төшермәдем кара күләгә.

Болыннарың гөл бакчасы кебек,
Кырларыңда иген өлгерә.
Суың эчәм, икмәгеңне ашыйм,
Газиз җирем, син бит бергенәм.

Үз төягем, сатып алмадым ла,
Бар булганың белән килештем.
Туган җиргә һәрчак рәхмәтлемен,
Шөкер, диярга дә тиешмен.

Гомерлеккә кордым йорт нигезен,
Тормыш учагымны дөрләттем.
Синдә яулыйм хезмәт уңышларын,
Хөр яшәргә мине өйрәттең.

Үз җиремдә ята тамырларым,
Кояшым да монда, аем да.
Ата-бабаларым гомер иткән,
Каберендә үскән каен да...

## Зарланмыйча яшик

Зарланмыйча гына яшик әле,
Тормыш хәлләре дә көйләнә.
Чайкала да, тирбәлеп тә куя
Күл өстендә йөзгән көймә дә.

Бабайларга әллә җиңел булган,
Авыр йөкне тарткан, төрлесен.
Сугышны да, ачлыгын да күргән,
Тунаганнар бер кат тиресен.

Пошынырга урын юк та сыман,
Илләр тату әле, иминлек.
Өстәлләрдә торган сый-хөрмәткә
Күз карашы төште иң элек.

Күңелебез һич тә шомланмасын,
Гаделлекне кем дә ачыклар.
Җир тетрәп, сулар басмады ич,
Язмыш бүләгедер бу чаклар.

Үз дөньяма бик тә канәгатьмен,
Афәтләрдән яшик сакланып.
Кылган эшләребез мактанырлык,
Бөтен галәм торсын сокланып.

## Кешеләргә булсын кирәгем

Борчуларым бетеп торганы юк,
Олы өмет белән яшимен.
Ходай белер, әгәр гөнаһ кылсам,
Кешеләрдән һич тә яшермим.

Урлашмадым, кеше таламадым,
Тапканнарым — хезмәт җимешем.
Шаһит булсын кулга йөкләп алган,
Илгә багышланган бар эшем.

Тәүбә итәм, кыңгыр эштән куркам,
Мин йөземә кара якмадым.
Кимсетелә кеше хаксызлыктан,
Авыр хәлгә тарыгач, якладым.

Изге теләктәмен, дога кылам,
Җиргә орыла башым, маңгаем.
Битарафлык инде күрсәт дисәм,
Каһәр укыр халкым, мөгаен.

Намусымны саклыйм тап төшерми,
Хезмәт бары яшәү терәгем.
Мин башымны горур йөретермен,
Кешеләргә булса кирәгем.

## *Дөнья ямен җибәрмик*

Бездән дөнья ямьле калсын әле,
Йортлар төзик, иген үстерик.
Килер буын, яшьләр рәнҗемәсен,
Тормыш күркәм, хәстәрен күрик.

Җир-анабыз, җәннәт бакчасы күк,
Асыл гөлләр белән бизәлсен.
Кылган эшләребез үрнәк булсын,
Ай, йолдызлар күктән күзләсен.

Кәүсәр чишмәләрнең күзен ачыйк,
Дәва тапсын сусаган җаннар.

Исән чакта сүнмәс хезмәт дәрте,
Куәтләнеп йөрәкләр янар.

Без яшәгән еллар, шаһит булып,
Басар берчак тарих каршына.
Гадел хөкем чыгар, бәһаләнер,
Җавап тотарбыз ич барсына.

Корал тотып яу кырына чыкмыйм,
Сәлам бирәм кереп күршемә.
Илем, имин-тынычлыгың кирәк
Хезмәт сөйгән барлык кешегә.

## Хезмәт дәрте бирә

Гөрли-шаулый мотор тавышлары,
Тынып тормый иртә-кичләрен.
Бuразналар сызып, тракторлар
Ярып уза басу өсләрен.

Алны-ялны белми эшли шулай,
Шәфәкъларны ялгап таңнарга.
Көчен биреп, кара тирен түгә,
Игенчене була аңларга.

Кыр эшләре һәрчак ашыктыра,
Заман башка хәзер, дисәк тә.
Аен, көнен, сәгатен дә хәтта
Игенчеләр ала исәпкә.

Авыл халкы кырда гомер буе,
Хәстәрлеген күргән элек тә.
Иген үстерергә максат куеп,
Багланган ул якты өметкә.

Тал бөресе кебек күңел тулып,
Хисләр таша, хыял канатлы.
Игенчегә хезмәт дәрте биреп,
Тургай җырын илгә таратты.

## *Киләчәккә дәшәм*

Киләчәккә барыр ара ерак,
Айлар, еллар тора тезелеп.
Агачлар да язын яфрак яра,
Күзләр җиткәч төшә өзелеп.

Кабатлана шулай ел фасылы,
Җилләр исә, сулар түгелә.
Дөнья фанилыгы уйландырып,
Бер гамь салып тора күңелгә.

Киләчәккә барам еллар аша,
Чакырып тора озын юлларым.
Олы бәхет, миңа гомер теләп,
Төш күрсәм дә, әни, юрадың.

Күңелемне моң чорнаган чакта
Күз карашым төшә гөлләргә.
Мин эндәшәм матур киләчәккә,
Таныш түгел, белмим кемнәргә.

Туктатып та, тизләтеп тә булмый
Йөгереп узган еллар агышын.
Мин җыр итеп язам киләчәккә
Йөрәктәге сагыну сагышын.

## Кузен ача тәрәзәләр

Күзен ача көнгә тәрәзәләр,
Челтәр-пәрдәләрем тартыла.
Кояш үрләп күк өстенә менә,
Күтәрелә соңгы катына.

Тәрәзәгә төшә нур балкышы,
Аккан су күк тоташ агыла.
Анам кулы сыман җылы тоям,
Кайнар сулыш җанга кагыла.

Көндез кояш, төндә ай-йолдызлар
Тәрәзәмә төшеп чагыла.
Болыт басса күкне, шомга калам,
Күреп яшим төрле чагын да.

Таң яктысы, шәфәкъ балкышы да
Үз бизәген саклый, үз төсен.
Тәрәзәдә яңгыр, кар бөртеге
Миңа чиртәме иртә-кичен.

Тәрәзәмнән күрәм бар дөньяны,
Айның, көннең һәрбер мизгелен.
Бар көчемә тотам ике куллап,
Ычкындырмый вакыт тезгенен.

## Җырларым

Җырларымда — бөтен шатлыкларым,
Җырларымда — күңел сагышым.
Тормыш юлларына аяк баскач,
Сискәндерә гомер агышым.

Заман гүләүләре колагымда,
Йөрәгемдә җыр-моң ярала.
Сызланганда җаным дәва тапсын,
Һәм сихәте тисен ярама.

Бар булышым җырларымда чагыла,
Шагыйрь өчен шулай тиештер.
Күкләремә күтәр канат куеп,
Бөркетләргә мине тиңләштер.

Сәфәр чыксам, җырларымны барлыйм,
Юлдаш итәм, илләр гизәмен.
Шигем бетә, юанычлар табам,
Сихри көче барын сизәмен.

Җырларымда — яшьлек хатирәсе,
Ялгышларым, керсез яшьләрем.
Гомер буе турылыклы булып,
Җырлар белән бергә яшәрмен.

## Ышанасы килә

Ышанасы килә могҗизага:
Гамьсез җаннар кайтыр иманга.
Күк читендә елмайган таң кебек,
Өмет яши, күңел инана.

Кыш юрганын ябар кыр өстенә,
Ышандыра шуңа ничек тә.
Быел игеннәрем уңар әле,
Теләгемне Ходай ишетә.

Адашканнар үз сукмагын табар,
Егылганнар басар аякка.

Бөлгенлеккә, мескенлеккә төшмик,
Юк, калмасын кеше оятка.

Үз парларын табар ялгызаклар,
Оя корыр бәхет кошлары.
Йөргән юлларыннан уңып кайтсын,
Нужа күрми адәм башлары.

Ышанасы килә кешеләргә,
Игелекле булыр эшләре.
Тормыш учаклары нур балкытсын,
Сый-хөрмәтле торсын өстәле.

## *Каршы барам искән җилләргә*

Агымсуга карап үрләдем гел,
Каршы барам искән җилләргә.
Ачу килә, тал чыбыгы кебек,
Башын игән мескен ирләргә.

Барган җирдә киртә очраса да,
Читләп аны урап үтмәдем.
Зарланмадым мохтаҗлыкны күреп,
Шәфкать беткән, ярдәм көтмәдем.

Тормыш кырларында адаштым да,
Зиһеннәрем баштан таралды.
Үз юлымны барыбер эзләп таптым,
Күз алларым булсын томанлы.

Ихтыяр да, көч тә җитәр, димим,
Мин чамасын аның белсәм дә.
Юлга чыксам, кире борылмадым,
Яшен уйнап, давыл килсә дә.

## Язмыш сынавы

Утлар булып дөрләп янам,
Сулар булып түгеләм.
Мин тормышта яраланып,
Тагын үзем тереләм.

Ташкан сулар кебек шаулы,
Болганчык заманасы.
Мескен хәлендә түгелмен,
Һич килми зарланасы.

Яшәгәндә мохтаҗлыклар
Адым саен кисәтә.
Бу дөньяга кунак булып,
Азга гына килсәк тә.

Язмышлар якадан алып,
Башымны җиргә ора.
Өзгәләнәм, сызланамын,
Гомерләр үтә тора.

Баш өстендә күк күкри,
Камчылый яшеннәрең.
Сабырлыгымны җыеп, мин
Күз яшен яшерәмен.

## Йөрәк серен саклый

Оядагы кош баласы сыман,
Бик кечкенә йөрәк талпына.
Өзгәләнә, бәргәләнә үзе,
Тынгы белми яшәү хакына.

Ярты дөнья сыйган йөрәгемә,
Җиккән атлар тора мичәүдә.
Диңгезләр дә, биек таулар да бар,
Барысын да салам үлчәүгә.

Туар таңнар йоклый тыныч кына,
Килер язның шаулый бөресе.
Сагышлар да, өметләр дә — миндә,
Үз урынын алган һәрберсе.

Яшерен ул хәзинәләр сыман,
Гомер буе саклый серләрне.
Киләчәккә якты факел булып,
Яшьлек дәрте кала, сүнмәде.

Бер карасаң, коштай талпынасың,
Бер карасаң, йөрәк, янасың.
Сызлансаң да, күпме сугылсаң да,
Күрсәтмисең, беләм, ярасын.

## Башкортстан җире

Башкортстан, юмарт туфрагында
Асыл гөл күк үскән баланмын.
Язмышыма рәхмәтләрем укыйм,
Туган төягемдә каламын.

Ак биләүгә төрелеп ятканда ук,
Курай моңы җанны җылытты.
Маяк булып тормыш юлларымда,
Азат-хөр рухлы, җырлы итте.

Кымыз эчтем шифа-тәмен татып,
Көчем артты, дәртем ташыды.

Уралтауның бер шоңкары булып
Колачладым кыя-ташыңны.

Башкортстан — хәзинәләр иле,
Өстәлем мул, пешкән икмәгем.
Нигъмәтең күп, күзләр кызарлык бит,
Күрәм хөрмәтнең зур икәнен.

Мәхәббәтем арта айлап-көнләп,
Хезмәт сөйгән минем халкым бар.
Җәннәт почмагына тиңләштерәм,
Башкорт җирен данлыйм — хакым бар.

## Дөньяда кунак кына

Мин кунакка килдем, дөнья, сиңа,
Мәңгелеккә түгел, бик азга.
Көнем якты, моңа рәхмәтлемен,
Хушлансын җан, сусаган назга.

Хыялларым чынга ашса икән,
Өметләрем бары аклансын.
Кара болыт булып кайгы-хәсрәт,
Күңел күкләремне япмасын.

Игелеген күрим җир-суымның,
Өстәлемдә торсын икмәгем.
Үкендермәс, уфтандырмас бер дә
Киләчәгем минем, үткәнем.

Еллар имин генә булсын, димен,
Илһам бирсен иҗат җимешем.
Бәхет-шатлыгымны юллап алам,
Гамьсез булмаска да тиешмен.

Мин тормышны матурларга тудым,
Җавап тотам барсы өчен дә.
Вакыт чикле, өлгерергә кирәк
Кыска гына гомер эчендә.

## Мин – хыялый кеше

Малай чакта мине гашыйк итте
Биек таулар, күксел кыялар.
Ашкындыра, җилкендерә һәрчак
Ташкан хисләр, татлы хыяллар.

Күзем кыза ерак галәмдәге
Йолдызларның тоныкутына.
Серле төсле җиһан киңлекләре,
Биеклеккә күңел тартыла.

Ай-кояшка арам якынаер,
Очып менсәм зәңгәр күкләргә.
Максатыма ирешергә телим,
Күпме вакыт кирәк көтәргә?

Һаваларда очкан чакта кошлар,
Талпынасым килә, очасым.
Килә йолдызларга юл саласым,
Галәм капкаларын ачасым.

Старт алган ракетадай булып,
Орбитага бер мәл атылам.
Мин – хыялый кеше, өметләнеп,
Кулым җитмәс эшкә тотынам.

## Дөнья чикләре

Күп илләрдә, күп җирләрдә булдым,
Аяк бастым диңгез читенә.
Бәхәсләшмим, дөнья чиксез, диеп,
Телдә генә юкка әйтелә.

Дәрья сулары да чиксез түгел,
Дулкын, башың ярга саласың.
Җиһан кораблары очып үтте
Йолдыз белән йолдыз арасын.

Күк читенә җитеп кояш байый,
Җир күчәре буйлап урады.
Вакыт әмере үлчәүләргә сала,
Сәгать теле белән санады.

Күккә ашып торган биек таулар,
Диңгез тирәнлеге үлчәнә.
Билгеләнә галәм киңлекләре,
Кеше кулы белән эшләнә.

Элек кенә олы сер ителгән,
Вакыт җиткәч ача бикләрен.
Бөтен дөнья үлчәүләргә сыя,
Хыял гына белми чикләрен.

## Илем-көнем калсын имин

Ут йөгертеп, яшен яшьнәтмик лә,
Илем-көнем калсын бер килеш.
Хәстәрлеген күрик алдан белеп,
Җаваплылык булырга тиеш.

Гамьсезлектән, саксызлыктан бары
Сызланыла, кеше җәфа чигә.
Үз ватанын, үз халкын читсенә,
Ата-анасын да куймый сүгә.

Бозмый яшәү тормыш кануннарын
Һәркемнең дә килми кулыннан.
Явызлык та, хөсетлек тә бердәй,
Табып була кеше канынннан.

Бу дөньяга кунак булып килдек,
Мәнсезлектәнме соң отылдык?
Тау күчереп, айга менеп була,
Ник күсәккә әле тотындык?

Һәрвакытта изге гамәл кылып,
Үкенмәслек гомер кичерик.
Мохтаҗ булса кеше — икмәк бирик,
Сусаганда сулар эчерик.

## *Җирем сабыр*

Учларыма алам җирдән туфрак,
Күп яшәгән, күпне күргәндер.
Карлар-бозлар яуган күкрәгенә,
Ачы җилләр аңа өргәндер.

Яңгыр булып яуган метеорлар,
Ут уйната яшен ташлары.
Ак кәфенен сөйрәп йөри төсле,
Афәт яный салкын кышлары.

Җирнең сабырлыгын, түземлеген
Нинди тирәнлектән үлчәргә?

Гөлләр шиңсә, урманнарың корса,
Су да табалмассың эчәргә.

Бетмәс назың, ямең, хәзинәң бар,
Хәвефләрдән, җирем, саклан син.
Галәм түрләреннән күреп торсын,
Ай-йолдызлар сиңа соклансын.

Игелекле җирем — анам кебек,
Сөеп ача иркен кочагын.
Мин куанып яшим гомер буе,
Сүндермичә тормыш учагын.

## Сораулар көтә җавабын

Таулар нигә чүгә икән,
Чишмә сулары корый?
Йөрәгем тынгысызлана,
Төгәл җавабын сорый.

Төн җитсә, нигә йолдызлар
Күк өстендә атыла?
Офыкларда яшен чатнап,
Җирне тота утына?

Урманнар нигә шаулый соң,
Шәфәкъләр алсулана?
Табигать серен ачыклыйм,
Төшенмим асылына.

Җил-давыллар нигә куба,
Дөньяның яме китә?
Яңа көн туса, ышанып,
Кеше иминлек көтә.

Сораулар көтә җавабын,
Тезелгәннәр чиратка.
Тормышның бөтен хәстәре
Йөкләтелә ир-атка.

## Офык аша уза юлларым

Күкне җиргә тоташтыра киңлек,
Еракларда зәңгәр сызыкка.
Җирне аркылысын буйлап чыктым,
И, бу дөнья бигрәк кызык та.

Офык аша уза борма юллар,
Күтәрелә яңа үрләргә.
Нинди генә болыт өскә килми,
Нинди җилләр исми ирләргә.

Утына да керәм, суына да,
Тешләремне кысам күп чакта.
Юл газабын, мәшәкатен аның
Үзем белән йөртәм капчыкта.

Җил сызгыра, яшен чатнап уйный,
Җан өшеткән әллә дәһшәт бар?
Үткәннәрем кире кабатланмас,
Киләчәккә куйган максат бар.

Уңга китсәм — гел уңармын төсле,
Сулга китсәм — никтер уйлата.
Кырык якта кырык язмыш көткән
Киләчәккә барыр юл ята.

## Чияләр пешкән

Бакчаларымны ямьләде,
Алланып чия пешкән.
Шәфәкъ нурын, таң балкышын
Иртәсен, кичен эчкән.

Бриллиант ташы диярсең,
Тәлгәшендә чияләр.
Учларыма җыеп алам,
Мөлдерәмә чибәрләр.

Чияләрем ширбәтләнгән,
Йотарлык телләреңне.
Быелгы җәй сөенечле,
Үтәде теләгемне.

Уты-ялкыны бар сыман,
Кулыңны алыр өтеп.
Тәлгәшен түшеңә тагып,
Йөрерлек бизәк итеп.

Хозурлыгы табигатьнең,
Җәйләрнең ямьле мәле.
Иреннәремдә калырлык
Чияләремнең тәме.

## Язмыш кулындамын

Бу дөньяга тугачтын да тәүдә,
Язмыш алды үзе кулына.
Бар булмышым, хөкем карарың да,
Мин тәкъдирең синең, колың да.

Биләүләргә төреп салдың мине,
Бишегемдә сөеп тирбәттең.
Күз яшемне түктем, елаттың,
Көләргә дә үзең өйрәттең.

Куанычын, шатлыгын да бирдең,
Кайгы-хәсрәтен дә күрсәттең.
Туган җирдән еракларга илттең,
Юксындырдың кабат, җирсеттең.

Шөгылемнән ләззәт алып яшим,
Тормыш үрләренә үрләттең.
Көтмәгәндә яшен уты кебек,
Сискәндереп җанны көйрәттең.

Гомер буе язмыш кулындамын,
Төрле булды хөкем карары.
Шатлык кичергәндә — күңел балкый,
Кайгы күрсәм — йөзем карайды.

## Тормыш мәйданы көтә

Авыр хәлгә калган мәлдә,
Сабырлыкны өнәдем.
Башымны түбән имәдем,
Мөшкел булып йөрмәдем.

Күз яшьләре аша көлдем,
Кайгы болытын күрдем.
Егылмадым, бөгелмәдем,
Үз максатымда калдым.

Газапларга юлыксаң да,
Кеше булырга кирәк.

Кызганырлар гафләт басса,
Моны өнәмәс йөрәк.

Рәнҗемәдем, кыенсынмыйм,
Ихтыяр көчем сыныйм.
Уңганлыкны, сабырлыкны
Барлыймын, кирәк саныйм.

Көрәшергә, алышырга
Җитсә егәрлек күпкә,
Цирк аренасы кебек,
Тормыш мәйданы көтә.

## Сабан туе

Җиз кыңгырау тагып, пар атларда
Урамнарны яшьләр әйләнде.
Бабайлардан мирас булып калган
Сабан туе — хезмәт бәйрәме.

Яшь киленнәр чуклап сөлге чикте,
Кызлар әзерләнә бәйрәмгә.
Тимер куллы, хәлле ир-егетләр
Көчен сыный бүген мәйданда.

Һәрбер йортта олы табын көтә,
Өстәлләрдә татлы сый-хөрмәт.
Кешеләргә бетмәс байлыгын да,
Шатлыгын да бирә тик хезмәт.

Бокаллар да тулсын — шәраб салыйк,
Бәллүр тавыш ерак чыңласын.
Хезмәт уңышларын без яуладык,
Каршылыйбыз быел яңасын.

Зур тантана, тастымаллар тагып,
Атлар уза болын буена.
Батырларны алкышларга күмәр,
Халык чыккан сабан туена.

## Бөркет юлларына тиң

Себер чаклы ерак себерләргә,
Таңнан торып мин дә китәмен.
Мәхәббәтен көткән кыз шикелле,
Озак еллар түзеп көттем мин.

Өметләрем күкрәп чәчәк атсын,
Барысы да күптән бөредә.
Аягымны җиргә баскан саен,
Киләчәгем якын күренә.

Күкрәк ачып себер җилләренә,
Йөрергә бар әле исәбем.
Авырлыклар килсә — атап килә,
Ихтыярым көчен үлчәдем.

Юлларыма томан пәрдә корыр,
Бозын чәчәр зәһәр салкыннар.
Үги итмәс җирнең бер почмагы,
Барысы да миңа якыннар.

Карашымны төбәп еракларга,
Утыр дисәм, уйлар төшерә.
Шул якларга поезд узган чакта
Үткәннәрнең авазы ишетелә.

Сөрген киткән ирләр богау асып,
Күпләр аннан кире кайтмаган.

Юлларына яткан чуер ташлар
Алар истәлеген саклаган.

Бу юллар да мине илтер кебек
Күк кыяга, таулар кашына.
Бөркет кенә сайлый биек күкләр,
Ят җирләрне, йөрәк, тарсынма.

## Дөнья иминлеген сакларга

Давыл керә кайчак төшләремә,
Йокылардан куркып уянам.
Бигрәк хәтәр чорда яшибез бит,
Бер ялгызым төндә уйланам.

Атылырга торган вулкан төсле
Җир шарының һәрбер почмагы.
Кемгә тансык икән матәм маршы,
Кемгә кирәк сугыш учагы?

Атом, нейтрон бомбалары арта,
Торган саен дөнья афәтле.
Кешелеккә хәвеф-хәтәр яный,
Борчылмас та идем бу хәтле.

Варварлыкка чик куярга вакыт,
Явызлыкта кылган эшләре.
Сугыш куркынычы яшәгәндә,
Үлчәүләргә сала көчләрне.

Нәфрәтләнә бердәм барлык халык,
Кыю баса корыч сафларга.
Ант итәләр дөнья иминлеген
Сугыш афәтеннән сакларга.

## Вакыт чикле

Чигә чәчләреңә кырау тигән,
Карашларың никтер моңсу ла.
Очкын чәчеп торган күз нурларын
Сатып алалмассың мең сумга.

Йөзләреңдә ята тирән сырлар,
Басу юлы кебек бормалы.
Урман кистең, шахталарга төштең,
Сиңа яшәү җиңел булганмы.

Бирешмәче көзге гөл шикелле,
Вакыт куя үзе билгесен.
Тормыш белән күпме алышырсың,
Нәрсә көтә алда — белмисең.

Мәшәкатьләреңнән арыналмый,
Ал-ял барын, ахры, оныттың.
Тынгысыз җан икәнеңне аңлыйм,
Уңган кеше итеп таныттың.

Вакыт чикле, сансыз түгел бер дә,
Мизгелен дә тота исәптә.
Мәңге кайтмас, китәр чагы җитсә,
Кешеләрне картлык кисәтә.

## Яратып яшим

Мин абындым тигез юлда,
Баскан җирдә егылдым.
Дусларым яккан учакта,
Җан күшегеп, җылындым.

Урманга кереп адаштым,
Ташу суларга актым.
Кайгы-хәсрәтен дә күрдем,
Җәүһәр ташын да таптым.

Болытлар каплап күгемне,
Яшеннәр камчылады.
Керфекләрем буйлап акты
Кайнар яшь тамчылары.

Җилләргә каршы атладым,
Артыма чигенмәдем.
Тормыш яратып яшәдем,
Ачудан сүгенмәдем.

Аренада батыр сыман,
Җиңүче булып чыгам.
Сыналганмын күп мәртәбә,
Йөрәгем түзә, чыдам.

## *Заман чыныктыра*

Таллар сыман җиргә бөгеләмен,
Төн карасы кебек эредем.
Тормыш утларында көйрәсәм дә,
Исән калам, кабат терелдем.

Җирдән, судан, күктән куәт алам,
Баш иелмәс, горур тоталам.
Кан-яшьләре аккан каргыш белән,
И, бу дөнья күптән буталган.

Миңа гына түгел, миллионнарның
Язмышына кара тап төшкән.

Әйтерсең лә бер тамырдан үсеп,
Уртаклык бар моңа бер төстән.

Мөшкел хәлгә калып юлыкканда,
Ихтыярга, көчкә таянам.
Җирдә яшәү кануннары төрле,
Күпләр өчен беләм, тыелган.

Заман чыныктыра корыч сыман,
Өермәләр килә өстемә.
Тыныч тотмый чорлар, яшьтән безне,
О, рыцарьлар итеп үстерә.

## Үз шөгыле

Кемдер берәү чалгы яный,
Кемдер көрәген саплый,
Һәр кешенең үз шөгыле,
Гадәт-фигылен саклый.

Кемдер берәү җирләр сөрә,
Мул уңышлар үстерә.
Кеше хәстәрен күрә шул,
Йөкләп ала өстенә.

Кемдер берәү күзен йома,
Дөнья белән хушлаша.
Фаҗигаләргә юлыга,
Юлларында адаша.

Берәүләр гел сусап яши,
Кешенең канын эчә.
Хөсетлек кылып яшәгәч,
Агуын җиргә чәчә.

Кемдер якты нур балкытып,
Йолдызларга тиңләшә.
Бөтен шатлык-куанычын
Үз халкына өләшә.

## Җиремә сөенәм

Чит якларга сәфәр чыгам,
Юлым төшә еракка.
Туган җиргә сагыну хисен
Саклап йөртәм йөрәктә.

Ят җирләрдә озак йөрсәм,
Үз йортымны юксынам.
Тартылам, очарга торган
Җәядәге ук сыман.

Кай тарафтан килдең, дигән
Сорауларга күмеләм.
Бер горурлык белән әйтәм, —
Башкортстан иленнән.

Безнең халык дан казанган,
Уңган, хезмәт ярата.
Үз җиремә сөенеп кайтам,
Күңел хисләр яңарта.

Туган төягем, кабыздың
Гомер учагымны син.
Рәхмәтлемен: иркен ачтың
Тормыш кочагыңны син.

## Урман кочагында

Агачларга карап җырлыйм әле,
Бер бушаныйм — рәхәт тоела.
Күз камаша монда тантанага,
Яфракларның алтын туена.

Киереп ачтың, урман, кочагыңны,
Сукмагыңнан киләм — йөреттең.
Ялгыз хис итмәдем һич үземне,
Миңа таныш имән егетең.

Миләшләрнең балкый учак уты,
Яфраклары белән серләшим.
Усакларның билләреннән кочтым,
Кардәшләрем итеп эндәштем.

Урман моңсулыгын тоймадым да,
Агачлар да күздән туй ясый.
Сайрар кошлар китсә, хушлашканда,
Зәңгәр диңгез сыман бер ярсый.

Җилләр дә бит ярсып шашып ала,
Сукмакларга поскан, тын ята.
Урман шаулый, берчак өнсез кала,
Гел шомланып тормый дөнья да.

## Йокыларың калды бүленеп

Ак мендәрдә татлы йокы кала,
Иртә белән капка ачыла.
Кулбашына салып ай-урагын,
Таңнан китә әни басуга.

Иген басулары уятамы,
Тургайлар да какты канатын.
Җәйрәп яткан сәхрә-кырларны
Гомер буе, әни, яраттың.

Батыр диңгезчегә тиңләшәсең,
Килеп баскач җирнең башына.
Күңелең сыман ярсып, башаклар да
Чайкалдылар синең каршыңда.

Учларыңа урып, учма салдың,
Кулларыңа тотып урагың.
Игеннәрең уңган — кырга сыймый,
Басуларны ничә урадың.

Көлтәләрен кысып күкрәгеңә,
Бала кебек итеп сөясең.
Тырышлыгың, уңганлыгың белән,
Хезмәт белән, әни, чибәр син.

Җиргә төшермисең башагын да,
Чүпләп алдың аның бөртеген.
Мичтән алдың — иртә белән пешкән,
Табыннарга икмәк китердең.

## *Иминлекне яклап*

Ак мендәрдә хәрәкәтсез ята,
Төне көнгә килеп тоташа.
Брянск урманында йөри,
Партизаннар белән саташа.

Маңгаенда бөрчек-бөрчек тире,
Тирән ала, авыр сулышы.

Тел очында сүзе, әйтә алмый,
Үкенечкә калыр соңгысы.

Өметләнеп якты көнне көтә,
Терелергә генә исәбе.
Тән өстеннән китми җәрәхәте,
Телгәләгән кургаш кисәге.

Диңгезче дә, партизан да булган,
Суны кичә, керә утына.
Яшәү белән үлем арасында
Туры кала биргән антына.

Утлы ядро асларында калып,
Соңгы әманәтен саклаган.
Соры шинель, кирза итек киеп,
Европа буйлап атлаган.

Ак халатлы шәфкать туташы да
Баш очында басып тора тын.
Сабырлыгы, горурлыгы җитә,
Көтеп ала соңгы минутын.

Гомеркәен бизи көрәш кыры,
Һәр кешегә якын, кадерле.
Иминлекне, азатлыкны яклап,
Җирдә арта солдат кабере.

## *Кешечә яшә, диләр*

Кешечә яшәргә өйрән,
Белмисең, энем, диләр.
Дусларым, иптәшләрем дә
Үгетлиләр, димлиләр.

Кыйбла якны яхшы бел син,
Табын катына әйдә.
Хан булып яшәргә кирәк
Унар бүлмәле өйдә.

Җиргә баткан иске йортың,
Каралтың да җимерек.
Юк эш хакына йөрисең,
Уйлан, диләр, син элек.

Син дә түрә булып кара,
Сөяркәләр тотарсың.
Таласаң да ил байлыгын,
Алдашсың да, отарсың.

Алыш-биреш итеп кара,
Сәүдәгәр исемен ал.
Кадерең артыр синең дә,
Капитал кесәңә сал.

Аягыңда килеш, энем,
Йөремә, диләр, йоклап.
Табыш биргән бер җиңел эш,
Ал, диләр, инде йөкләп,
Кешечә яшә, иплəп.

## Атам йорты көтә

Туган якка күптән кайтканым юк,
Төшләремә кереп йөдәтә.
Атам йорты, сәхрә кырлар — бар да
Урын алган, сыйган йөрәккә.

Яшьли киттем атам нигезеннән,
Авыр йөкләр салып сөйрәтте.

Елар чакта еламаска кушты,
Сызланмаска җанны өйрәтте.

Сәбәпләре төрле — санамадым,
Юлга чыксам, кайчак борылам.
Хәлсезләнеп, көчем җитми кала,
Башым белән җиргә орынам.

Туган җирем үз иткәнен тоям,
Онытмады — һәрчак чакыра.
Әллә бер мин генә юксынамын,
Чара табалмадым чак кына.

Кошлар кебек очып кайтырмын да,
Иңнәремдә булса канатлар.
Авылымда үскән егетләр бар,
Язмышымны кемдер кабатлар.

Мине әсир итте туган төяк,
Бар дөньяның синдә яме бар.
Атам йорты көтә — нигъмәте күп,
Чишмә суы эчсәң — тәме бар.

## *Агачларда бөре ачыла*

Сыерчыклар кайткан, оя кора,
Агачларда бөре ачыла.
Туй күлмәге киялмәгән кызлар
Каеннарга карап борчыла.

Табигатьтә һәрчак сакчыллык бар,
Бар да уяу, бар да җанлана.
Гөрләвекләр чыңлый, елга таша,
Сулар менә ярсып ярларга.

Кар астыннан умырзая чыккан,
Яшел чирәм төрә тау кашын.
Җәйрәп яткан зәңгәр офыкларда
Торып калды якты карашым.

Җир күчәре, берни булмаган күк,
Әйләнә гел, алга уктала.
Ак күлмәкле каеннарга карап,
Язлар җиткәч, кызлар уфтана.

## Үсегез, тирәкләрем

Яшь тирәкләр су буенда,
Тибрәнә талгын җилгә.
Якты бизәк булып төшкән,
Шәүләсе яткан җиргә.

Буйга үсеп кенә килә,
Кошлар кормаган оя.
Тирәкләрдә җанлылык бар,
Серле күкрәүләр тоя.

Тирәкләр дәшә чакырып,
Очкан кошларны күзләп.
Үз вакытын көтеп ала,
Әллә юаныч эзләп.

Буй җиткерә, хозурлана
Табигать кочагында.
Күкләргә карашын сала,
Моңлана уйчан гына.

Сәхрә-кырларымны күрдем,
Талпынды йөрәкләрем.

Туган җиргә ямь өстәгез,
Үсегез, тирәкләрем.

## Хезмәт кешесе

Олы хөрмәт баглыймын мин,
Хезмәт кешесен күрсәм.
Алтын итәр тимерне дә,
Көч кызганмый җан өрсәң.

Кулы бара бар эшкә дә,
Башкара төгәл итеп.
Теләген чынга ашыра,
Эш көнен ала көтеп.

Уңганлыгын, тырышлыгын
Хезмәт җимеше сөйли.
Гомерлектер дәрт ялкыны,
Йолдызга тиңлим, сүнми.

Хезмәт кешесе шөгылен
Бар галәм тора күзләп.
Ай-кояшкай кебек юмарт,
Тормышны ямьли бизәп.

## Дусларым була терәк

Шатлыкны да, кайгыны да
Бүлешер кеше кирәк.
Юанычлар табалмасаң,
Дусларың була терәк.

Сүнеп барган учак төсле,
Пыскып ятма син көйрәп.
Күпме генә талпынсаң да,
Тынычланмассың, йөрәк.

Өмет утын кабызырга
Җитә назлы караш та.
Җил иссә дә талгын гына,
Ярда бии камыш та.

Битарафлык күрсәтмәдем,
Гамьсезләнмим ничек тә.
Көн-таң атса, көтеп алам,
Дуслар килсен ишеккә.

Җирдә ялгыз яшәмәдем,
Күптән таныш формула.
Дуслар белән бергә булсам,
Айга очарга була.

## Күңелемдә — җир бизәге

Күңелемдә мең төрле нурлар балкып уйный,
Кеше минем хакта әллә ниләр уйлый.

Якты көнне караңгы төн алмаштыра,
Бу табигать үзе белән таныштыра.

Мин табигатьнең сөекле улы булдым,
Юмартлыгын тоеп яшим, аннан ундым.

Сәхрә-кырлар сыеп бетә, күңелем — киң,
Зәңгәр дулкыннар уйнаткан диңгезгә тиң.

Чишмәләрнең дәртле моңын отып алдым,
Җырга булган мәхәббәткә тугры калдым.

Болыннардан, тугайлардан кайттым йөреп,
Күзләрем камашты матурлыгын күреп.

Таулар, чакырып, яннарына кул изәде,
Күңелемә күчте бөтен җир бизәге.

## Заман

Ракеталы, нейтронлы безнең заман,
Вулкан төсле атылырга тора һаман.

Бу дөньяның илләре дә төрле-төрле,
Тыныч яшик, дисәм, аңларлармы телне?

Ничә дәүләт, ничә лагерь халкы каршы,
Кемгә тансык булыр матәм маршы?

Кешеләргә утлар йотып ник яшәргә,
Чик куярга вакыт җитте бу мәхшәргә.

Туп шикелле типкәләргә исәп тота,
Җир-ананы көйрәтмәсеннәр, дим, утта.

## Урман юлы

Бу хисләрнең артык кайнарлыгы
Агачларга барып урала.
Мәрмәр заллар да юк, сәхнәләр дә,
Гел үзенчә яши урман да.

Агач кәүсәләре кардан чыккан,
Кыйбла яктан йомшак җил өрә.
Яктылыкка, назга башын сузган,
Усак бөреләре өлгерә.

Урман шанлы каршылады көнне,
Җырчы кошлар белән яз башын.
И, шатлана, сайрый, канат кага,
Миңа таныш, җырчы, язмышың.

Сары сандугачың талга кунган,
Башка кошлар әллә көнләшә.
Барысы да шашып канат кага,
Барысы да аңа тыңләшә.

Җиргә ята агач шәүләләре,
Тау сукмагы сыман тарала.
Урман шаулый кошлар сайраганда,
Җыр отамын барган арада.

Яланнарга, атауларга чыгам,
Зәңгәр дәрья сыман күренә.
Урман юлы алга дәшкән саен,
Мин күбрәк төшәм серенә.

## *Авылым чишмәсе*

Тау астыннан гөрләп ага,
Авылым, чишмә суың.
Күп гасырлар узып киткән,
Белмисең аның санын.

Таш катламын ярып чыккан,
Ташулар булып ташты.

Моңлы, җырлы ямьнәр өсти,
Авылның йөзек кашы.

Сусаганда суың эчтем,
Сугардың тәнне-җанны.
Чишмә буйлары тал-тирәк,
Кошлар сайравы җанлы.

Көмеш кыңгыраулар сыман,
Чыңлый, чишмә, тавышың.
Авыл халкы тансык итә,
Дәртләндерә таныш моң.

Күзләрең йомылмасын да,
Өн-авазың тынмасын,
Һәрчак чишмә агышларын
Авылым халкы тыңласын.

## Кулларымны канат итәм

Ике кулны ике канат итеп,
Урап чыгам галәм киңлеген.
Киңлекләрне тирәнлеге белән
Сыйдырала үзенә күңелем.

Абагалы яшел урман буе,
Зәңгәрсу рәшәләр тирбәлә.
Дингез генә һичбер дә күрсәтми,
Җәүһәрләрен саклый тирәндә.

Йолдызларга карап күзем кыза,
Баш өстендә балкып күренә.
Күкләремдә оча корабльләр,
Биеклеккә һаман үрелә.

Галәм киңлекләрен айкап әллә,
Хезмәт вахтасыннан кайтасың.
Гаҗәпләнмим һич тә сюрпризга,
Алып төшсәң зәңгәр ай ташын.

Уйлар йөгерә чиксез киңлекләргә,
Мәртәбәне, беләм, данлыйсың.
Каһарманнар узган юлны сайлап,
Килә минем бәхет даулыйсым.

## Көч табам

Күз яшьләрен, дөнья, түктерәсең,
Әрнеш белән гомер итәмен.
Газабыңны күреп яшәгәчтен,
Нинди рәхим синнән көтәмен?

Этләр туен күреп гомер үтте,
Тормыш ләззәте юк бер төрле.
Ызгыш-талаш белән узган көннәр
Йөрәгемне талап бетерде.

Юанычлар эзләп карасам да,
Табалмадым аның дәвасын.
Биләүгә дә, кабергә дә сала
Фани дөнья адәм баласын.

Табигатьнең кырыс кануннары,
Үскән гөл дә корый вакытсыз.
Гомеремдә күп югалту күреп,
Көйрәп яндым утсыз, ялкынсыз.

Бу заманда яшәү җиңелмени,
Мин көч табам иҗат эшемнән.

Йөрәк кенә түзсен шартламыйча,
Көнчел кешеләрнең үченнән.

## *Озак яттың авырып*

Озак яттың авырып, хәлсезсең,
Күтәр әле, әни, башыңны.
Язлар җитте, ямьле көннәр килде,
Бозлар ага, елга ташыды.

Тәрәзәгә торып кара әле,
Кар пәрдәсен ачты кырларым.
Рухың төшкән, күңел күтәрерсең,
Ишетерсең тургай җырларын.

Үлем көтеп ятма түшәгеңдә,
Кыр казлары кайта күленә.
Урам читләрендә борын төртеп,
Яшел чирәм шыткан — күренә.

Гөрләвекләр тавышы тынмый әле,
Җил тирбәтә агач бөресен.
Өй алдында каз-үрдәкләр йөри,
Их, терелсәң, җимнәр бирерсең.

Тормыш йөген сөйрәп яшәгәчтен,
Киләчәккә юллар чакыра.
Язга, әни, өмет багласаңчы,
Сабыр итсен әҗәл чак кына.

## *Кояшым да, аем да бул*

Җан өшегән, калтыраган чакта
Җылы тапмый иза чигәмен.
Бик кызганыч — үз-үземне кочам,
Кечерәеп калам, чүгәмен.

Каным туңа, йөрәк хәлсезләнә,
Авыр сулап куям бу мәлне.
Давыл кубар, җир тетрәр, бәлки,
Ничек тә кил, бел син хәлемне.

Син кил миңа якты кояш булып,
Күңел бозларымны эретерсең.
Хисләремне уят ташкын итеп,
Көткән язларымны китер син.

Мөлаемлы карашыңны күрсәм,
Бөркет сыман канат кагармын.
Тормыш учагына ут алырмын,
Җан җылысы шунда табармын.

Кояшым бул инде, аем бул син,
Энҗе нурлар чәчеп китәрсең.
Моңсу минутымда рухым төшсә,
Йолдызларга кадәр күтәр син.

## *Мәхәббәт күбәләгем*

Вәгъдәләштек, сүз куештык,
Туйлар ясарга исәп.
Егет сүзе бер була ул,
Килмисең әле нишләп.

Аккошым, фәрештәм, диден,
Чыңлый сүзең колакта.
Гөлбакчада, айлы кичтә
Серләштек без аулакта.

Киләчәкне күзаллаек,
Сөю хисе сүнмәсен.
Бүләк иткән чәчкәләрең
Һич вакытсыз шиңмәсен.

Тормыш учагын тергезик,
Бәхет ишеген ачсын.
Сөеп, сөенер чагыбыз,
Теләкләр чынга ашсын.

Изге эшләр кылдык микән,
Син кайчан төгәлләдең?
Очып йөрисең кайларда,
Мәхәббәт күбәләгем?

## Хатларымда — йөрәк җылым

Айлар түгел, моңа еллар шаһит,
Язган хатым кала җавапсыз.
Бераүгә бу хәл кызык тоела,
Хаҗәте юк, имеш, яраксыз.

Хатларымда барсын йөрәк җылым,
Саф мәхәббәт, кайнар хисләрем.
Барысын да шуның сиңа юллыйм,
Хәтерләтсен күргән төшләрең.

Минем ярсу, кайнар сөюемне
Вакыт яңгырлары юмасын.

Бер ышаныч белән яшим әле,
Шикле уйларым да югалсын.

Почтальоннар хатлар тапшырганда,
Учакларга аны ыргытма.
Өзелеп сөйгән кешең сәлам юллый,
Бу дөньяда мин бар, онытма.

Җавап көтәм язган хатларыма,
Акланмыйча кала өметем.
Әллә язмыш сынап карыймы соң,
Ихтыярын чын ир-егетнең?

## *Син — язмышым*

Тормыш юлым илтә киләчәккә,
Язмышымның, белмим, кайсысы.
Кемнеңдер син бетмәс зур шатлыгы,
Кемнеңдер син ачы кайгысы.

Мин киләсен син дә белмәгәнсең,
Юлларымда сине очраттым.
Күрер күзләремә нур балкыттың,
Бер күрсәм дә, ихлас ошаттым.

Күзләребез сүнмәс ялкынланды,
Сүзләребез сүзгә кушыла.
Көтмәгәндә кызык булды бу хәл,
Килеп бастың көлеп каршыма.

Без моңарчы таныш булмасак та,
Күңел тартылгачтын, караштык.
Күпме күзләр арасыннан сайлап,
Якын күреп, көлеп табыштык.

Киләчәккә барам юлларымнан,
Син — язмышым,
белмим, кайсысы.
Кемнеңдер син бетмәс зур шатлыгы,
Кемнеңдер син бетмәс кайгысы.

## Туган җирдә мәхәббәтем

Авылымнан китәм, дигән чагым,
Бураннарда, кара күзләрдә.
Сандугачлы язлар,
җәйләр җитсә,
Уйлар башка, тагын үзгәрә.

Бер фикергә һаман киләлмимен,
Хушлашырга булмас быел да.
Нигез ташын,
туган туфрагымны
Ташлап китүләре кыен ла.

Көмеш кыңгыраулы чишмәләрем,
Дулкын шаулый зәңгәр күлемдә.
Мәхәббәтем, шатлыкларым барда
Күтәреләм бәхет күгенә.

Якты таңнар тәрәзәмдә балкый,
Алмаларым алсу аллана.
Туфрак җылың каннарыма күчә,
Алмаштырмыйм аны калага.

Ата-бабам нигез корган монда,
Чәчкән, урган, иген үстергән.
Куанычлар, табышлары белән
Хезмәт сөйгән, гомер кичергән.

Үз җиремә шөкер итеп яшим,
Мәхәббәтем арта, куанам.
Иген үсә, гөлләр чәчкә ата,
Бар да уңа минем кулымнан.

## Кеше

Кеше җирдә
Бәхет көтә.
Гомер юлын
Үзе сүтә.

Эше белән,
Төсе белән,
Көче белән —
Төрле, беләм.

Күңеле ак,
Карасы бар.
Җәрәхәтле,
Ярасы бар.

Бар моңлысы,
Бар җырлысы,
Бар шомлысы,
Бар җылысы.

Һәр кешенең
Үзгә эше,
Җәүһәр кебек,
Төрле төсе.

## Игенче

Таңнан ашыга
Игенче кырга.
Иркен басулар
Күмелә җырга.

Җирне тырмата,
Сукасын сөрә.
Яңгырын, җилен
Күп тапкыр күрә.

Игенче тырыш,
Кара тир түгә.
Озын көн буе
Билләрен бөгә.

Ашлыклар уңса,
Шатлыгы сыймый.
Уңышын җыеп,
Бәхетен сыный.

Җиргә бәйләгән
Язмышын белеп.
Игенче яши
Хәстәрен күреп.

## Май яме

Көнем кояшлы,
Төннәрем айлы,
Көтеп аламын
Чәчәкле майны.

Май ае ямьле,
Тургайлар сайрый.
Назлы җилләре
Чәчемне тарый.

Күкрәүләр йөри
Офык артында,
Сәхрә-кырларга
Караш тартыла.

Яшел басулар
Дулкын күтәрә.
Кош юлы үрли
Зәңгәр күкләргә.

Табигать уяу,
Илаһи көч бар.
Күз явын алган
Ничәмә төс бар.

Әсир итәрлек
Гүзәл май яме.
Синдә генәме
Бөтен җир гаме?

## Таң ата

Тын офык читендә
Яктылык күренә.
Алсу таң нурына
Бар дөнья күмелә.

Сылу кыз шикелле,
Таң көлә, елмая.

Тирәктә талпынып,
Сайрар кош моңая.

Мөлаем, бик юмарт
Таң нурын өләшә.
Һәр агач, һәрбер гөл
Үзенчә эндәшә.

Яфраклар серләшә,
Чишмәләр телләнә.
Күк төсе, җир өсте
Күп төргә төрләнә.

Бу изге сәгатьтә
Сихри көч яңара.
Җир балкый, нурлана,
Яңа көн ярала.

## Юллар озая

Юллар йомгагын
Гомергә сүтәм.
Тормыш кырларын
Мин җырлап үтәм.

Язмышым дәшә
Ерак җирләргә.
Йөз куеп барам
Искән җилләргә.

Чыксын юлларга
Җаным яраткан.
Әзме канатлар
Давыл канаткан.

Бар мәшәкате,
Бетмәс газабы.
Кайларда туктар
Юллар азагы?

Заман озайта
Йөргән юлларны.
Галәмгә оча
Илем уллары.

## *Күпер салам*

Күпер салам
Үткәннәргә,
Бу дөньядан
Киткәннәргә.

Күпер салам
Киләчәккә,
Киртә кормыйм
Күрәчәккә.

Киләчәк, син —
Хыялымда,
Күңел белән
Тоямын да.

Мул тормышта
Кешеләре,
Алар белмәс
Көнчелләрне.

Имин торыр
Бөтен дөнья,

Җырлап агар
Идел-дәрья.

Галәмнәргә
Салам күпер,
Еллар аша
Юллар үтәр.

## Күл өстендә ак томан

Кояш нуры уйный көне буе,
Күл өсләре тонык, тын ята.
Шик-шөбһәләр калмый мондый мәлне,
Серле кичерешләр уята.

Пар аккошлар йөзә күл суында,
Камышлары өнсез, тын калган.
Назларына аның ләззәтләнә,
Тирә-юнем чыңлый, моң тулган.

Җилләр тарый аккош каурыйларын,
Дулкыннарга салып тирбәтә.
Җәй айларын ямьләп, данлап җырлый,
Кошлар кунган, сайрый тирәктә.

Күл буйларын яшел сукмак чорный,
Төрле тарафларга таралган.
Туган җиргә бер хәзинә итеп,
Күпләр гүзәллеккә табынган.

Фәрештәләр әллә канат җәйгән,
Күл өстендә иртән ак томан.
Табигатьнең иркен кочагында
Җир-анам күзен ача сыман.

## *Егет чакта*

Егет чакта ут чәчрәтеп,
Клубларда биедек.
Тар балдаклы чалбар киеп,
Модный гына йөр(е)дек.

Кичләрен урам әйләндек,
Гармун уйнап, жырладык.
Яшьлек назын, гүзәл мәлне
Кадерләдек, зурладык.

Җан күкрәве тынгы бирми,
Күтәрәм горур башны.
Ашкынып йөрәгем тибә,
Күңелдә хисләр ташты.

Тулпарларны йөгәнләдек,
Җилдән җитез җилдердек.
Оран салып бар җиһанга,
Егетлекне белдердек.

Яшьлек истәлеге итеп,
Асыл гөлләр җыямын.
Давылларны уятырлык
Көч-дәрт барын тоямын.

## *Бәйрәм сые өстәлдә*

Бер ел тагын үтеп китте,
Маңгайга сыр өстәлде.
Шампан шәраблары тора,
Бәйрәм сые өстәлдә.

Яңа ел кичен каршылыйм,
Сәгать теле кисәтә.
Дусларны табынга җыйдым,
Барлап чыктым исәптә.

Үткәннәр белән хушлашам,
Моңсумын, сагышлы да.
Шатлыгын, кайгысын күрдем
Вакытлар агышында.

Җир-суыбыз имин торсын,
Дусларым, бергә булыйк.
Зурлаек хезмәт кешесен,
Һәр йортта булсын муллык.

Татлы хисләр ташып тора,
Иңә төсле күкләрдән,
Мәҗлес ямьле, дуслар янда,
Шуңа да тост күтәрәм.

## Әкият итеп сөйләрлек

Буй җиткергәч,
Үрелеп сука тоттым.
Озын көне буе җир сөрдем.
Егет чакта,
Урамнарны иңләп,
Тальян гармун уйнап мин йөрдем.

Башта бүрек, өстә чикмән булды,
Купшылана әллә белмәдек.
Аямады безне язмыш, ахры,
Мул тормышны, назны күрмәдек.

Аулак өйдә
Урын аш пешердек,
Заманасы исең китәрлек.
Уйнарга да, көләргә дә булды,
Үзебезчә күңел күтәрдек.

Еллар уза,
Үткәннәргә карыйм,
Бетми кызык, юләрлек.
Яшь чакларны искә алсам,
Әкият итеп кенә сөйләрлек.

## Авылым

Авылым,
Гүя тау куеныннан чыккан,
Таулар белән тора тиңләшеп.
Чал түбәле монда таш кыялар,
Күккә карый, ахры, көнләшеп.

Ямьле, биек, якты йортлары да,
Озын булып сузган урамы.
Диңгез кебек дулкын кагып тора,
Шаулап үскән иген кырлары.

Шомырт тәлгәшләнә ак чәчәккә,
Керфегеннән хуш ис түгелә.
Кыр казлары кайта тезелешеп,
Төнбоеклы зәңгәр күленә.

Юмарт туфрагында гөлләр үсә,
Иртә таңда чыклар төшәләр.
Арыш басулары серкә очыра,
Карлыганнар изрәп пешәләр.

Туган җирем, туфрагыңны үбәм,
Анам кебек килә кочасым.
Зифа талың, кәүсәр чишмәң белән,
Күз алдыма килеп басасың.

## Дөнья һаман тыныч түгел

Сугыш дигән сүзне ишетсәм дә,
Тетрәп китәм, йөрәк сызлана.
Күңел һаман көрәш корбаннарын,
Ятимнәрне ифрат кызгана.

Дөнья нигә тыныч түгел икән,
Бомбаларны сынап торалар.
Агрессорлар безгә каршы күптән
Сугыш планнары коралар.

Безнең халык иминлекне яклый,
Барып чыкмас алар планы.
Безнең якта хаклык,
Безнең якта, чөнки,
Хаклык дигән көрәш коралы.

## Үкенечле булмасын

Узып киткән гомер юлларыма
Күңел күзен салдым тагын да...
Егет чакта йөргән малайларны
Очратамын сирәк, табында.

Очрашкачтын, сөйләп сүзләр бетми,
Төннәр буе бергә утырдык.

Хатирәләр яңара күңелдә,
Йөрәкләрне моңга тутырдык.

Узган гомер — аккан сулар кебек,
Үткәнен дә аның сизмибез.
Кайберәүләр юк ич арабызда,
Күңел юксынгачтын, эзлибез.

Аерылгачтын, еллар үткәч кенә,
Якыннарын кем дә сагына.
Аяныч ы, үкенечле икән,
Караш төшә юллар ягына.

Якты таңны бергә каршылаек,
Күк читләре әле аллансын.
Гомер уза, еллар үткән саен,
Үкенечләр генә калмасын.

## Халык күңелендә син

*Мостай Кәрим истәлегенә*

Башкортстан күген бизәп,
Йолдыз булып балкыдың.
Бөтен галәмгә җитәрлек
Йөрәк утың, ялкының.

Күңелләргә нур балкыттың,
Язлар булып җылыттың.
Моңсызларны моңландырдың,
Ил халкын җырлы иттең.

Пәйгамбәрләр затыннан син,
Изгелек кылдың җирдә.

Замандашың шаһит моңа,
Тиңләштермәс мең иргә.

Дөнья аренасында син
Хаклык өчен көрәштең.
Ходай биргән шагыйрьлекне
Хуплап алдың, күрәсең.

Шәм шикелле кинәт сүндең,
Сизми калдык бер төнне.
Әҗәл нигә аямаган
Бу дөньяда Шагыйрьне?

## *Гел бергә*

*Хәсән Туфан истәлегеі*

Шагыйрь рәнҗетүне, кимсетүне
Үз йөрәге аша үткәрде.
Иңгә төшкән авыр кичерешне,
Таулар кебек, горур күтәрде.

Сыйныф яклы түгел, имеш, контр,
Көнчел затлар яла яктылар.
Гомеренең матур язларында
Аягына сугып ектылар.

Тоткынлыкта яши кош шикелле,
Канатларын язмыш каера.
Яшен яшьни, күкләр күкри аңа,
Баш өстендә болыт куера.

Шагыйрь өчен давыл уты сүнми,
Каны тамып тора дөньяның.

Бик кадерсез ятим бала төсле,
Тормыш кырларында кыйналды.

Бинахакка җаны әрнегәндә,
Күкрәгенә аһ-зар җыйнала.
Таш зинданда күпме кыйналса да,
Күз карашы була юлларда.

Югалтулар, юксынулар хисе
Борчылдыра аны гомергә.
Көрәш мәйданына җырлап килде,
Халык белән атлый гел бергә.

## Игеннәрнең үсмер чагы

Җәй иртәсе, күктә нур балкышы,
Күз карашым тарта еракка.
Сәхрә-кырларның бу хозурлыгын,
Басу ямен күңел ярата.

Арышлар да яңа баш чыгарган,
Бала бишеге күк тирбәтә.
Берчак тына, берчак дулкын кага,
Ничә төргә көнгә төрләнә.

Сабан тургайлары җырын көйли,
Күкләреңә менеп тараттың.
Басу түрләреннән йөгереп уза,
Җилләр какты каурый канатын.

Малайлар күк уйный башаклар да,
Кояш нурларына коена.
Үсмер чагы җиткән игеннәрнең,
Бу мәл миңа тансык тоела.

## Тәрәзәңдә таң нурлары

Таң нурлары кунгач тәрәзәңә,
Әни, бүлдең татлы йокыңны.
Якты көнгә өмет баглыйсыңдыр,
Изге догаларың укыдың.

Кабул итеп тормыш мәшәкатен,
Урыныңнан торып басасың.
Вазыйфаңны теләп башкарасың,
Иртән иртүк ишек ачасың.

Чишмәләргә барып су аласың,
Учагыңда утлар дөрләсен.
Төрле уйлар баштан кичерәсең,
Йөзләреңдә сагыш күрмәссең.

Күңел күкләреңдә күкрисең,
Ташу сулар булып агасың.
Язмыш кырыс, ул үзенчә сыный
Бу дөньяда адәм баласын.

Куанычлар тоеп яшәгәнгә,
Шөгыльләрнең барын өнисең.
Ике кулың эштән бушап тормый,
Җаның тынычлыгын белмисең.

## Бер карашың җитә

Юк,
Сизмисең, ахры, карашымны,
Сиңа гына карап күз кысам.
Тоясыңмы ярсу йөрәгемне,
Аңлатырга теләп, сүз кушам.

Тарсынмыйча, керфегеңне сирпеп,
Каршыма ук килеп бас әле.
Челтәр пәрдәләрен күтәреп куй,
Тәрәзәңне, иркәм, ач әле.

Бер карашың җитә, шул теләгем,
Елмай әле, нигә көлмисең?
Ялкынланды сөю хисләрем,
Их, син генә аны белмисең.

Килерсеңдер, димен, мин чакыргач,
Якын итсәң, әгәр иш итсәң.
Син бәхетле итәр идең дә бит,
Сөям, дигән сүзең ишетсәм.

## Үз кардәшем

Ике туган: татар, башкорт,
Арага чөй какмадык.
Кулга кул тотып тормышта,
Киләчәккә атладык.

Үз башкортым, үз татарым,
Бергә көн күрү мотлак.
Туган җиребез бер генә,
Язмышлар безнең уртак.

Кода-кодагыйлар булдык,
Туй ясап, кызлар бирдек.
Бергә яшик, бергә булыйк,
Дөньяның ямен күрик.

Үз кардәшемә барамын,
Кымыз эчәргә дисәм.

Табын корам, мәҗлес ясыйм,
Башкорт туганым, килсәң.

Туганлыкка чик куймадык,
Ватанга хезмәт итик.
Дуслык хисләрен сүндерми,
Гомер сукмагын үтик.

## Таң уянды

Таң уянды җиләс сулыш өреп,
Үлән-яфрак куйды калтырап.
Күл өстендә вак дулкыннар чыңлый,
Көмеш чулпылар күк ялтырап.

Тирәкләргә, агач башларына
Тонык таң балкышы үрелде.
Төн карасы җирдә эреп ята,
Көн яктысы күзгә күренде.

Сайрар кошлар канат какты иртә,
Тирә-юньгә моң-аваз салды.
Каршылыймын ничәнче таң икән,
Миңа билгесез кала саны.

Сокландыра таңның хозурлыгы,
Кодрәт көчең җитә — кочасың.
Еракларда йокымсырап яткан
Офык капкаларын ачасың.

Аклык-сафлык шөһрәт биргән мәлдә,
Бу күренеш белән килештем.
Җиһан киңлегендә шәм кабызып,
Якты нурларыңны өләштең.

## Авылым кичләре

Авылымның кичләре дә ямьле,
Тальян гармун моңын чыңлата.
Яшьлек язларыма алып кайта,
Мин хушланам моңа чынлыкта.

Тулган ай калыкты күк йөзенә,
Сызып үтте көмеш буразна.
Татлы кичерешләр биләп алды,
Өнсез калып торам беразга.

Алма агачлары шау чәчәктә,
Хуш исенә күмде бу төнне.
Җан азыгын табып сихерләндем,
Башта уйлар йөри бер төрле.

Хәтеремдә калыр май кичләре,
Күңел түрләремә күчерәм.
Дәртле җыр-моңнарга канатландым,
Ташкан хисләремә исерәм.

Ашыктыра вакыт агышлары,
Их, куйсагыз мине иректә,
Күз камаша мондый хозурлыкта,
Юк, туймадым әле күреп тә.

## Онытa алмассың бу якларны

Булдыңмы син элек бу якларда,
Атлар җигеп бармы үткәнең?
Бармы синең язын чәчәкләрне,
Болыннарда йөреп, үпкәнең?

Сылу кызлар кебек ак каеннар
Керфекләрен түбән карыйлар.
Аналарча назлы таң җилләре
Чәчләремнән сөеп тарыйлар.

Ялтыраплар яткан тын күлләргә
Зәңгәрлеген биргән күкләр дә.
Җир куенында нефть фонтан бирә,
Бу як таныш илдә күпләргә.

Ямь табарсың безнең якларда,
Тәм табарсың эчкән суыннан.
Бер күрсәң дә, гомер буена
Онытмассың әле соңыннан.

## Ел фасылы чылбырында

Язлар миңа чәчәк алып килде,
Хушландыра, илһам-дәрт биреп.
Еллар буе яткан кар-бозларым
Йөрәк түреннән аксын эреп.

Җәйләр миңа татлы нигъмәт бирде,
Сыйландым җиләк-җимеш белән.
Онтылмаслык хатирәләр калсын,
Бу мәл – куанычлы чор, беләм.

Көзләр миңа җыр-моңнарын бирде,
Мәҗлесләрдә бергә җырларбыз.
Гомерләр бушка әрәм узмасын,
Тормыш гамен мактап зурларбыз.

Кышлар аклык-сафлык алып килде,
Дөньям хәзер күпкә яктырак.

Тәңкә кебек карлар юлларымда
Күз алдында уйный ялтырап.

Көмеш божра сыман бергә тоташ,
Чылбырында елның фасылы.
Үз төсендә, үз мохите аның,
Мәңгелектер саклый асылын.

## Уйлар дәрьясында

Ялгыз төштем уйлар дәрьясына,
Үткәннәрне кайтам ачыклап.
Буй суының яшел тугаенда
Малай чагым калды ат саклап.

Ир уртасы булып җиткәч сиздем,
Сабырланам, арта көчем дә.
Яшьлек дәрте, кайнар ташкын хисләр
Кая китә, кая күченә?

Якты өметемне каршылыймын,
Көтеп алам алсу шәфәкъны.
Гомеремнең узган һәр минуты
Сагындыра нигә шулчаклы?

## Хезмәт куанычлы

Иртә торам, соңга калмыйм,
Бу хәлгә күнегелгән.
Эш калдырып йоклап яту
Хупланмас күңелемнән.

Яшьли эшкә тотынгачтын,
Хезмәткә гадәтләндем.
Бар көчемне сарыф иттем,
Дәртләндем, гайрәтләндем.

Җаным теләп башкарамын
Кулыма алган эшне.
Күктә йолдызлар кабызам,
Таңнар аттырам төсле.

Тормышны гел матурларга
Үземә максат куям.
Асыл ташларын тезәмен,
Кул белән алтын коям.

Төрле шөгыльләр башкарам,
Баш тартмыйм, күнегелгән.
Хезмәт куанычын тоям,
Сөенәм күңелемнән.

## *Көнем уза басуларда*

Озын көнем басу түрендә гел,
Эшләп үтә, тәмам арыймын.
Өйгә кайткач ятып хәл җыямын,
Тирән йокыларга тарыймын.

Басуларга, кырларыма бәйле,
Багышладым гомер юлымны.
Тырышлыгым бушка китмәгәчтен,
Балаларча ихлас юанам.

Авыл кешесенең шөгыле шул,
Таңнан шәфәкъкача эшләдем.

Шушы җирдә бәхетемне эзлим,
Шушы җирнең суын эчкәнмен.

Түшемә дә сәхрә-кырлар керә,
Башакларны җилдә уйнатам.
Оран салып, авыл әтәчләре
Иртә йокылардан уятты.

Авыл белән басу арасында
Сукмак-юлымны суытмадым.
Яуды башка бозлы яңгырлары,
Давыл купса да, сынатмадым.

## *Юллар дәшә*

Атар таңнар, килер язларым бар,
Киләчәккә мине эндәшә.
Гомер чикле, хәвеф-хәтәр бетми,
Теләгенә күпләр ирешә.

Юллар дәшә зәңгәр офыкларга,
Өмет шәмнәремне тергезеп.
Юанычлар, борчуларым белән,
Алларымда тора тезелеп.

Галәм киңлекләре дәшә мине,
Йолдыз илләренә гизәрмен.
Ышанасы килә үз көчемә,
Катгый сынауларга түзәрмен.

Дуслар дәшә мине хөрмәт итеп,
Барына да сәлам юлладым.
Хыял канатларым талпынганда,
Күңел хисем балкый, юандым.

## Гаделсезлек җирдә булмас

Уртак тел табалам сөйләшергә,
Ярдәм кулым әзер сузарга.
Гамьсез кешеләрне күреп яшим,
Алар өчен йөзем кызара.

Эшлекле дә, әдәпле дә кеше
Ышанычлы була, сынатмый.
Холкы, фигыле дә аның күркәм,
Бәгыреңне юкка сызлатмый.

Игелекле, олы җанлы кеше
Яшерми, чын йөзен күрсәтә.
Үчләшми дә, көнләшми дә үзе,
Тотынмый да барып күсәккә.

Намус төшенчәсен белгән кеше
Ялгышын да танып төзәтә.
Ил алдында казанышы була,
Килер уңышларны тизләтә.

Изге җанлы кешеләр күп булсын,
Гауга, талаш булмас, афәт тә.
Җирдә гаделлек гел хөкем итсә,
Кан-яшь түкмәс беркем, әлбәттә.

## Табигатьнең кодрәт көче

Тәрәзәмне ачтым, өй алдымда
Сиреньнәр дә ап-ак чәчәктә.
Яз аеның яме, хозурлыгы,
Назланамын, күпкә яшәртә.

Йомшак искән җилләр хуш ис бөрки,
Тәрәз челтәрләрен тирбәтә.
Бер юаныч, куанычлар белән,
Татлы уйлар, хисләр терелтә.

Табигатьнең кайда кодрәт көче,
Гөл-чәчәккә җирем төренде.
Бар дөньяга ходай рәхмәтле шул,
Җәннәт бакчасы күк күренде.

Ел фасылы серле йомгак төсле,
Сөйләп бирми үзе барысын.
Колагымда таныш моң авазы,
Тизләмәсен, вакыт, агышың.

Әйтерсең лә күк гөмбәзен ачты,
Изге көндә шөһрәт кичердем.
Касәләргә салып бирдең миңа,
Ширбәт итеп ләззәт эчердең.

## *Йокыга талам*

Көн дә эштән арып кайтам,
Мәшәкатем, бетмәдең.
Йокы баскач, торып кала
Авызымда икмәгем.

Белмим, тагы нәрсә бар соң
Йокыдан да татлырак?
Көне буе эшләп кайткач,
Тынып йоклыйм, катырак.

Төшемә килә дә керә
Бетмичә калган эшем.

Барысына да өлгерәм,
Кулда җитәрлек көчем.

Йолдызларга, айга менәм,
Аккошлар булып йөзәм.
Иңнәремдә канат үсә,
Ерак илләрне гизәм.

Бу чакта хаҗәтем калмый,
Килер язны тизләтәм.
Төштә үзем ялгышымны,
Язмышымны төзәтәм.

## Төрле тарафларга юл уза

Юл чатына җиткәч туктап калдым,
Җиде якка киткән юл ята.
Нигә икән шомландыра уйлар,
Ышанычым бары юата.

Максатыма ирешергә кирәк,
Кай тарафка караш төбәрмен.
Ерак сәяхәткә ялгыз чыктым,
Ихтыяр, көч җыеп түзәрмен.

Кайсы юлны монда сайларга соң,
Өметләрем бары аклансын.
Күкрәгемне болыт капламасын,
Яшен яшьнәп, давыл купмасын.

Көмеш күлләр, алтын тауларыңа
Урау юллар аша үтәрмен.
Аякларым белән җирдән атлыйм,
Күңелләрем белән күктә мин.

Бер мәсьәлә алга килеп баса,
Чишелешен ничек табарга.
Юлым кайсы сәфәремә илтер,
Төрле тарафларга тарала.

## *Кыш сулышы*

Тәрәзәмә карлы яңгыр чиртте,
Сискәндерде кинәт, шикләндем.
Соңгы көне җитте көз аеның,
Атлап чыга вакыт чикләрен.

Кыш сулышын өрер гайрәт чәчеп,
Карлар ташыр сәхрә-кырларга.
Галәм буйлап үз урынын яулар,
Белеп килә катгый карарга.

Сукмак-юлларыма карлар түшәр,
Бураннарыңны хет кичектер.
Бертуктаусыз салкын җилләр исәр,
Җилегемә үтеп өшетер.

Ак өермә шашып тузынганда,
Күңел кошым очар адашып.
Табигатьнең хөкем кануннары
Серен ачмый, булмый аңлашып.

Салкын көннәр, кышның бураннары
Сагышларга берүк күммәсен.
Күпне күрдең, йөрәк, түзәрсең бит,
Бу хәлгә дә әле күнәрсең.

# Дүртьюллыклар

* * *

Таулар горурлыгын үз итәмен,
Мин аламын чәчкә-гөл назын.
Яшәү яме, рухың, көчең кирәк,
Гомер көзләренә юл озын.

* * *

Пар атларда җилдерәсем килә,
Көмеш кыңгыраулар чыңлатып.
Яшьлек хатирәсен яңартамын,
Керфегемне яшькә чылатып.

* * *

Базар гөрли, алыш-биреш бара,
Берәү ота, берәү отыла.
Йомыркалар саткан карчыкларны
Шпаналар талап тотыла.

* * *

Адашканда берәү юл күрсәтә,
Егылганда килеп күтәрсә.
Максатка да ирешергә була,
Миннән генә тормый күп нәрсә.

* * *

Басу өсләрендә зәңгәр рәшә,
Тибрәнделәр җилләр искәндә.
Арыш башак косып өлгергән мәл,
Дулкын кага, дулый үскәндә.

* * *

Ачуларың булса, саклама син,
Аңлатырга телим күптән мин.
Тонналы йөк тартырга да риза,
Гайбәт сүзен һич тә күтәрмим.

* * *

Шом басты тирә-юнемне,
Төн кара пәрдә япты.
Бермәл шик-шөбһәм югалды,
Күк читендә таң атты.

* * *

Томан пәрдәләрен җыеп ала,
Иркен сулый сәхрә-кырларым.
Көтүченең курай моңнарына
Тургай кушты дәртле җырларын.

* * *

Киртәләр дә, тирән упкыннар да
Гомер сукмагында гел очрый.
Адым саен адәм баласыннан,
Кызганмый да, әҗәл җан сорый.

* * *

Очрашсак, сөйләр сүзләр бетми,
Алларыма үзең төшәсең.
Яннарымнан китеп, күз качырсаң,
Үтмәс пычак белән кисәсең.

* * *

Үзем йорт төзим, дисең гел,
Сөйләгәнеңне беләм.
Күргәнем юк какканыңны
Кадак та кулың белән.

* * *

Мөдир булып алганнан соң
Сөйләшми кеше белән.
Ул дөнья кендеге, имеш,
Мәшгуль үз эше белән.

* * *

Башланган эш кинәт туктап кала,
Җитәлмәдем чыгып очына.
Кемнәр әйтер, булдыксыз ир, диеп,
Күңел шомлы, җаным борчыла.

* * *

Башы күккә тигән биек таулар
Берчак җир белән тигезләнә.
Үлем килеп баскач каршысына,
Бар кеше дә бер үк тезләнә.

* * *

Дәрья сулары да тынлыклана,
Ярларына дулкын сикерми.
Бар табигать вакыт хөкемендә,
Агач яфрагы да селкенми.

* * *

Авырып ятам, кинәт чирләдем,
Мондый хәлгә ничек күнәргә?
Бер танышым хәстәрлеген күрә —
Кәфенлеген алган күмәргә.

* * *

Җилфер-җилфер искән җилләр
Чәчләреңне тарады.
Иңгә япкан шәлең кебек,
Толымнарың таралды.

* * *

Күктән төшкән сыман кыланабыз,
Без, әйтерсең, җирнең кендеге.
Тормыш кочагына алып сыный,
Ачыклана кемнең кемлеге.

## Кайгы көтмәгәндә килә

Кайгы көтмәгәндә килеп,
Башны түбән идерә.
Сырлар салып йөзләремә,
Утларында көйдерә.

Моңсулата, хәлсезләтә,
Ихтыяр көчен сыный.
Исәпләшми беркем белән,
Суыра, җаның сорый.

Мөшкел хәлгә калгач beләм,
Жаен тапмый, баш ватам.
Читлектәге тоткын кошка
Үземне тик охшатам.

Кайгы болыты каплагач,
Кояшымны, аемны,
Бер юанычтабалмыймын,
Чуалтты бар уемны.

Кайгы җиле кагып-сугып,
Бермәл ега аяктан.
Бирешмәскә дигән идем,
Күз яшь түктем ояттан.

## *Тамырыбыз — тирәндә*

Шушы җирдә, шушы туфракта ла,
Тамырыбыз ята тирәндә.
Яшәвемә көч вә куәт биреп,
Кояш карый көлеп түбәмдә.

Без яшәгән еллар алга сөйри
Гасырларның көмеш чылбырын.
Утлар алам тормыш учагыннан,
Язмыш язган миңа чын барын.

Туфрагыма җан өрүче булды,
Челтер-челтер чишмә чыңлады.
Ата-бабам изге төбәге син,
Моңнар йомгагына чорнады.

Газиз җирем, игелегeн күрәм,
Әй сихәтле, сулыйм һавасын.
Әсир итә моңы, яме белән
Туган төяк адәм баласын.

Күңелдә дәрт, кулда көч бар әле,
Гөлләр үсә, сулар сибәбез.
Туган җирдә, изге туфрагында,
Хезмәт сөеп, гомер сөрәбез.

## Дулкыннар уйный

Дулкыннар ярга кагылып,
Зеӊ-зеӊ килеп чыӊлады.
Таш кыяларга сикерә,
Белми әллә чаманы.

Ярсыган тулпар шикелле,
Дулкыннар ак күбектә.
Сихри моӊнар чыӊлатып,
Уйный гына кебек тә.

Йомгак булып бөтерелә,
Йөгерә ярга табан.
Бәргәләнә, сибелә дә,
Дулкыннар тынмый һаман.

Кояш көлде, җил басылды,
Тирә-юнь тынып калды.
Елга агышы сизелми,
Сулар да тоныкланды.

Үз язмышы дулкыннарныӊ,
Гел шулай кабатланды.

## Көзге җилләр

Агачлар яфрак коя,
Зар еламый ничек тә.
Узган юлаучылар кебек,
Җилләр килә ишеккә.

Көзге җилләр авыр сулап,
Кырлар буйлап әй йөрде.
Канатланып кошлар сыман,
Һәр тарафка йөгерде.

Сабырланмый, тынычланмый,
Җилләр җирдә аунады.
Җиз кыңгыраулар шикелле,
Сары яфрак чыңлады.

Караңгы төн, җилләр улый,
Яшь бала сыман елый.
Җиһандагы бар тере җан
Ышаныч, өмет юллый.

Кырыслана, усаллана,
Көзләр җиткәч, җилләр дә.
Җәйләрне юксынамы соң,
Сагышлана җилләр дә.

## Торналар чыккан юлга

Чылбырларга тезелеп очып үтә,
Күктә торналар кәрваны.
Вакыт җиткәч, юллар чакыра микән,
Никтер борылып карамады.

Сез китәсез бит, кошкайларым,
Туган җирегезне калдырып.
Зәңгәр юллар салып киткән якка,
Күзләремне карыйм талдырып.

Бакчаларда кошлар моңы тынды,
Сукмакларым калды бушанып.

Чит җирләрдә сагыну хисе арта,
Кайтырсыз бит, калам ышанып.

Нәселегез белән ирекле зат,
Иңегездә көчле канат бар.
Ник китәсез, моңсуланып калам,
Сезнең өчен әллә дөнья тар?

Табигатьтә бөтен җан иясе
Гел үзенә ясый ишарә.
Йөрәк өзгеч өн-авазлар салып,
Ялгыз торна оча, бичара.

## *Вакытым юк*

Көне-төне бергә тоташ ага,
Туктап тормый, вакыт ашыга.
Мең елдан соң ниләр булыр икән,
Торып бассаң кабер ташына.

Җир күкрәге иркен — җыя барсын,
Исем, шәрифен дә сорамый.
Кешеләрне үлем тез чүктерә,
Дәрәҗәгә, данга карамый.

Йөз яшәрдәй хәтәр кылансак та,
Фанилыгын белми дөньяның,
Агач яфракларын койган мәлне,
Моңсуланып озак уйландым.

Күзен йомды таңда карт ветеран,
Кемнәр китәр тагын иртәгә?
Әҗәл эзләп килеп җитәр әле,
Вакытым юк аны көтәргә...

## Уйландыра төрлесен

Матур чагы узды гомеремнең,
Ашкындырмый килгән язлар да,
Вакытында сөеп, сөелдем дә,
Күз төшермим хәзер кызларга.

Гүзәл яшьлек төшкә генә керә,
Күкрәү сала җанга, чаңы бар.
Табигать тә кешеләргә охшый,
Сокландырган ямьле чагы бар.

Агачларның бөреләнгән мәле,
Кыр казлары кайта еракнан.
Уятсаң да сагыну хисләремне,
Тормыш, сине һаман яратам.

Вакытымны йөз төрлегә бүләм,
Йөкләп алдым кулга ил эшен.
Еллар саны үлчәгәнен беләм
Миңа тигән гомер өлешен.
Уйландыра уйлар төрлесен.

## Туган төягә көтә

Хәбәрсезләр илгә кайта,
Югалганнар табыла.
Кылган батырлыклары да,
Һич онтылмый, таныла.

Ватан бурычын үтәде
Әфган җирендә күпләр.

Баскан туфрагы шуыша,
Чайкала анда күкләр.

Яу кырында ятып калды
Кемнәрнең газиз башы.
Легендалар булып калган,
Тезелгән кабер ташы.

Хәвефле еллар шаукымы
Гасырларга юл алыр.
Сугыш уты сүнми тагын,
Кем хәбәрсез югалыр?

Язмышына язылганы
Тормыш юлыннан үтә.
Хәбәрсез югалганнарны
Туган төяге көтә.

## Авыл тараламы?

Авыл, сине халык ташлап китә,
Киткәннәрең кире кайтмады.
Күпләрнең бит төшләренә керә,
Сагындыра туган яклары.

Юлга чакыра авыл кешеләрен,
Гел бәхетле кебек ятлар да.
Кемнәр җәяү, кемнәр машинада,
Кемнәр китә җиккән атларда.

Авыл бетә, авыл тарала шул,
Ялгыз йортлар торып, буш кала.
Хезмәт дәрте белән яшәгәчтен,
Ничә төрле эшләр башкара.

Күпләр киткәч, кире кайтмады,
Шахталарда күмер казыган.
Кайда гына алар көн күрсә дә,
Тормыш утын җирдә кабызган.

Безнең заман аямады һич тә,
Язмыш кырыслыгын танытты.
Үз авылын ташлап киткән кеше
Йорт-нигезен никтер онытты.

## Яшел сукмакларым

Яшел сукмаклардан киләм
Зәңгәр офык читенә.
Гомер йомгагым шикелле,
Әкрен генә сүтелә.

Үткәнемнән киләчәккә
Сукмаклар алып килә.
Абынмый да, егылмый да,
Кем яши белеп кенә?

Күкрәк ачып искән җилгә,
Гел алга карап барам.
Шатлыгыма, бәхетемә,
Бик якын кала арам.

Максатыма җитәлмәсәм,
Табалмасам юлымны,
Фатыйхамны бирәм аңа,
Кисәтәмен улымны.

Яшел сукмакларда калган
Адашып малай чагым.
Сәхрәләр, кырлар чакыра,
Ачкан миңа кочагын.

## Уҗымнарга карыйм

Уҗымнарым яңа күтәрелде,
Яшелләнде бөтен кыр өсте.
Игенчеләр юкка тир түкмәгән,
Максатына, димәк, иреште.

Орлыкларым шытармы, дигән уй,
Башларымнан китеп тормады.
Иртә торып, сабан тургайлары
Басу өсләрендә җырлады.

Сөенеп йөрим сәхрәләргә чыксам,
Кырларымны килә карыйсым.
Кайчагында салкын җил өрсә дә,
Уҗымнарга төшә карашым.

Яңгыры да вакытында яуса,
Кояшы да бирсә җылысын,
Игеннәрем быел уңар, дигән,
Өметемнең йөртәм олысын.

## Ышанам халыкка

Сазга баткан ат шикелле,
Пычрандык, карайдык.
Бу тормышка аптырашып,
Бер-бербезгә карадык.

Ниләр булганын белмисең,
Михнәтле, авыр заман.
Җаен таба белмәдекме,
Көйләнми дөнья һаман.

Кеше кадере дә калмый,
Ачудан каным кайный.
Куштаннар, җыен түрәләр
Илем байлыгын талый.

Җир убылып төшә сыман,
Ыгы-зыгы калыкты.
Киләчәктә ниләр көтә,
Шомландыра халыкны.

Кеше язмышына кем соң
Суза пычрак кулын?
Халык азатлыгын тели,
Ышанам, табар юлын.

## Җирдә алыш бара

Кичә генә кыш хөкемен кылды,
Энҗе карлар юлга сибелде.
Ыжгырлыгы, салкын сулышы да
Бүген килеп кинәт сүрелде.

Кыш селтәде бәллүр кылычларын,
Ядро-туплар булып чәчелде.
Әйтерсең лә, күк йөзләрен телеп,
Күкрәп уза төсле яшенме?

Вакыт тота барын үз сагында,
Сәгать-минутында үзгәрде.

Кояшның да мәрхәмәте арта,
Нур балкышы тула күзләргә.

Табигатьнең йокылары качты,
Көн ямьләнә, җилләр назланды.
Моң-сагышлар арта, сулар таша,
Тансык итәм килер язларны.

Җирдә алыш бара, кыш сынала,
Сөңгеләрен төбәп мишеньгә.
Язның ярсу симфониясе дә
Зәңгәр офыклардан ишелә.

## Аз гына хаталансаң

Бер адымың җитә, ялгыш бассаң,
Үз юлыңнан читтә калырга.
Дәрәҗәне бикләп сакламыйлар,
Аннан мөмкин колак кагарга.

Бәхеткә дә үрелеп буй җитәрлек,
Баш очында гына кайгы да.
Яз белән кыш арасына ятып,
Вакыт мизгелләре аера.

Кайгы артын шатлык алыштыра,
Икесе дә килми янәшә.
Чит-ят булса, бер хәл әле тагын,
Якын дуслар кайчак көнләшә.

Озак түгел күздән төшәргә дә,
Яшәсәң дә булып зур түрә.
Бик аз гына хаталансаң да бит,
Кара чәчләреңә чал керә.

## Диңгез

Сары комын йомшак мендәр итә,
Тынып калгач, диңгез, шау-шуың.
Акчарлаклар килеп сөенче алды,
Юк, калмады бер дә ачуым.

Фирүзә нур суда көмешләнә,
Ышанычым кабат терелә.
Ят авазлар, моңнар еракдаша,
Ярдан күчә диңгез түренә.

Имин сәгатеңне күреп беләм:
Кош каурые хәтта селкенми.
Бу мизгелең хәтеремдә калды:
Яр өстенә дулкын сикерми.

Гаярь көчкә тагын юлыктыңмы,
Су өсләре кинәт тирбәлде.
Аһ-зарын да, сагышын да сөйли,
Аңлашыла дулкын телләре.

Син чөяргә килгән үгез сыман,
Хет аз гына, диңгез, сабырлан.
Усал ният белән мин килмәдем,
Матур көннәреңне сагынам.

Ай толымын синдә килеп сүтә,
Кояш тәңкәләре сибелә.
Бишегендә бала кебек йоклый,
Диңгез сулышыннан сизелә.

## Юллар эзләрсең

Тау ишелеп, сулар ярдан чыгар,
Юлларыңда очрар киртәләр.
Көтмәгәндә, уйламаган чакта,
Кайгы алып килә иртәләр.

Кемгә карап өмет багларсың соң
Кайнар яшең түккән чакларда?
Утка кереп, суга төшсәң дә гел,
Сер бирмәссең һич тә ятларга.

Йончу чагың төшләреңә кереп,
Өзгәләнер әрнеп бәгырең.
Канатларың сынган кош шикелле,
Кайгылардан җиргә бәрелдәң.

Яшәвеңнең яме калмаса да,
Өметеңне әле өзмәссең.
Киләчәккә карап табынырсың,
Максатыңа юллар эзләрсең.

## Кемнең мәхәббәт язы

Кемнең бу мәхәббәт язы,
Кемнеңдер гомер көзе.
Ел фасылы кешеләргә
Өлеш чыгара үзе.

Берәү таңда әҗәл көтә,
Йолдызлар сүнәр куктә.
Чишмә чыңлый, урман шаулый,
Вакыт кисәтеп үтә.

Кемдер көтә туй көннәрен,
Кемнәр йорт-нигез кора.
Афәткә юлыккан кеше
Башларын җиргә ора.

Кеше үз бәхетен юллый,
Уйлар диңгезен йөзә.
Газаплы кичерешкә дә
Хәле мөшкелдә түзә.

Кемнеңдер якты карашы
Күңелне нурга төрде.
Тормышта һәрчак кешенең
Кылган эшләре төрле.

## *Көтеп яшим*

Мин яшәдем гомер буе көтеп
Килер көнне, атар таңымны.
Яшәү дәрте җанда бөркет булып,
Күңел күкләрендә кагынды.

Елның дүрт фасылын көтеп алам,
Күз алладым аны төрлечә.
Назы, яме белән сокланырлык,
Йөрәк түзми моны күрмичә.

Көтеп яшим килер язларымны,
Кояш мәрхәмәте күб(е)рәк.
Тормыш бишегендә тирбәләмен,
Дөньяларым булсын түгәрәк.

Көтеп алам барын, озак, димим,
Өметләрем бушка калмасын.

Ихтыярны, көчне җыям бергә,
Сабыр канатлары талмасын.

Очрашырга, күрешергә көтәм,
Киләчәккә аны юрадым.
Ходай бирсен исән-иминлекне,
Өзелмәсен гомер юлларым.

## Ай сукмагы буйлап

Тулган ай күктә елмаеп,
Көмеш сукмаклар салды.
Сихерләде җәйге төнне,
Тирә-юнь тынып калды.

Алмагачлар ак чәчәктә,
Татлы хуш-ис таралды.
Үләннәрдә чык ялтырый,
Җир тынып сулыш алды.

Агыла, моңнар агыла
Сандугачлар телендә.
Фәрештәләр канат җәйде
Кадерле, изге төндә.

Ләззәт алам, шөһрәтләнәм
Айның тоныл нурына.
Кызлар кебек көлеп тора,
Килгән өем турына.

Ай сукмагы буйлап йөрим,
Хыялларга бирелеп.
Тоныл су шикелле бу төн,
Дөнья тора күренеп,
Чәчәкләргә төренеп.

## Торналар тавышы

Торналар авыл өстеннән
Очтылар озак урап.
Агач яфракларын коя,
Уйланып торам карап.

Кошлар хушлаша торгандыр
Урманнар, кырлар белән.
Әллә җәйләр ямен алып,
Китәсез ерак, беләм.

Торналар тавышы күкне
Яшен төсле камчылый.
Туган җирдән киткән чакта
Алар бар да зар елый.

Табигать хөкем кылганмы,
Юктыр башка чаралар.
Күз күреме җитми кала,
Ераклаша аралар.

Моңсуланып тал-тирәкләр,
Җилләргә башын иде.
Торналарның өн-авазы
Ук булып җанга тиде.

## Урам матурлана

Кемнәр бурап яңа йорт тергезгән,
Мин сокланып кайтам урамнан.
Туйлар уза, машиналар үтә,
Ефәк тасмаларга уралган.

Арлы-бирле төрле кеше йөри,
Иртә таңнан шау-шу башлана.
Пар аттагы җиз кыңгырау кебек,
Чыңлап куя урам ташлары.

Урам чаты зур сәхнәгә охшый,
Төн пәрдәсе иртән ачыла.
Скрипка кылын чиртәм кебек,
Аяк баскач урам ташына.

Берәү әле сменадан кайта,
Кемнәр яңа эшкә ашыга.
Тирә-юньдә өн-авазлар тынмый,
Көчле аккорд бергә кушыла.

Таш өстендә уелып эзләр кала,
Көнгә, белмим, ничә урадым.
Матурлана, үсә, зурая ул,
Үз язмышы һәрбер урамның.

## *Кайда әниләрнең яшь чагы?*

Безнең әниләр дә кыз чагында
Чигү чиккән, җебен эрләгән.
Алар тәрәзәсен кемнәр чирткән,
Юкка гына этләр өрмәгән.

Йөзләрендә балкып нур уйнаган,
Күзләренә серле моң тулган.
Тик аларга кемдер гашыйк булган,
Алар өчен йолдыз атылган.

Иңнәренә төшкән чәч толымы,
Кигән киемнәре килешә.

Хыяллары чынга ашкан мәле,
Теләгенә күпләр ирешә.

Күзне ачып йомган чаклы гына,
Яшьлек еллары да тиз үтә.
Тормыш көйле, чынга ашты исә,
Гомер агышларын тизләтә.

Матурлык та, көч тә чикле — бар да,
Эзләп алалмыйсың үткәнне.
Сизелми дә, картлык килеп җитә,
Әниләрне, алдый күпләрне.

## *Ашыкмагыз әле*

Бишегемдә чакта күзаллыйлар:
Рәтле кеше, имеш, чыгармы?
Аткарырмы, килсә авырлыкны,
Җитәрлекме, диләр, чыдамы?

Кылсалар да алдан күрәзәлек,
Төгәл багланмый ул ерактан.
Еллар аша күп сынаулар үттем,
Туган илем, сине яраттым.

Шөгылем бар — бетмәс бәхет биргән,
Ике кулга алам бер эшне.
Хезмәт җимешемнең мул уңышы,
Хыялларым чынга иреште.

Мәхәббәттә күп сыналган кеше,
Үзем сөйдем, үзем сөелдем.
Барысы да уйлаганча булды,
Егетләрчә ихлас сөендем.

Чын дусларны авыр чакта белдем,
Тормыш йөген бергә күтәрдек.
Ил алдында, ватан каршында да
Йөзем якты, сүзем үтәрлек.

Гомер буе гел сыналып киләм,
Яшәү максатымны сорыйлар.
Ашыкмагыз әле, вакыт җитәр,
Чебешне дә көзен саныйлар.

## *Кеше кеpә бәхәскә*

Күккә ашкан биек таулар чүгә,
Дәрья суы бора агышын.
Ерак гасырларга алып китә
Без яшәгән еллар тавышын.

Ташлар чатный, тимер эреп ага,
Әверелә берчак туфракка.
Сәгатен дә соңламыйча коя,
Агачларда калмый яфрак та.

Мәңгелеккә җирдә урын бармы,
Без табынган дөнья фанимы?
Барысын да олы мишень итеп,
Бер-бер артлы еллар саныймы?

Узган гомер җилгә очкан сыман,
Чакырып алалмыйсың кирегә.
Якты төсләр, матур бизәкләр дә
Соңгы чиктә төссез күренә.

Вакыт күз алдында тота барын,
Читтә калмый аннан шәхес тә.

Үз дәвере даһиларын таба,
Кеше керә кайчак бәхәскә.

## *Кыр казлары китә*

Кыйгак-кыйгак кыр казлары оча,
Зәңгәр күк өстендә югары.
Юлларыгыз гына уң булсын, дип,
Күрше карчык бәхет юрады.

Ерак якка китәсез дәмени,
Канатыгыз берүк талмасын.
Каршы искән җилләр тынып калсын,
Юлыгызда болыт таралсын.

Офыкларга җитеп күмелгәнче,
Күрше карчык күзли казларны.
Моңсулыгы чыккан йөзләренә,
Узган көннәренме кызганды.

Туган илгә кайтыр кошлар кире,
Күрер өчен кем дә борчыла.
Күрше карчык өнсез торып калды,
Чыгалмады уйлар очына.

Җәйләр ямен алып китә сыман,
Кыр казлары барын ияртеп.
Утлы ялкын йөрәк аша уза,
Йөрәк-җанны шулчак көйрәтеп.

## Юлларда гомер уза

Арба тәгәрмәче сыман,
Алга тәгәри еллар.
Киләчәккә чакырып тора
Бормалы озын юллар.

Юлларым сүтелеп кала,
Кемнәр чыкты очына?
Зәңгәр капкалар шикелле,
Офыкларым ачыла.

Елларым белән юлларым
Бергә үрелеп бара.
Кеше гомере санаулы,
Ерак шул барыр ара.

Җилләр исә, сулар ага,
Йөрәк майлары сыза.
Күренми дә, сизелми дә,
Юлларда гомер уза.

## Моң алам

Болын сукмагыннан чыклар ярып,
Керфек сирпим гөлләр таҗына.
Кәефләнеп, мин хушланып кайтам,
Җан азыгы кирәк аз гына.

Таулар горурлыгы күңелемдә,
Чишмәләрнең алам сафлыгын.
Туган җирем, туфрагыңда синең
Минем язмыш, минем шатлыгым.

Гашыйк итә күкләр зәңгәрлеге,
Җитез җилләр хуш ис тарата.
Күл камышы бии ярларында,
Сызылып кына сихри таң ата.

Күңелемә бетмәс гүзәллекне
Энҗеләр күк итеп җыясың.
Барысы да кешегә бит кирәк,
Ай-йолдызың булсын, кояшың.

Көн кояшлы торса, төнен айлы,
Үкенечле түгел хаҗәтем.
Дөнья сукыр тиенгә дә тормас,
Табалмасаң тормыш ләззәтен.

Күз карашым еракларга төшә,
Үз җиремдә шөһрәт табалам.
Хисләремне назлап уятырлык,
Йөрәгемә тынмас моң алам.

## Карлыгачлар оя кора

Җилкендерә, ашкындыра җанны,
Гөрләп аккан язгы ташулар.
Ком-ташларны авызында ташып,
Карлыгачлар оя ясыйлар.

Фидакарьлек, зур тырышлык сорый,
Җиңел түгел нигез корганга.
Йорт җиткереп йөргән чакта кеше
Башын сала кайчак урманга.

Кара тирне түккән табышка да
Эче пошып, мәнсез үч итә.

Көнләшмичә, шикләнмичә һич тә,
Сезнең нәсел бала үрчетә.

Һәр яз саен яңа оя корып,
Карлыгачлар шатлык кичерә.
Йомыркада каз бәбкәсе кебек,
Агачларда бөре тишелә.

Кеше белән кошлар арасында
Уртаклык юк, диеп ялгышма.
Күге аяз, көне имин булсын,
Килеп терәлә шул язмышка.

Кояш нурларында иркәләнеп,
Карлыгачлар очып уйнады.
Мин кызыгып, иләсләнеп карыйм,
Күккә чөям татлы уйларны.

## Унҗиденче язың

Унҗиде яшеңне тутырганда,
Каршыладың көлеп языңны.
Көндәлегең ята өстәлеңдә,
Истәлеккә җырлар яздыңмы?

Унҗидедә кем дә дулкынлана,
Хисләр кайнарлыгын кичерә.
Таң елмая, җилләр назлап сөя,
Ширбәтле су каен эчерә.

Җир өстенә яшел чирәм шыта,
Йолдыз калка илем күгенә.
Каен кызларына тиңләшәсең,
Күлмәк тегеп туган көнеңә.

Күкрәү узды күңел түре буйлап,
Тойдың тәүге сөю ләззәтен.
Бәхет кошы итеп зарыгып көттең
Мәхәббәтнең килер сәгатен.

Сабырлана да бел вакытында,
Горур да тот башны ничек тә.
Гомер агышының бер мизгеле,
Унҗиденче язың исертә.

## *Кемгә ачу сакларга?*

Дусларым да кайчак йөз качыра,
Ятлар уза яннан кул селтәп.
Күкрәү көтеп йөрәк талпынса да,
Шатлыкларым йөри гел читләп.

Яңа көнгә керәм сагышланып,
Өметләнәм әллә гел бушка.
Газапларын күреп яшәсәм дә,
Зарланмадым бер дә тормышка.

Күк ишелеп, җирем тетрәгәчтен,
Бара торган юлым өзелде.
Ихтыяр да, көч тә кирәк булды,
Кулга алдым барыбер үземне.

Утта янып, ташу суда актым,
Әйләнмәсен йөрәк күмергә.
Торгынлык та, шәхес культы — бар д
Туры килде минем гомергә.

Кемгә хәзер ачу сакларга соң,
Акланырга җиткән вакытмы?

Тормыш сынауларын озак үтеп,
Ачыкларга кала хаклыкны.

## Диңгез ярында

Гомеремдә бер тапкыр тик
Диңгезне барып күрдем.
Соры комнарын капшадым,
Ярлары буйлап йөрдем.

Чиксез зәңгәр киңлеге дә,
Серле үзе, тирән дә.
Акчарлаклар каңгылдаша,
Оча минем тирәмдә.

Чал дулкыннар йөгерешеп,
Ярларын кага килеп.
Кояш балкый күк өстендә,
Нурларын чәчә көлеп.

Диңгез шавы кайлардан ук
Ярына урап кайта.
Җир-ана бер дә эндәшми,
Моң-зарын тыңлап ята.

Җәүһәр ташы кебек балкый,
Төсләре мәңге сүнми.
Яшермәде кешеләрдән,
Диңгез серләрен сөйли.

## *Сукмак буйлап килэм*

Без сокланган айлы төннәр булды,
Кая калды йөргән сукмаклар?
Исләреңә син дә төшерерсең,
Төшләреңә керер ул чаклар.

Юк, бәхәссез, бергә узган көннәр,
Күңелләрдә калды яктысы.
Мин дә сине, син дә мине белеп,
Гомерләрнең узган яртысы.

Мәхәббәттә бәлки уңгансыңдыр,
Язмышларны булмый белеп тә.
Теләсәк тә хәзер күрешәлмибез,
Юксынуга булмый күнеп тә.

Син дә барыбер күргән төшләреңне
Сөйлисеңдер иртән уянып.
Бер ялгызым озын сукмакларда
Мин дә йөрим озак уйланып.

## *Көз сарысы*

Йөзләремә көз сарысы чыккан,
Көзгеләргә карыйм сагышлы.
Ыгы-зыгы килеп узган көннәр,
Колагымнан китми тавышы.

Хәвефле елларга туры килдем,
Дөньягамы тудым ашыгып?
Кемгә хәзер аның кирәге бар,
Зарланмадым һич тә ачынып.

Йөгереп чыктым ачып колачымны,
Бик яшьтән үк тормыш каршына.
Хыялларым акланмыйча кала,
Мин җаваплы аның барсына.

Киләчәктә дөнья матурланыр,
Өмет итәм әле, ямьләнер.
Гел хөсетлек кылган адәмнәр дә
Йөзе белән берчак әйләнер.

Ышанасың, йөрәк, үз көченә,
Сәер хәлдә калып аңлашам.
Күп үзгәреш, мең кичереш күреп,
Гаделлекне яклап алышам.

## Авылым яме

Авылыма ямьнәр өсти
Сәхрә, урман, күле дә.
Горурланам, сокландыра,
Яшим якты көнемдә.

Сукмакларым илтә мине,
Кырлар кочагын ача.
Иген басулары шаулы,
Күңелдә хисләр таша.

Язмышыма рәхмәтлемен,
Җир, суларга да юмарт.
Гомер йомгагын сүтәмен,
Шатлык, бәхетләр юллап.

Авылым ямьле гөл бакчасы,
Мең төрле бизәкләре.

Йөз яшәп тә күңел туймас,
Вакытны тизләтмәле.

Авыл күрке хушландыра,
Җырларыма кертәмен.
Нәсел-ыру тамыры синдә,
Төшмәгәнмен күктән мин.

## Югалтуларым күп булды

Зәңгәр күлнең аккошлары очты,
Сары көйде җирнең гөлләре.
Иртәгәсен соңгы юлга чыгар
Бу дөньяның әллә кемнәре.

Табигать тә, кешеләр дә төрле,
Бер мизгелдә бар да үзгәрә.
Җылы язлар, салкын кышлары да
Төсмерләнеп кала күзләрдә.

Кара җирне ап-ак карлар күмә,
Ак өстенә кара тап төшә.
Кайгылар да, шатлыклар да була,
Икесе дә түгел бер төстә.

Яшен уты кебек сүнәрбез ич,
Ике яшәргә дип килмәдек.
Чибәрлек тә, көч тә бетә икән,
Яшь чагында уйлый белмәдек.

Озатканда якты көннәремне,
Күзаллыймын үткән хакында.
Нидер җитми, югалтуларым күп,
Сүзсез калам юллар чатында...

## Су буенда

Җәйләр ямьле су буенда,
Сукмагы яшел келәм.
Үләндә җемелди чыклар,
Иртәсен, кичен киләм.

Көтү-көтү каз-үрдәкләр
Су өстендә тирбәлә.
Күбәләкләр уйный, оча,
Гөлләр сайлый тирәмдә.

Су юллары бормаланып,
Офыкка башын сузган.
Ерак гасырлардан калган
Сибелеп монда тузан.

Яр читендә, су чәчрәтеп,
Бер мәл килә уйныйсым.
Яшьлек дәрте, хисләр ташып,
Йөрәгемдә уянсын.

## Күптән сүнгән учаклар

Яшел болыннарда ат сакладым,
Сүнгән анда янган учаклар.
Урам буйлап яшьләр җырлап узмый,
Кая китте икән ул чаклар?

Су буеннан кызлар тезелеп кайта,
Кайтыр сыман егет чагым да.
Гомер язларымны күңел эзли,
Яшьлек хатирәсен сагына.

Эфир дулкыннары аша килә
Башка җырлар, башка авазлар.
Гомер уртасына бер җиткәчтен,
Җаным тели тормышта назлар.

Төн җиткәчтен урамнарга чыгам,
Гармун тавышларын ишетим.
Яшь чагыма мине алып кайтсын,
Могҗизалар туар, хис итим.

## Таулар гына очрашмый

Тау белән тау гына очрашмый ул,
Кеше белән кеше күрешә.
Максат куеп җирдә яшәгәндә,
Теләгенә күпләр ирешә.

Максатыма мин дә ирешермен,
Хат-хәбәрләр сиңа юлладым.
Гел керәсең, төшләремдә күрәм,
Очрашырга булсын, юрадым.

Яшьлек еллары да ерак калды,
Адаштырды тормыш сукмагы.
Истән чыкмый бергә узган көннәр,
Якты хатирәләр сакланды.

Еллар саны, вакыт яңгыры да
Сүндермәде сөю утларын.
Язмышыммы, әллә күрәчәкме,
Акланырга сәбәп тапмадым.

Утлар, сулар кичеп сиңа барам,
Очрашырга иде теләгем.

Көрешмичә, сөйләшмичә калсам,
Тынычланмас ярсу йөрәгем.

## Көнлисең

Януымны, көюемне
Аңламыйсың, белмисең.
Башка сөяр кешем юк ич,
Һаман да син көнлисең.

Мәхәббәт учагын саклыйм,
Сүндермичә гомергә.
Тормыш юлыбыз үрелеп,
Узса икән гел бергә.

Чәчәкләр бүләк итәмен
Синең туган көнеңә.
Язмыш төрлечә бит сыный,
Алдан барын кем белә?

Яшьлек назы назландыра,
Кадерле сәгатьләре.
Рәнҗүләргә, үпкәләргә
Юк бер дә сәбәпләре.

Кояшым да, аем да син,
Исән булыйк, югалтмам.
Чәч толымнарыңнан сөеп,
Иркәлимен, юатам.

## Шөгыль таптым

Кышын чана сөйрәп чыктым,
Җәй көнен арба тарттым.
Айлар, көннәр сизелмәде,
Үземә шөгыль таптым.

Йөгерсем дә, егылсам да,
Күрдем әллә кызыкка.
Урамда малайлар белән
Гаугалаштык кызып та.

Агач башларына үрлим,
Иң биекләрен юллап.
Канатсам да борынымны,
Өйгә кайтмадым елап.

Агайның усал карашы
Куркыта мине, качтым.
Шуклыгым өчен күп чакта
Почмакка үрә бастым.

Малай чактан җигелдем ич,
Арбага, я чанага.
Ир-егет булам, дигәчтен,
Күрмим башка чара да,
Туры килә чамага.

## Расланмады төшләре

Бакчасында чия чәчәк аткан,
Өй аллары яшел чирәмле.
Каз бәбкәсе куып чирәменә,
Күрше карчык быел йөрмәде.

Челтәр пәрдәләре тартылмаган,
Тәрәзәсен чиртте җилләрме?
Тал бөресе борынланган чакта,
Авылдашлар аны җирләде.

Йорты ятим, җыйган малы калды,
Фани, димәде ул дөньяны.
Тормыш мәшәкатен татыса да,
Сук(ы)ранмый, авыр тоймады.

Тугайларда җәен печән чапты,
Карлыганнар җыеп киптерде.
Газиз улларының язган хатын
Укытырга бик еш китерде.

Төрле хатта төрле адресы —
Махачкала, берсе Дүшәмбе.
Теләкләре кабул булмагандыр,
Рас килми күргән төшләре.

Соңгы сәгатендә өметләнде,
Ана йөрәге түзем, чыдамлы.
Җаны суырылганда күкрәгеннән,
Улларын ул бары сорады.

Газизләрен карчык күрәлмәде,
Аянычлы таңнар, иртәләр.
Җыйган малын ятлар саталар да,
Йорт нигезен аның сүтәләр.

## Чишмә

Таулар куенында ургый чишмә,
Сокландыра моңлы тавышына.
Карурманнар, сәхрә, кырлар аша
Диңгезләргә барып кушыла.

Тасма булып сукмак сузылып ята,
Таллар үскән чишмә янына.
Таң нурларын сибә тирә-юньгә,
Сандугачлар куна талына.

Офыкларга моңлы жыр тарала,
Хисләр таша, канат кагына.
Ләззәтләнеп шифа суын эчәм,
Яшәү ямен өсти тагын да.

Сукмакларны чишмә очраштыра,
Якты хатирәләр саклана.
Чишмә моңсулыгын тойганым юк,
Табигатьтә һәрчак тантана.

## Йөгереп уза көннәр

Йөгереп кенә көннәр үтеп китә,
Еллар кочагына ташлана.
Төннәрен дә йокым белән сизмим,
Шаулы иртә тагын башлана.

Галәм йөзә вакыт дәрьясында,
Бер мизгелгә хәтта туктамый.
Күзгә чалынса да, төрле төстә,
Кеше кулы капшап тоталмый.

Ямьле җәй аеның хет бер көнен
Тотып булса икән тезгендә.
Йөзләремә чыгар шатлыкларым,
Якты нуры балкыр күземдә.

Бер-бер артлы көннәр өзелеп кала,
Әйтерсең лә яфрак коела.
Тормыштагы булган куаныч хәл
Төш шикелле генә тоела.

Мәңгелектер — вакыт кануннары,
Минуты да аның кичекми.
Гомер уза, сизмичә дә калам,
Моң-зарымны никтер ишетми.

## Кызлар тавы

Тау буена кызлар килә,
Уйныйлар әйлән-бәйлән.
Җәй җиткәч бергә җыелып,
Күңел ачалар, беләм.

Тау ягы җырлы була гел,
Колакта тора чыңлап.
Күңелле бәйрәм кичәсен
Хәтерләтә бу чынлап.

Җырлый да алар, бии дә,
Күгәрчендәй гөрләшә.
Тауда үскән назлы гөлгә
Бар да монда тиңләшә.

Сукмаклар сузылып ята,
Үләннәр арасында.

Читтән карап күз төшерәм
Кызларның барысына.

Кызлар тавы эндәшә гел,
Офыкларга кул болгап.
Сокланып, дәртләнеп кайтам,
Аһәңле җырлар тыңлап.

## *Вокзал тулы халык*

Ташкент вокзалында халык тулы,
Бу кешеләр кая ашыга?
Кояш көлә, бөтен һава кызган,
Басып булмый урам ташына.

Төрле халык, төрле яктан килгән,
Арлы-бирле килеп сугыла.
Кошлар сыман очып кайтыр идем,
Туган җирне күңел сагына.

Сәфәр кылучылар поезд көтә,
Чемоданын тоткан кулына.
Кулбашыма салып йомшак кулын,
Кемдер килеп миңа кагыла.

Таныш та ул, таныш түгел сыман,
Күзгә карап шунда таныштык.
Яшьлек дустым, авылдашым икән,
Ничә еллар узгач, табыштык.

Ул Кавказга ял итәргә китә,
Мин Ташкенттан кайтам авылга.
Онытмаган яшь чакларны, сөйли,
Узган көннәр кайтты аңыма.

Авылдашлар, дуслар бу дөньяның
Төрле почмагына таралган.
Җир читенә барып җитсәгез дә,
Барыгызны эзләп табалам.

## Бәхәсләшмик әле

Кызып-кызып бәхәс кузгатабыз,
Вак мәсьәлә икән, зурламыйк.
Яшәү безгә бик җиңелдән булмас,
Бу тормышны әле хурламыйк.

Сокландырып алсу таңнар ата,
Якты көнне күреп назланам.
Кемгә генә шатлык килмәгән дә,
Кемнән генә кайгы узмаган.

Куанычлар табып юанамын,
Тетрәп-тетрәп йөрәк янмасын.
Каргыш белән кан-яшьләре түгеп,
Күпләр китте сүгеп дөньясын.

Горурлыкта, мескенлектә түгел,
Кызганмыймын тормыш ятимен.
Без зарланмый яши белик, диеп,
Җиде ят булса да, әйтермен.

## Авылның үз матурлыгы

Авылның бар матурлыгы,
Урамы яшел үлән.
Тирә-юньдә урман-кырлар,
Гомергә күреп беләм.

Таулары бар, чишмәләре,
Җаныма куәт биргән.
Иген үстереп яшәгән,
Бабайлар дөнья күргән.

Авылның бар бетмәс яме,
Гөл бакчалы өйләре.
Урамга йөгереп чыккан
Тавыклар җыр көйләде.

Атлар кешни, этләр өрә,
Ничә төрле өн-аваз.
Зәңгәр рәшәләр тирбәлә,
Күк йөзе тора аяз.

Әкрен генә ага сыман,
Монда тормыш агышы.
Авыл өстендә ишетелә
Каз-үрдәкләр тавышы.

## *Күреп сөйләшәсе килә*

Гөл үстерәм, суларымны сибәм,
Читләп узмадым кабереңне.
Исән чакта сирәк очраштыкмы,
Белмәдек әллә кадереңне?

Бер күрешеп сөйләшәсе килә,
Утырырга иде чәй эчеп.
Моңсуланып, сагышланып йөрим,
Йөрәк куя кинәт чән(е)чеп.

И, гомерләр нигә кыска икән,
Сизелми дә кала үткәне.

Исәпләшми әҗәл беркем белән,
Җир куенына алды күпләрне.

Кызганычлы, үкенечле була,
Кешеләрне үлем сагалый.
Кемнәр генә өметләр багламый,
Йөз яшәргә бар да чамалый.

Юксынганда төшләремә кердең,
Ятим калды дөнья синнән соң.
Уңганлыгың, әдәплегең дә бар,
Матур сыйфатларны җыйгансың.

## Ташу сулар ага

Елга ярларыннан шашып чыкты,
Ярсып ага язгы ташулар.
Үзәннәрне, су буйларын биләп,
Тынлыкларны куа шау-шулар.

Сулар ургый, бозлар актарыла,
Дулкыннар да чәчте күбеген.
Авыр тойгылардан аз булса да
Бушаныргa тели күңелем.

Әрнүемне, борчуларны — барын
Ташу суларына саламын.
Канатланып, күкрәп каршылаган,
Узган язларымны саныймын.

Кимсенүләр, вакланулар бетми,
Агып китсен күңел бозларым.
Заманасы нинди чуарланган,
Миңа җитми тормыш назларың.

Таулар булып дулкын килгән чакта,
Арта тәсле бары ярсуым.
Җирдә булган бөтен хәсрәтләрне
Алып китсен юып кар суың.

## *Җир-анам яңгыр көтте*

Күк өстендә кара болыт
Актарыла, чайкала.
Өй алдында каеннарны
Йолкып алмый чак кына.

Диңгез сыман шаулап тора,
Актарыла болытлар.
Тынып калды сайрар кошлар,
Мөшкел хәлдә, боеклар.

Җилләр ярсу, ашкынулы,
Дымсу һава китерде.
Өнсез калып калтырана,
Яфрак, үлән бертөрле.

Көмеш яңгыр бөртекләрен
Җир өстенә сипмәде.
Яшен камчысын күрсәтте,
Бер мизгелдә чикләнде.

Табигать көйсез кылана,
Болытлар яумый үтте.
Җир-анам сабыр һаман да,
Мәрхәмәт күктән көтте.

## Йөрәктә саклыйм

Йөрәгем кыңгырау сыман,
Чаң кага, оран сала.
Яшәү хакына талпына,
Сызлана белеп чама.

Үлән генә калтырасын,
Йөрәк жу итеп китә.
Җиһанда нәрсә булмас соң,
Карашым кала күктә.

Көчсезлегем сәбәпчеме,
Бит очларым кызара.
Әйтерсең лә йөрәгемә
Яшен ташы казала.

Мине читләп узганы юк
Яңгыры, бозы, җиле.
Хәвеф-хәтәр янап тора
Яшәгән, йөргән җирне.

Битараф булып калалмыйм,
Барын да кабул итәм.
Күк җисемен, җирем гамен
Йөрәктә саклап йөртәм.

## Күк пәрдәләрен ачты

Карлар эреп, сулар ташыган чак,
Мәрхәмәте арта кояшның.
Табигатьнең җанлы, уяу мәле,
Сәхрә-кырга төшә карашым.

Агачларда бөре күзен ачты,
Җирдә яшел үлән калыкты.
Гаме, яме, назы белән килеп,
Яз көннәре үзен танытты.

Өй алдында казлар каңгылдаша,
Кошлар кора бар да оясын.
Бу гүзәллек, матур күренешне
Вакыт яңгырлары юмасын.

Тамырланган җирдә гөл-чәчкәләр,
Күк йөзләре балкып ачыла.
Туй күлмәге киялмәгән кызлар
Каеннарга карап борчыла.

Сулышларым җиңеләеп китте,
Язда тойдым сихри көч барын.
Офыкларда күкрәү авазы бар,
Күк бозлары эри кышларның.

## *Хөкемеңне сизеп килəм*

Табигать бик юмарт кешеләргә,
Барысын да үзе өләшә.
Кемне батыр, кемне матур итә,
Кемнәр очкан кошка тиңләшә.

Мин мәхрүм түгел, кимсенмәдем,
Сүз китермәм хезмәт эшемә.
Яшәгәндә көч тә, ихтыяр да,
Тырышлык та кирәк кешегә.

Җырга-моңга гашыйк булып яшим,
Аерылмадым аннан чак кына.

Иңнәремә пар канатлар куеп,
Киләчәгем мине чакыра.

Берчак бетә матурлык та, көч тә,
Дөнья фанилыгын беләмен.
Вакыт үлчәвендә — җан иясе,
Хөкемеңне сизеп киләмен.

## Җаным җыр теле

Тол хатыннар зарын ишетәмен,
Ятимнәрнең күрәм күз яшен.
Язмыш кыйный адәм балаларын,
Җәберенә ничек түзәсең?

Башны ташка орып буламы соң,
Уйлар дәрьясына төшкәндә?
Сугыш афәте дә, ачлыгы да
Читләп үтми безне үскәндә.

Кимсетелеп, үги бала төсле,
Шикләнделәр, куркып шәүләмә,
Кисәттеләр кайчак усал гына,
Күп сөйләмә, энем, шаулама.

Чәнчү ала йөрәгемне чемтеп,
Учларыма кысып тотамын.
Ятлар белми, серләремә керми,
Кайгы-хәсрәтемне йотамын.

Зарланмаска, кайгырмаска ничек,
Күреп, белеп агын-карасын.
Җаным теле бер моң, аһәңле җыр,
Төзәтергә күңел ярасын.

## Яшәү серләрен саклый

Җиһан түрендә ай-кояш
Сүнмичә мәңге балкый.
Назы, нуры, яме бетми,
Яшәү серләрен саклый.

Чык бөртекләре ялтырап,
Үлән өстенә төшә.
Татлы булып, алсуланып,
Җир җиләкләре пешә.

Болытлар ага туктаусыз,
Уйный яшеннәр яшьнәп.
Сәгате, минуты чикле,
Үзенчә кала яшәп.

Табигатьнең үз шөгыле,
Вакыты, сәгате бар.
Ничә төрлегә керсә дә,
Куәтле, сәләте бар.

## Кышкы урман

Кышкы урман уйга чумып калган,
Агачларның төбен кар баскан.
Сайрар кошларыңны озаткансың,
Юксындырып тәүге караштан.

Моң эчендә калган урман тынып,
Ак йолдызлар җиргә сибелгән.
Нур агыла ерак галәмнәрдән,
Кар өстенә челтәр чигелгән.

Сукмак өсләрендә эзләр кала,
Озын булып төшкән шәүләләр.
Каен чукларына бәсләр каткан,
Урман агачлары шәрәләр.

Күзләремә тулган яктылык бар,
Көмеш нурлар сибә балкышын.
Җаным сихерләнеп, илһамланып,
Урманнарда йөрим мин кышын.

## Ялгызлыгым кисәтә

Ялгызлыгым гел кисәтә,
Иртәсен дә, кичен дә.
Җаныма тынгы бирмәде,
Хәтта күргән төшем дә.

Гомер буе ялгызлыкның
Газабын шул кичерәм.
Юксындыра җан дусларым,
Һәрчак искә төшерәм.

Дөнья куйдылар күп дуслар,
Аяныч хәл, нишләрмен,
Ятим калган малай кебек,
Моңсулата хисләрем.

Кемнәр уртаклар кайгымны,
Серемне кемгә сөйлим?
Язмыш кулыннан ычкынып
Күптән китәргә телим.

Ялгызлык яралар сала,
Йөрәгемне сызлатып.

Соңгы юлга киткән чакта
Кемнәр калыр озатып?

## Җәйләр ямьле

Җәй аеның ямьле чагы,
Алсу таңнар балкышы.
Тугайларны җанландыра
Яшел яфрак алкышы.

Үләннәрдә чык җемелди,
Уйный кояш нурлары.
Тау астында ургып ага
Чылтыр чишмә сулары.

Чәчәктән чәчәккә куна,
Очып йөри күбәләк.
Кояшлы җәйнең көннәре
Сокландыралар күбрәк.

Җирдә гөлләр хушландыра,
Назлы күлләр камышы.
Ишетелә кыр өстендә
Дәртле тургай тавышы.

Күзаллыймын җәйләр төсен,
Үләннәр яшел келәм.
Сәхрә-кырларда бушанам,
Шөһрәт алырга киләм.

## Булдыксызга санама

Әни, бәгърем, миңа рәнҗемәче,
Булдыксызга әле санама.
Тормыш бизмәнендә үлчәп тора,
Гомер буе ирләр сынала.

Кызган ташка басып йөргән төсле,
Үрсәләнәм, пешәм, көйрәдем.
Табышларым бар да үземнеке,
Тапмаган чак була, көймәдем.

Үкенмәдем бер дә туганыма,
Баскан җирдә утлар чәчрәттем.
Хезмәт җимешемне җыйган чакта,
Күңел кырларымны яшәрттем.

Урап узмыйм яшәү кануннарын,
Үчләшмәдем, таш та атмадым.
Мине күрсәтмәсләр бармак төртеп,
Намусым саф көе сакладым.

Үз тапканым өлешемә чыккан,
Кулдан тотып, бирми куйдылар.
Әти салган иске йортта яшим,
Шәп егетләр сарай кордылар.

## Давыл ачты тәрәзәмне

Давыл килеп тәрәзәмне ачты,
Челтәр пәрдәләрен җил бәрде.
Тополь агачына яшен тиде,
Җәйләремнең ямен җибәрде.

Салкын кырау тиде чәчкәләргә,
Җир, назыңны тагын югалтам.
Чара табалмадым, нишләргә соң,
Күңелемне ничек юатам?

Җәйләремне көтеп алдым да соң,
Татлы хыялларга бирелеп.
Кургаш болытларны күктә күреп,
Офыкларга карыйм үрелеп.

Әй, табигать, синең хөкемеңә,
Ышандырдың мине көчеңә.
Хәзинәң күп, гүзәлсең дә үзең,
Мәрхәмәтең булсын кешегә.

## Төрле чак була

Моңсуланган вакыт та бар,
Елмайган чак та була.
Аһәңле моң тавышына
Күңелем кинәт тула.

Дәрья суыдай чайкала,
Хисләрем түгелмәсен.
Килер көннәремне көтәм,
Өметем, бөредәсең.

Сүнмәс уты бар күңелнең,
Эремәс бозлары да.
Шау чәчәкле җәйләре дә,
Сагышлы көзләре дә.

Уйланам да, елмаям да,
Бу йөрәк түземле дә.

Йөрәгемә сыеп бетә
Елның дүрт мизгеле дә.

## Үткән белән арам өзелми

Үткән белән арам өзелмәде,
Күргән-белгән керә төшемә.
Явызлыкмы, әллә изгелекме,
Кайсы тиде икән кешегә?

Күзне ачам иртән йокылардан,
Уйларымда калам озакка.
Шикләнү дә, икеләнү дә бар,
Таңнар көлеп көнгә озата.

Гадел юлда йөргәч әйтәләмен,
Горурланып җиде ятка да:
Гамьсезлекне, көнчеллекне тойдым
Бинахакка утлар йотканда.

Бер кыюсыз малай төсле көлеп,
Ихлас юк-барга да ышанам.
Бер син генә түгел таш ыргыткан,
Бер ул гынамы соң үч алган?

Чәчләремә сибелеп ак төште,
Кайгылар да килде башыма.
Елмайсам да, еласам да барыбер,
Мин җавабын тотам барсына.

Үз хәлемә, үз көчемә кайтам,
Онытмыйча алам исәпкә.
Үкендереп, сискәндереп җанны,
Һәр адымым мине кисәтә.
Бу тормышлар күпне күрсәтә.

## Сөенәм

Балкып төшә офык читләренә,
Шәфәкъ алсулыгын күп күрдем.
Ай толымын сүткән зәңгәр кичтә
Танып буйларында мин йөрдем.

Чирәменә ятып хәл аламын,
Өнгә юрыйм күргән төшләрне.
Тугайларда утлап йөргән атым
Йокыларны бүлеп кешнәде.

Йөргән юллар Танып аша үтә,
Ярларына килеп суклыгам.
Йөз чагыла, мин үземне күреп,
Су өстенә карап сокланам.

Ташкыннарга тиңлим шаулы узган
Яшьлегемнең ямьле көннәрен.
Күңелемә бер моңлы җыр салды
Сандугачның татлы телләре.

Ак дулкыннар ярда йөгергәндә,
Уйнап торсын нурлар бөркелеп.
Юллар очы сиңа урап килсен,
Сөенермен тагын бер күреп.

## Чын сөю бар

Мине ташлап киттең, ялгыз итеп,
Шәльяулыгың калган онтылып.
Кулым белән йөрәгемне тотам,
Кайгыларым калды йотылып,

Агы-күге күзгә күренмәде,
Кара болыт каплый күгемне.
Кайнар яшем, дәрья суы булып,
Мендәр читләренә түгелде.

Тормыш куанычы миннән китте,
Шатлыгымны алды үзенә.
Киткән юлларыңа карап калдым,
Үзәкләрем, белсәң, өзелә.

Рәнҗетмәдем авыр сүз дә әйтеп,
Хәер, үзең белеп киткәнсең.
Тормышымның очын син чуалттың,
Авыр кичерешне көтмәдем.

Күз төбендә кайнар яшьне сөрттем,
Беркемгә дә чишмим серемне.
Мәхәббәтнең кайнарлыгын тойдым,
Шунда белдем чын бар сөюне.

## Таныш сукмакларым

Тын сукмаклар буйлап озак йөрим,
Монда калган аяк эзләрем.
Чирәм өсләрендә аунап яткан
Малай чагым кайда, эзләдем.

Гөрләп узган сабантуйлар кебек,
Яшь чакларым калган еракта.
Берни тоймый, тирәкләр дә шаулый,
Сагыш кына салып йөрәккә.

Күп гомерләр узган, тагын килеп,
Якты хатирәләр яңартам.
Таныш кырлар, таныш сукмакларым,
Газиз җирем, сине яратам.

Эзләремә басып кемнәр килер,
Сәбәпләрен аның кем белгән.
Көзләр җитәр, агач яфрак кояр,
Карлар явар, тиздән мин булмам.

## Әйтер сүзләрем калды

Телнең очында тибрәнеп,
Әйтер сүзләрем калды.
Хушлаштың да китеп бардың,
Күзләрем карап талды.

Үкенечле, сагышлы да,
Очраклы күрешү дә.
Насыйп булмый күп чагында
Теләккә ирешергә.

Уйламаган, көтмәгәндә,
Юллар килеп кисешә.
Туган җирем юксындыра,
Их, яшәргә кешечә.

Моңа җаным ризалашмый,
Моң-сагыш кайнап таша.
Гомер узгач, чит якларда
Дуслар да ераклаша.

## Гомер мизгелләре

Канатланган чаклар була,
Күк өстен айкап төшәм.
Маңгай тирләремне сөртеп,
Чишмә суларын эчәм.

Хәлсезләнгән чаклар була,
Кыл өзәрлек көч калмый.
Мондый мәлне үз башыннан
Кичергән кеше аңлый.

Хушландырган, дәртләндергән,
Бар андый сәгатьләрем,
Аңлатып, ачыклап булмый,
Төрле, күп сәбәпләрем.

Ятсам йокымда төшләнәм,
Утларда дөрләп янам.
Хөсетлек кылган кешене
Камчылап тотып ярам.

Гомер мизгелләре төрле,
Боз булып агам эреп.
Бетми дөнья хикмәтләре,
Яшимен барын күреп.

## Таныш

Боргаланып, боргаланып,
Таныш, гөрләп агасың.
Нинди хәлләргә тарыдың,
Ярга дулкын кагасың?

Агымсуларга карадым.
Уйларымны тараттың.
Яшел сукмаклардан йөрдем,
Тугай буйлап ураттың.

Йөрәкләрне җилкендерде
Монда кошлар авазы.
Күңелләргә хуш килерлек
Купшы чәчәкләр назлы.

Үзенә чакырып тора
Яшьлегем тирәкләре.
Уятасың җанда бары
Иң изге теләкләрне.

Ерактан урап киләме
Үткәннең тавышлары.
Яшь киленнәр кебек җитез
Таныпның агышлары.

## Син йоклыйсың

Мин чәчкәләр куям кабереңә,
Болыннардан җыеп китердем.
Йөрәгемдә калган юксынуым,
Сагышларым давыл күтәрде.

Син йоклыйсың җир йокысы белән,
Дөнья мәшәкате калмаган.
Белмисең дә, сизмисең дә, тормыш
Әзме кешеләрне алдаган.

Икәү печән чапкан тугайларны
Урап килдем әле яныңа.

Күксел таулар, сулар эчкән чишмәң,
Барысы да сине сагына.

Назлы чәчкә кебек гомерең синең,
Бик вакытсыз кинәт өзелде.
Искән җилгә һәрчак каршы бардың,
Кызганмадың бер дә үзеңне.

Күзаллыймын соңгы минутыңны,
Юлларыңның монда азагы.
Сабырлык бир, Ходай, көч җитәрлек,
Югалтуның чиксез газабы.

## Адаштым

Төн уртасы узып бара,
Авыл йокыга талган.
Этләр дә чинап өрмәде,
Урамнар тынып калган.

Ай-йолдызлар елмаймады,
Болыт пәрдәсен корган.
Урам читендә каеннар
Нигә шомлану тойган?

Гармун тавышы да килми,
Кошлар да канат какмый.
Күземә йокы кермәде,
Җаным да тынгы тапмый.

Күзгә чалына шәүләләр,
Таныш түгел беркемгә.
Уйлар очына чыгалмыйм,
Мин адаштым бу төндә.

## Гомер уза

Галәм киңлегендә вакыт
Бар төшкә дә кул суза.
Күзне ачып йомганчы да
Кеше гомере уза.

Аклар төшә чәчләремә,
Кигән кием дә туза.
Көннәр, төннәр алмашына,
Йөрәгем мае сыза.

Белеп тора, соңламыйча
Агач яфрагын коя.
Иртәгә нәрсә буласын
Күңелем алдан тоя.

Күктә янган йолдызларга
Күзләрем күреп кыза.
Бар гүзәллеккә сокланып,
Гомер сизелми уза.

## Көйсез булды заманасы

Кырыс тормыш кирза итек,
Чабата да кидерде.
Үгәйтелгән малай сыман,
Елатты да көлдерде.

Шулай кирәк булдымы соң,
Ачыклап та тормадык.
Кимсенмәдек, хурланмадык,
Башны җиргә ормадык.

Көйсез заман баласы без,
Алмады кочагына.
Көтелмәгән фаҗигаме,
Ник кирәк пычагыма?

Ярым шәрә хәлдә калып,
Ачлыгын күреп үстек.
Көч җитмәде, яшьли генә
Урал урманын кистек.

Аянычлы узды гомер,
Ходай каргады микән?
Безнең бәхет булгандыр бит,
Кемнәр урлады икән?

## Шагыйрь дуска

Йолдыз булып янам, дисең,
Шигърият күгендә.
Икеләнәм, шөбһәләнәм,
Шик туа күңелемдә.

Шигырь язучылар да бит
Безнең чорда күбәйде.
Карашларыбыз үзгәрде,
Офыгыбыз киңәйде.

Шигырь язып кына беркем
Дөньяны үзгәртмәде.
Юлларга маяк булмады,
Яраны төзәтмәде.

Дефицит китап укучы,
Шагыйрьләр ник зарлана?

Тукай булып тумагансың,
Башка хәзер замана.

Иҗат мәйданын юллаган
Бик күпләр килер әле.
Вакыт үлчәвен үткәчтен,
Күзебез күрер әле.

## Якты күл

Күл өстендә акчарлаклар оча,
Ак каеннар баскан ярына.
Мин малайлар кебек ихлас булып,
Гаҗәпләнеп карыйм барына.

Ак болытлар чагыла күлләрдә,
Камышлары ярда тирбәлә.
Ай коена суда кызлар сыман,
Чәч толымын сүтә төннәрдә.

Таң уята көмеш дулкыннарын,
Су буйларын сихри моң баса.
Иртән-кичтә киләм күл янына,
Моңсуланса, күңел шомланса.

Якты төсләр күзләрендә балкый,
Күкләр, җирләр бергә нурлана.
Бу гүзәл җир миллион еллар буе
Халык телләрендә җырлана.

Пар аккошлар күлгә очып төшә,
Йөрәгемә алам якыннар.
Ярларыннан ташып чыкса, күмәр
Бар дөньямны шулчак ак моңнар.

## Җилләр уйный

Шук малайлар кебек җилләр,
Кырлар буйлап йөгерде.
Чәчләремне сөеп тарый,
Биттән үбеп өлгерде.

Агачтагы бөреләргә
Бишек җырларын көйли.
Егетләр күк тирәкләргә
Сөю хакында сөйли.

Чәчләрен туздырып җилләр
Тибрәндерә кыр өстен.
Шәрә яткан тау битеннән
Алып килә җир исен.

Гөрләвекләр белән уйный,
Тизләтә агышларын.
Ишетсәм, сискәнеп куям
Сызгырган тавышларын.

## Мин үземчә яшим

Адашканда дуслар юл күрсәтте,
Егылганда килеп кул бирде.
Бу тормышта үги малай кебек,
Туккән күз яшем дә күп инде.

Яшен уты тигән имән кебек,
Калтыранам, җиргә бөгеләм.
Аҗаганнар кебек уйнап торам,
Аккан сулар сыман түгеләм.

Көчем җитми кала, зарланмадым,
И, тәгәрәп төшәм бик түбән.
Үз-үземне ачуланып әрлим,
Гарьләнсәм дә, бары мин көләм.

Өскә кинәт кара шәүлә төшә,
Дуслар аңлар, ятлар ни әйтер.
Акны кара, юкны бар дип кенә,
Гайбәтчеләр гайбәт кубәйтер.

Тормыш назларын да татып карыйм,
Афәтен дә күрдем яшьли мин.
Күкләр булып күкрәп тә алам,
Яшен булып чатнап яшьнимен,
Мин үземчә шулай яшимен.

## *Матур чак ерак калды*

Еракта калды, кайда соң
Гомернең матур чагы?
Уйландырды, моңландырды,
Төшемә керде тагы.

Яшьлек еллары тиз үтте,
Сизми дә калдым үзем.
Юксыну бар йөрәгемдә,
Сагышлы шуңа йөзем.

Уйнап тормый тәндә каным,
Басылды ярсуларым.
Дөнья хәлләре көйләнсә,
Калмас та ачуларым.

Офыкка тәгәрәп төшә,
Кояш баеган чакта.

Тетрәпләр сүнә бермәл
Дөрләп янган учак та.

Агач яфрагы өзелеп,
Искән җилгә сибелә.
Гомер йомгагы сүтелә,
Җитеп киләм чигенә.

## Дим ярында

Дим өстеннән томан пәрдәләре
Җилфер-җилфер җилдә тарала.
Яр буенда үскән тирәкләргә
Ефәк тасма булып урала.

Сайрар кошлар канатларын кагып,
Тибрәнмәде тирәк-талларда.
Тугайлардан киләм Дим ярына,
Агымсулар чыңын тыңларга.

Уелып-уелып кына сулар ага,
Ярсулары тәмам басылган.
Сары ялкын алган тирә-юньне,
Офык капкалары ачылган.

Учакларда утлар сүнгән күптән,
Җәйрәп ята тояк эзләре.
Утлап йөргән атлар кайда икән,
Күз карашым тапмый эзләде.

Дим ярында моңсу тынлык тора,
Чагу җәйләр төсен югалткан.
Күбәләк тә очмый, гөл дә үсми,
Күңел эзли, ничек юатам?

## Иялэнми авыл баласы

Шәһәр шау-шулары ялыктыра,
Тынлык эзлим, тынчу һавасы.
Ыгы-зыгы белән узган көнгә
Иялэнми авыл баласы.

Монда таш капчыкка төшкән төсле,
Тансык итәм авыл иртәсен.
Яшьлек ямен күздән кичерергә,
И, күңелем, түзми көтәсең.

Туган якка, җае гына чыксын,
Кошлар кебек кайтам ашкынып.
Дөнья мәшәкате кулны тота,
Бик еш булмый аннан ычкынып.

Туган туфрагымда тамырларым,
Өзелмәгән, аны аңладым.
Ерак яшим, җаным риза түгел,
Язмышымнан, ахры, уңмадым.

## Йолдызлар сәламе

Авылым кичләре ямьле,
Йолдызлар күген бизи.
Ерактан серле елмаеп,
Чакырып кулын изи.

Юмартлыгына ышандым,
Якты нурын өләшә.
Төндә җемелди йолдызлар,
Сәлам биреп эндәшә.

Көмеш тәңкәләрен сибә
Авылым өсләренә.
Сүнмәс бизәк булып кала,
Балкыды хисләремдә.

Зәңгәр төндә сихерләндем,
Тирә-юнем тора тын.
Йолдызларга очып менәм,
Булсын гына канатым.

## Әти, киңәшеңә мохтаҗмын

Күбәләктәй җаның очып йөри,
Хет төшемә, әти, кермисең.
Тормыш рәте, куанычы бетте,
Минем газабымны күрмисең.

Заманалар башка, үзгәрде шул,
Фәкыйрьлеккә кала күп кеше.
Намус белән исәпләшеп тормый,
Алыш-биреш итә — кем көчле.

Мохтаҗмын бик, әти, киңәшеңә,
Аптырадым, белмим — нишләргә?
Гаделсезлек хөкем сөргән чакта,
Нинди шөгыль сайлыйм яшәргә?

Мин әүлия түгел, каян белим,
Ничек күзалларга иртәгәсен?
Күк ишелеп өскә төшкән төсле,
Барлык авырлыгын күтәрәсең.

Заманасы сырхау, сызландыра,
Күземне ачып йомган саен.

Исән булсаң, әти, әйтер идең,
Тормышның табарга бер җаен.

## Хөсетлек кылучылар

Хәвеф-хәтәр читләп үтми,
Бер-бер артлы килеп тора.
Хөсетлек кылган кешеләр,
Шәп булды, дип көлеп тора.

Кара җанлы бу бәндәләр
Йөзеннән, беләм, чагыла,
Ярсып ташкан кар суы күк,
Ачы нәфрәт ташып чыга.

Гаепсезне гаеплиләр,
Мине күреп таш аталар.
Ничек итеп үчләшергә –
Гамьсез җаннар баш ваталар.

Кайчак көчем җитми кала,
Кимсенәмен, яшермәдем.
Яшен булып яшьнәсеннәр,
Беркайчан да баш бирмәдем.

## Яшәү мизгеле төш кенә

Тәрәзәмдә шәфәкъ алсулыгы,
Җирдә күрәм яфрак сарысын.
Көннәр, айлар үтеп кенә тора,
Ни булса да, йөрәк, сабырсың.

Дөнья яралгач та — шуннан бирле,
Төн белән көн килә алмашып.
Ел фасылы ничә төргә керә,
Вакыт белән булмый аңлашып.

Офык читендәге шәфәкъ нуры
Юлын таба йөрәк түренә.
Яшә — мәңгелекнең бер мизгеле,
Төш шикелле генә күренә.

Йөгерек дулкыннар кебек җитез,
Туктап тормый, кая чабасың?
Якты көнне моңсу озатып калам,
Вакыт белми һич тә чамасын.

Иртәгәсен кояш көлеп чыгар,
Юксынуым бетмәс, тик беләм:
Газаплану, югалтуым булыр,
Хушлашырмын тагын кем белән?

## Йөземне җилгә борам

Җилләр исә йөзгә бәреп,
Калтырата, өшетә,
Ыжгыруын, гаярьлеген
Бөтен галәм ишетә.

Агач башларын йолкалар
Яфракларын туздырып.
Ярсыган ерткыч шикелле,
Сызгыра җилләр сузып.

Адашкан юлаучы сыман,
Шакый килеп ишеккә.

Әллә җирне каргыймы соң,
Белмим кемгә үч итә?

Җикерсә дә, шашынса да,
Башымны җилгә борам.
Җирне күккә орган чакта,
Имән күк басып торам.

## Сер бирмәдем

Дан-дәрәҗә кирәк түгел,
Кызыкмадым юк-барга.
Сер бирмәдем, зарланмадым
Беркайчан да ятларга.

Җанымны фида кылмамын
Дөнья малына кызып.
Мең яшәр кебек кылана,
Кайчакта кеше кызык.

Җанын, тәнен сатучы бар,
Яшәп калырга теләп.
Намусымны югалтмаска —
Минем шул бөтен теләк.

Күңелем ак, йөзем якты,
Кешегә шәфкать итеп.
Сагаламас, арттан йөрмәс,
Явызлык мине көтеп.

Битараф кеше түгелмен,
Гамьсезлектә калмадым.
Күктән җиргә очып килгән
Мин фәрештә булмадым.

## Тынлык белән сөйләшәм

Эй, кешеләр, сак булыгыз,
Бар көчемә эндәшәм.
Сугыш уты кабынмасын,
Тынлык белән сөйләшәм.

Дөньялар имин чагында
Тоям җирнең сулышын.
Сөендерә, шатландыра
Куанычы тормышның.

Афәтләргә юлыкмасын,
Гомеремнең агышы.
Ил өстендә ишетелсен
Шат балалар тавышы.

Сискәнеп куям кайчакта,
Илләр тыныч булса да.
Офыкта янган шәфәкъ та
Күңелемә шом сала.

## Күп югалту күрдем

Эчкән суларымның тәмен тапмыйм,
Йокыларым качты күземнән.
Ялкын үрләп йөрәгемә капты,
Борчуларым китми йөземнән.

Юанычлар табып юанмадым,
Кая китте, йомшак җил, назың?
Сүнеп барган шәфәкъларга карап,
Юксынганга әрнеп, җыр яздым.

Күк ишелеп төшкән сыман булды,
Таулар чүкте, дөньям үзгәрде.
Куаныч та, сөенеч тә тапмыйм,
Мин бәхетле идем элгәре.

Кәефемне бозып үксеп елый
Юл буенда каен кызлары.
Агач яфракларын сипкән вакыт,
Күтеп алганым юк күзләрне.

Ачы җилләр килеп кагылалар,
Күп югалту күрдем гомеремдә.
Сары ялкын тагын кабына да
Үткән көнне күңел сагына.

## Тугры калам антыма

Әйткән сүземдә торалам,
Биргән вәгъдәм үтәлә.
Кешеләргә кылган эшем
Ышанычлы итәлә.

Намусыма тап төшмәсен,
Йөрәкне куям сакка.
Каргыш, рәнҗүләрдән куркам,
Ходаем, үзең сакла!

Юлларым адаштырмасын,
Томаланыр күзләрем.
Чын хакыйкать барын беләм,
Гадел хөкем эзләдем.

Үземә хыянәт итмим,
Туры калам антыма,

Изге гамәл кылам, дигәч,
Җаным түзми, тартыла.

## *Яшәү көче*

Тормыш бөтен авыр йөген салды,
Бар көчемне җыеп күтәрдем.
Яшен үткәргечтәй тетрәндем дә
Үз йөрәгем аша үткәрдем.

Яз башында күкрәп бөреләндем,
Яфракландым, җилдә җилләндем.
Табигатьнең юмартлыгын тойдым,
Сабырлыгын алдым җиремнең.

Кайгы күленә дә тотып салдың,
Утларыңда тетрәп яндырдың.
Язмыш сыный ялгыз имән сыман,
Давыл уртасында калдырдың.

Егылганда юатмадың сөеп,
Күк бозыңны бары имездең.
Тормыш сөеп йөрәк яраланды,
Яшәү көче мине тергезде.

## *Казлар юлы*

Төркем-төркем кыр казлары оча,
Карап калам киткән юлларын.
Ерак сәфәрләргә җыенгансыз,
Изге теләк сезгә юрадым.

Хушлашырга вакыт җиттемени,
Күнәлмимен, булмый өйрәнеп.
Миллион еллар буе кош юллары
Күк өстендә тора тирбәлеп.

Казлар коя каурыйларын, әллә
Миңа җибәрәме сәламен?
Күк йөзләре моңсуланып кала,
Ник китәсез, белмим сәбәбен.

Урман-кырлар яшеллеген җуйган,
Көзләр җитсә, арта кадере.
Җәйләр ямен алып китәсез күк,
Юксынуым телә бәгырьне.

## Җирдә яфрак тузына

Җилләр исә кай тарафтан,
Җирдә яфрак тузына.
Күшеккән агачлар карый
Кызгылт миләш кузына.

Сукмакларым алып килә
Мине урман читенә.
Өскә үрли сары ялкын,
Агачларга сикерә.

Урман-кырларын юксына,
Җыр-моңнарын ярата.
Көзләр җитсә, агачлар да
Сагышларын яңарта.

## Көз бизәге

Сызгыра егетләр сыман,
Җилләр исә еректан.
Каеннарның чәч үремен,
Толымнарын тараткан.

Көзге җилләр усаллаша,
Үләннәр яткан, чүккән.
Агач яфракларын өзеп,
Җиргә барын да сипкән.

Каен кызлары моңланып,
Тирә-юньгә җыр суза.
Күктә оча каңгылдашып,
Казлар төркеме уза.

Сискәнә чәчкә-гөлләр дә,
Карады күзләремә.
Көз сагышына тарыдым,
Чагыла йөзләремдә.

Көзнең хөкемендә кала
Аккан су, искән җил дә.
Үз көчен, төсен күрсәтә,
Бизәк төшерә җиргә.

## Яңгыр да, кар да ява

Шыбыр-шыбыр яңгыр коя,
Бер карасаң, кар ява.
Күктә адашкан болытлар,
Көйсез кылана һава.

Ялгыз калган тол хатындай,
Җир сыкраплар борчыла.
Шәрә агач күкрәкләре
Искән җилгә ачыла.

Гүзәллекне, бар сафлыкны,
Бу мизгел җуя төсен.
Табигать, бул мәрхәмәтле,
Җитәрлек синең көчең.

Сәхрә-кырлар өнсез кала,
Яфрак, үләннәр шиңгән.
Дулкыннар ярга сыена,
Судагы нурлар сүнгән.

Таллар бөгелеп үкседе,
Кемнәр икән елата?
Бу күңелсез һәм шомлы көн
Уйлар салды йөрәккә.

## *Күрми китәм аулак өйләрне*

Аулак өйгә йөрүчеләр юкмы,
Ишетмәдем тальян тавышын.
Бөтен гореф-гадәтеңне беләм,
Авыл, миңа яшьтән танышсың.

Кайда узар кичке уеннары,
Тансык миңа гармун телләре.
Җыелмады яшьләр су буена,
Юкәтауга кызлар менмәде.

Үзләренчә яшьләр ял итәдер,
Башка җирдә, ахры, типтерә.

Мин белмәгән яңа музыкага
Үзләренчә уйный, сикерә.

Авыл саклый яшьлек хатирәсен,
Сүндермичә якты учагын.
Заманында урам урап йөрдек,
Минем дә бит булды шәп чагым.

Сөенеп кайтам таныш сукмак буйлап,
Чишмәләрнең моңын тыңласам.
Күңелләрем бер бушанып кала,
Гармуннарга сузып җырласам.

Кемнәр кабат көйләп йөргәннәрдер
Мин хуп күргән, дәртле көйләрне.
Ишекләрен ачып керәлмәдем,
Күрми китәм аулак өйләрне.

## *Тәрәзәмә боз каткан*

Салкын кышның карлы төне килде,
Тәрәзәмә күксел боз каткан.
Керфегемә кунмый, күзгә керми,
Йокы тапмыйм, кая соң качкан?

Якты көнем, ташлап киттең мине,
Назларыңнан мәхрүм итәсең.
Йорт эчендә сәер тынлык тора,
Вакытларым, әкрен үтәсең.

Ялгызлыгым әллә сискәндерде,
Җилләр кактымы соң ишекне?
Мондый шомлы кичерешләр әле
Тойган булмагандыр бу тикле.

Төннең кара пәрдәсенә төренеп,
Моңсуланып карыйм күптән мин.
Салкын кышта өшеп калтыранам,
Җан җылысы җитми, көтәмен.

Таң да балкып туар, төн дә үтәр,
Җылы яз да килер кыштан соң.
Сулышларым җиңеләер төсле,
Хакыйкать барына ышансаң.

## *Кышкы төн*

Декабрьнең өрә ыжгыр җиле,
Карлар оча, карлар тузына.
Кулларымны сузып җылытамын,
Учактагы күмер кузына.

Кышның төне озын, салкын була,
Тәрәзәмә зәңгәр боз каткан.
Калтырата, тәнне күшектерә,
Ак гарасат җирне кузгаткан.

Учагыма утын өстәп торам,
Казанымда ашым кайнады.
Бер мәл дөнья тәмам тынып калды,
Кинәт тагын буран уйнады.

Мин читлектә төсле хис итәмен,
Йорт эчләре калды бушанып.
Афәтенә кеше юлыкмасын,
Кышкы төнгә булмый ышанып.

Болыт томалаган күкләремне,
Урам этләре дә өрмәде.

Яшәү шомлы, шикләндерә генә,
Башта уйлар күпкә төрләнде.

Болганчык су кебек вакыт ага,
Җан борчыла авыр чынлыкта.
Йокы тапмый, күпме җәфа чигәм,
Шомландыра хәтта тынлык та.

## Егылсам, еламадым

Мин абындым тигез юлда,
Егылдым кайчак үзем.
Сынатма, сызланма, диләр,
Ир халкы була түзем.

Егылсам да еламадым,
Чит-ятлар сөенмәсен.
Зарланмадым дусларыма,
Алар да көенмәсен.

Абынганда, егылганда,
Гаебемне эзләдем.
Тормыш бишегенә салмас,
Хөкеменә түзәрмен.

## Җырларыңны, әни, ишетәм

Сәхрәләргә чыксаң, моңга күмдең,
Җырлы-моңлы узды кичләрең.
Чишмә кебек ташып чыңлап акты,
Әни, синең кайнар хисләрең.

Кулың эшкә тисә — җыр сузасың,
Дәртең арта, илһам табасың.
Иген басуында тургайлар күк,
Бар көчеңә канат кагасың.

Тирән сулап, тирләреңне сөртеп,
Мин тап булам шундый чагыңа.
Шатлыгың да, кайгы-хәсрәтең дә
Җырларыңда, әни, чагыла.

Күңелең иркен, бар да сыйган аңа,
Урман, кырлар, яшел болыннар.
Юатасың жанны сабырлатып,
Яшәргә көч биргән моңың бар.

Кояшлымы, болытлымы көнең,
Моңсуладымы соң кич-иртәң?
Тирәктәге сайрар кошлар кебек,
Җырларыңны, әни, ишетәм.

## *Гомернең канатлы чагы*

Йокыларымда төшләнеп,
Очып мендем күкләргә.
Канатлы хисләрем мине
Бик югары күтәрә.

Галәм киңлегендә очтым,
Талганчы канатларым.
Тәвәккәллек, кыюлыкны
Үземчә кабатладым.

Гомернең канатлы чагы,
Тынып тормый аз гына.

Бу кадерле минутларым
Җырлар итеп языла.

## Дөнья гашыйк итте

Үсмер чакта таулар биек сыман,
Чиген белми аккан дәрьялар.
Юллар ята еракларга дәшеп,
Серле булып тора дөньялар.

Офыкларда сызылып таңнар ата,
Йомшак җилләр исә иркәләп.
И, бу дөнья гашыйк итте мине,
Сөю хисе килде иртәрәк.

Ак канатлар үсте иңнәремдә,
Диңгез кичтем, мендем тауларга.
Баштан төрле уйлар йөгереп уза,
Күк томаннар булып тарала.

Ерак илләр күзне кызыктыра,
Ашыктыра заман тизлеге.
Хәвеф-хафалардан арынып яшик,
Кулда булсын тормыш тезгене.

## Сәфәр чыксам

Юлдаш була, сәфәр чыксам,
Ай-йолдызым, кояшым.
Ялгызлыгым гел кисәтте,
Җанны кая куясың?

Ак каеннар юл буенда
Шәлләрен болгап кала.
Биек таулар, карурманнар
Тын гына күтеп ала.

Упкыннар кисә юлымны,
Кичүләр аша узам.
Юлаучыга юлдаш була,
Күңелдән җырлар сузам.

Юл буенда торып кала,
Сәхрә, басу, болыны.
Җилләр дә читләп үтмәде,
Миңа табан борылды.

Юлаучыга юлдаш икән,
Очкан кош, искән җил дә.
Адымнарым кыскарса да,
Көч табып атлыйм җирдә.

## Күңелемнең язы, назы бар

Бөтен галәм сыйган күңелемә,
Үз урынын алган һәммәсе.
Чиксезлекне, иркенлекне тели,
Гомеренә адәм баласы.

Күңелемнең язы, көзе дә бар,
Аяз күге, айлы төннәре.
Бар дөньяны моңнарына күмә
Чишмәләрнең көмеш телләре.

Кошлар оя кора күңелемә,
Асыл затлар нәсел үрчетә.

Җырлар туа, кош баласы итеп,
Очырам аларны кич-иртә.

## Чәчләреңне җил тарады

Җилфер-җилфер искән җилләр
Чәчләреңне тарады.
Иңгә япкан шәлең кебек,
Толымнарың таралды.

Кигән күлмәгең килешә,
Болын чәчәге төшкән.
Камышлы күл — зәңгәр күзең,
Кояш нурларын эчкән.

Сине күреп таң елмаер,
Офык тәрәзә кагар.
Җан сөйгәнне, ни теләсәң,
Күңелең эзләп табар.

Таулар сиңа сәлам юллар,
Кырлар ачар кочагын.
Хәтереңә уелып калыр
Истәлеккә кыз чагың.

Яшьлек күкрәүләрен тоеп,
Сокланыр сиңа кемнәр?
Хисләр давылын кузгатыр
Киләчәк матур көннәр.

## Чибәр кызга күз төшермим

Чибәр кызга күз төшермим,
Йөрәк чәнчү алмасын.
Дөрләп янган учак төсле,
Утларында янмасын.

Сөю газабын кичергән
Кешенең хәлен аңлыйм.
Битараф калырга исәп,
Үземне әллә алдыйм.

Чибәрләргә гашыйк булсам,
Күңелдә тынгы тапмыйм.
Сүнми дә, сүрелми дә гел,
Гомерлек сагыш саклыйм.

Юлларымда очратканда
Гашыйк итә сылулар.
Кыен хәлдә калганым бар,
Баштан кичте сынаулар.

Тәүбә иттем күп тапкырлар,
Кабатлана бу хатам.
Сөю-сөелмәү хакында
Юкка гына баш ватам.

## Сине һаман яратам

Безнең ара ераклаша,
Бергә булган көннәр дә.
Кеше гомер кичергәндә,
Мең төрлегә төрләнә.

Уртак иттек шатлыкларны,
Сөю хисләрен татып.
Ятлар керде арабызга,
Бәхетне алды тартып.

Күргән төш шикелле хәзер
Бергә чаклар тоела.
Минутын да кичектерми,
Син керәсең уема.

Тормыш юлы адаштыра,
Сизми калдым ул чакны.
Йөрәктә ут яна дөрләп,
Хәтерләтә учакны.

Ике яр өстендә калып,
Тыңлыйк вакыт агышын.
Башымны түбән идерә
Күңелдәге сагышым.

Оныталмый, авыр кичерәм,
Белмисең шул еракта.
Күзләрем эзли — табалмый,
Сине һаман яратам.

## *Куллар сузам биеклеккә*

Яңа үрләр яулау — татлы хыял,
Куллар сузам — җитми, биектә.
Тормыш һәрчак ашыктыра үзе,
Кубызына бары биетә.

Таныш түгел җирдә юл салуы
Икеләтә авыр, шикләнәм.

Максатыма барып җитәм, дисәм,
Киртәләр күп моны чикләгән.

Теләк бар чагында өмет сүнми,
Күчерергә мөмкин тауны да.
Эш күрсәткән, көчен кызганмаган
Ир-егетләр илдә таныла.

Ышанычың гына югалмасын,
Мең төрле хәстәрлек күрергә.
Кулдан килмәс эшләр юктыр да ул,
Комнан була аркан үрергә.

Мин тормышны матурларга телим,
Күзем кызса, күңел тартылыр,
Морадыма ирешермен әле,
Ходай кушса, ташка җан керер.

## Игелекле эшләр кылсам

Кырын эшкә тәүбә итеп яшим,
Ялгыш кул тигәнен сизмәдем.
Йөзләремә чыга ачуларым,
Сүгенеп тә алам, түзмәдем.

Дөнья малына да күңел кызмый,
Байлык артыннан да кумадым.
Бар булмышым — кыйбла ягында шул,
Иҗат хезмәтемә куандым.

Тормыш юлы төрле якка илтә,
Укый алмыйм тәкъдир язмасын.
Хаталансам, адашсам да барыбер,
Язмыш чыгарачак җәзасын.

Игелекле эшләр кылган булсам,
Еллар шаһит, гомер үтелгән.
Авыр хәлгә кинәт юлыксам да,
Яшәвемә бер дә үкенмәм.

## Килсә көчемнән

Үteләсе юллар үтелгән дә,
Гомер йомгаклары сүтелгән.
Илләр гизеп, диңгезләрне кичеп,
Урап чыктым дөнья читеннән.

Күтәп алган таңнар күптән аткан,
Ерак илдән кайткан кошлар да.
Ак карларга, бураннарга күмеп,
Җирдән китеп барды кышлар да.

Офыкларда сүрән шәфәкъ уты,
Ничә кабат тетрәпләр сүнде.
Бакчамдагы нәфис, назлы гөлләр
Сары көзләр килгәчтен шиңде.

Вакыт тезгеннәре табигатьнең
Бар мизгелен тота исәптә.
Йолдызлар да бермәл атылалар,
Мәңгелек ул галәм, дисәк тә.

Табигать баласы булгач, мин дә
Язмыш уртаклыгын төшенәм.
Гомер язларында калыр идем,
Мөмкин булса, килсә көчемнән.

## Безме жирнең кендеге?

Күктән төшкән сыман кыланабыз,
Без, әйтерсең, жирнең кендеге.
Бар булмышы, кылган эше белән
Ачыклана кемнең кемлеге.

Читләп кенә карап күз атабыз,
Сүз әйтмичә бары баш кагып.
Кая хәзер ихлас елмаюлар,
Патша вәзиренә охшадык.

Кеше кыланышы харап кына,
Читләп кенә аны күзләсәң.
Йөрәк өянәгең кинәт тотар,
Мондый хәлгә ярый түзәлсәң.

Тәкәбберлек, масаю да — жанда,
Канга күчкән аның вирусы.
Ил алдында, ата-бабага да
Гадел булырга без бурычлы.

## Бетми күңел ваклыгы

Яшен сүнә, ташу сулар тына,
Үз сагында тота вакытлар.
Төн карасы кебек эреп бетми
Күңелдәге бөтен ваклыклар.

Юлларыма каршы йөгереп чыга,
Читләп үтми нигә борчулар?
Атылырга торган вулкан сыман,
Бәгырьләрне телгән ачу бар.

Тынгысызлык җанны биләп ала,
Күкрәү сала уйлар яңартып.
Газапларга сала йөрәгемне,
Яраландым тормыш яратып.

Юк-бар өчен акланулар бетми,
Җилгә оча ятлар вәгъдәсе.
Тормыш юлларымны бизи алмас
Бу дөньяның чуар пәрдәсе.

## *Килер көннәр ничек булыр?*

Килер көннәр ничек булыр икән,
Күкләремне болыт капмармы?
Кешеләргә шатлык өләшерме,
Әҗәл сагалармы картларны?

Вакыт үзе хөкем итә барын,
Югалтуың булсын, табышың.
Үлчәвенә салып хисап ала,
Ел фасылын, кеше язмышын.

Килер чакны фаразлавы кыен,
Өметемне һич тә өзмәдем.
Тормыш сукмагында адашсам да,
Бәхетемне җирдә эзләдем.

Күзаллыймын татлы мизгелләрне,
Күрәчәгем — хыял диңгезе.
Иңнәремдә үскән пар канатлар
Галәм түрләренә менгезде.

Упкыннарга төшеп исән чыктым,
Мондый хәлгә күндем күптән мин.

Фәрештәләр күк гөмбәзен ачкан,
Канат каккан көнне көттем мин.

## Битараф булып яшисең

Кеше чәчәк аткан чакта,
Яфрак та яралмадың.
Масайсаң да, мактансаң да,
Әллә ни кыралмадың.

Синең яшьтә күп егетләр
Кулда тота тезгенне.
Айга оча, илләр гизә,
Ихтыярлы, түземле.

Күз йомасың бар эшкә дә,
Кул селтәдең тормышка.
Битараф булып яшисең,
Ирешмәдең уңышка.

Максатыңа юллар үрләр,
Хезмәт дәрте уятсаң.
Хәстәрлек күреп яшәрсең,
Кешеләрдән оялсаң.

## Көтмәгәндә җир шуыша

Кичә дөнья көйле генә торды,
Күңелләр көр, хисләр ташыды.
Тормыш кочагында иркен сулап,
Горур тотып йөрдем башымны.

Бүген килеп баскан җир шуыша,
Көтмәгәндә кыйблам үзгәрде.
Күкләремне болыт каплап алды,
Томалады сагыш күзләрне.

Шатлыкны да кайгы алыштыра,
Яшен ташы кебек чәчелде.
Җаным телгәләнде, күңел сызлый,
Агарттым ич чигә чәчемне.

Төнме, көнме — аера алмый торам,
Бер күзлектән карыйм барсына.
Утлы өермәләргә юлыктым,
Цунамилар килде каршыма.

Адәм баласының тәкъдиреме,
Афәтенә әллә юлыга?
Дөнья куйды таңда ахирәтем,
Озата бардым соңгы юлына...

## Шөгылемне алмаштырмам

Күк патшасын күргәнем юк,
Белмим кошлар телен дә.
Җир сөрәм, иген үстерәм
Туып-үскән илемдә.

Шаулы диңгез ярына да
Әле аяк басмадым.
Үз җиремдә иректәмен,
Зиндан биген ачмадым.

Хыялым дәшә еракка,
Зәңгәр офык артына.

Алтын тауларын күрергә,
Җаным түзми, тартыла.

Шөгылемне алмаштырмам
Оҗмахның почмагына.
Иген игеп гомер итәм,
Сәхрә-кыр кочагында.

Тамырыннан өзгән гөл дә
Саргая, корый, шиңә.
Туган җирем юксындырыр,
Хыянәт итсәм сиңа.

## *Авыл, шәһәр арасы*

Үлчәүләргә салсаң, ерактамы
Шәһәр белән авыл арасы?
Барам, дисәң, айлар, еллар кирәк,
Якын юлны каян табасы?

Авыл, шәһәр ике утрау кебек,
Тормыш уты аның сүнмәде.
Һәр кешенең монда үз шөгыле,
Үз мохите, эшләр гөрләде.

Зур сарайлар, завод, фабрикалар,
Шәһәр урамнары шау-шулы.
Авыл җире урман, кырларга бай,
Дулкын кага иген басуы.

Охшашлык та, аермалык та күп,
Авыл белән шәһәр арасы.
Туган җирен, үз төяген барыбер
Изге саный адәм баласы.

## *Максат куйган карарым*

Тормыш юлымны бизимен,
Кулымнан төшми эшем.
Утны, суны кичеп чыгам,
Булгач җан сөйгән кешем.

Көч-куәтемне җигәмен,
Максат куйган карарым.
Үз телемдә, үз җиремдә
Бәхетемне табармын.

Җилләргә карап йөз тоттым,
Суларга үрләп йөздем.
Төрлечәгә төрләндерә,
Тормышны күреп сиздем.

Мин бар җирдә дуслар була,
Маҗарага тарысам,
Бар да ярдәм кулы сузар,
Хәлдән таеп арысам.

Җир күчәрендә әйләнсен,
Күктә кояш елмайсын.
Кеше өмет белән яши,
Ышанычын җуймасын.

## *Карлар яуса да*

Үз сукмагым, үз юлымнан атлыйм,
Офыкларда шәфәкъ янса да.
Сагышланып сиңа киләм әле,
Башларыма карлар яуса да.

Кайнар хисләремне түкми-чәчми,
Бар булганын сиңа илтәмен.
Аякларым җиргә тими кала,
Очкан бөркет кебек, күктәмен.

Уйларымнан чыгып торганың юк,
Иртәсен дә шулай, кичен дә.
Юксынуым һич тә басылмады,
Йокыларда керден төшемә.

Ара ераклыгы шикләндерми,
Чакырымнарын аның санамыйм.
Бөтен мәшәкатьне читкә куеп,
Сиңа киләм, бер дә соңламыйм.

Таң шикелле балкып елмаямын,
Назлы җилләр булып исәрмен.
Юлларымның очы өзелмәсен,
Синең өчен диңгез кичәрмен.

## Төрле хәлләр була

Тормышта күңелсез хәлләр
Көн саен булып тора.
Пошындыра, уфтандыра,
Кычкырып булмый «ура».

Күпме кеше рәнҗетелә,
Кимсетүләр бетмәде.
Анасыннан туган бала
Мондый җәза көтмәде.

Хөсетлек тә, гайбәте дә
Дөньяга ник яралган?

Җәрәхәтли йөрәкләрне,
Авыр уйлар яңарган.

Төрле заманалар булган,
Кем соң җиңел кичергән?
Нужа калачын ашаган,
Хәмер суын эчергән.

Алла каршында кешенең
Кылган гөнаһы зурмы?
Төзәлмәс яралар кебек,
Кеше күңеле зарлы...

## Күтәп алам

Бураннары дулап, кыш та узды,
Тиздән язга аяк басамын.
Сәлам биреп колачымны ачтым,
Сәхрә-кырларымны кочамын.

Кошлар кайта — сөенче аламын,
Агачларда бөре тулышты.
Елга ярларыннан ташып чыкты,
Гөрселдәде сулар тавышы.

Күк йөзләре зәңгәр ефәк төсле,
Кояш суза алтын кылларын.
Илем имин, куанычлы булгач,
Бу көнемә дога кыламын.

Язга килеп җиттек исән килеш,
Бер могҗиза тере кешегә.
Сагышларга салып, кыш, бураның
Йөдәтте гел кереп төшемә.

Тынгысыз бу янган йөрәгемә,
Вакытында белеп су салдың.
Күтеп алам олы бәйрәм кебек,
Язның назларына сусадым.

## Галәм карашы

Галәм карашын төби
Жирдәге бар кешегә.
Таулар өя, күлләр ясый,
Хәйран кала көченә.

Күк сәламен тапшыра,
Йолдыз җилләрен өрә.
Кеше иҗат, хезмәттә,
Бар дөнья аны күрә.

Зәңгәр планетабызга
Язлар китерә кеше.
Җирне яшәртә, бизи,
Гомерлек бөек эше.

## Бөреләр

Биләүдәге бала төсле
Уяналар бөреләр.
Яз сулышы җанландыра,
Бар да исән, тереләр.

Бөреләр күзләрен ача
Апрель иртәсендә.
Сыерчык эндәшә сайрап
Үзенең иркәсенә.

Көмеш тәңкәдәй чылтырый,
Кар сулары телләнгән.
Бөтен җирдәге өн-аваз
Мең төрлегә төрләнгән.

Яшь тирәкләр кулын суза,
Күккә табан үреләә.
Бала күк тәүдә елмая,
Кояш күргәч, бөре дә.

## Кабул итәм

Кабул итәм яңа көнне,
Елмаюлы таңын да.
Талгын искән җилләрен дә,
Кошлар кебек кагына.

Кояшка куям йөземне,
Җаным, тәнем сөенсен.
Күңел кырларым назлансын,
Якты нурлар сибелсен.

Кабул итәм иген кырын,
Яратам шөгылемне.
Тургайлар телен отамын,
Язамын шигыремне.

Кабул итәм тормыш йөген,
Күп төрле мәшәкате.
Яшәү хәстәрен күрәмен,
Язмышыма рәхмәтле.

Давыллы, шомлы көннәр бар,
Кабул итәм шикләнми.

Күк ишелә, җир ярыла,
Бер дә мине читләми.

## *Җиңү көне*

Бүген — Тугызынчы май,
Җиңү бәйрәме көне.
Көтеп алган тантана
Шатландыра һәркемне.

Ветераннар түшендә —
Орден һәм медальләре.
Китапларга язарлык
Сугышта күргәннәре.

Кеше кадере арта
Бәхетле туган илдә.
Зур мәйданнар өстендә
Әләм җилферди җилдә.

Май юмарт чәчәкләргә,
Җир-анабызның назы.
Күп гасырлар үтсә дә,
Онытмаслар бу язны.

Кеше язмышы борчый,
Ярсыта хисләремне.
Тарихка сыеп бетмәс
Җиңү көн истәлеге.

## Җирем бәйрәм итә

Ташу сулар тавышы тынып кала,
Яшел үлән җиргә калыкты.
Чылтыр чишмәләргә моңнар кайтты,
Тирә-юньнән куа тынлыкны.

Яфрак яра шаулап яшь тирәкләр,
Күл өстендә дулкын уйнады.
Тургай җырлап көнне каршы ала,
Тын басулар кабат уянды.

Яз тантана итә бу мизгелдә,
Төсләр, моңнар җирдә төрләнде.
Дулкыннарны куып дулкын дәшә,
Бар табигать тәмам телләнде.

Якты нурын, җылы сулыш бөрки,
Үлән, туфрак кояш ярата.
Алма агачлары тәлгәшләнә,
Туган җирем, синдә ямь арта.

Яз ае гел юмарт бүләкләргә,
Кабул итеп алам гөлләрен.
Бөтен җиргә бәйрәм төсе керде,
Куанычлы, ямьле көннәрең.

## Бәйрәм тантанасы

Ямьле чакта уза сабантуйлар,
Кунак кайта, туган-тумача.
Мондый җыеннарны күрмәс идем,
Хезмәт бәйрәмнәре булмаса.

Халкымның бу күркәм йоласы шул,
Гасырлардан килә күптәнге.
Сәхрә кочагында, болыннарда,
Һәр ел саен ярыш үткәрде.

Гармун чыңлый, мәйдан тулы халык,
Җыр-моң белән күңел ачыла.
Ярсу атлар чабып, кешнәп уза,
Караш төшә юллар очына.

Мәйданнарга чыга ир-егетләр,
Көч-гайрәтле, билләр алыша.
Сабан туе гөрли бар җирдә дә,
Күзләр камаштырган тамаша.

Рухланып, хисләр ташкан чакта,
Әйтерсең, мин тудым яңадан.
Бәйрәм тантанасы хушландыра,
Хезмәт, иҗат белән яралган.

## *Мин көтәм*

Нигә инде,
Җәйгә керсәм,
Кышны сагынып бетәм.
Сары көзен, сандугачлы язын —
Барысын да мин көтәм.
Көтеп таң аттырам.

Таңнар атса, мәшәкатем арта,
Тагын чыгам юллар чатына.
Юк бит чарам
Бармый калырга,
Киләчәгем мине чакыра.

Күңел дулкынлана,
Йөрәк хисе таша,
Йөргән юллар әгәр уң булса.
Дөнья булгач, төрле чаклар була,
Барсын көтәм, яңа көн туса.

Тормыш югалтмасын өлешемне,
Куанычын бирсен, кайгысын.
Бер булса да, язмыш тәрәзәсен
Килә әле ачып карыйсым.

Ераклардан
Якыннарны көтәм,
Төн артыннан көтәм көннәрне.
Ышанычлы көтеп киләчәкне,
Якты өметләрем сүнмәде.

Беләм, ни булса да,
Узган яшьлек таңым,
Кабатланмас инде ул бүтән.
Соңга калып килгән яз шикелле,
Мәхәббәтем килер — мин көтәм.

## *Кош тотсаң*

Яшьтән бисмилла әйтергә
Өйрәттеләр, белмәдек.
Атеистлар хөкем кылды,
Алар сүзен өнәдек.

Диннән, телдән язып беттек,
Иман әһеле калмады.
Күзләрне кара кан басты,
Күңелләр дә каралды.

Гамьсезлектә битарафлык
Томалады аңыңны.
Танымагач гаебеңне,
Рәнҗетерсең анаңны.

Ярый, вөҗдан газабыннан
Тиз генә котылалсаң.
Яшәвеңә үкенмәссең,
Кул белән кош тоталсаң.

## Ант иттем, вәгъдә бирдем

Әйткән антлар, биргән вәгъдәләр дә
Яшь чагымда булды күптәнге.
Кирәге юк, хаҗәте юк инде,
Кабатламыйм хәзер үткәнне.

Давыл алып килгән болыт кебек,
Күкрәп узды яшьлек еллары.
Куанычлы хезмәт җимешләрем,
Мин ышаныч белән юлладым.

Үтенечләр, үкенечләр дә бар,
Кул җитмәгән эшкә сүз бирдем.
Тәвәккәллек, кыюлык та җитте,
Барын да тик татып өлгердем.

Заманында шулай кирәк булды,
Күргәч, белгәч, кулны селтәдем.
Бар көчемә хыял канатымда
Күк йөзеннән йолдыз чүпләдем.

Антлар иттем, вәгъдәләр дә бирдем,
Җиңел генә үзем күп оттым.

Бу тормышны авызлыклап алып,
Кулга аны тезгенләп тоттым.

## *Хисләр ташкыны*

Давыл кочагына алып мине,
Җиденче кат күккә күтәрде.
Йолдызларны күреп сәлам бирдем,
Урап, җиргә кабат китерде.

Иңнәремә пар канатлар үсте,
Каным кайнап тәндә йөгерде.
Яшьлегемнең кабатланмас язын
Каршылыймын, бары — егерме.

Бу мәл дөнья гаҗәеп тә серле,
Мохтаҗ булмадым бит назына.
Гомеремнең татлы кичереше
Күңел дәфтәремә языла.

Дәртем таша, көч-гайрәтем арта,
Уй-хыялларым чынга аша.
Изге эшләр кылып яшәгәндә,
Могҗизалар көтәм көн аша.

Җир белән күк арасында калсам,
Түземсез, ник йөрәк ашкынды?
Юлларымнан алып кая илтер
Тезгенсез ул хисләр ташкыны?

## *Күл буенда*

Күзге сыман күл өсләре тоныкъ,
Кояш нурларында чагыла.
Бу мизгелдә ямьле җәй уртасы
Хозурлыгын алган сагына.

Күлгә төште казлар тезелешеп,
Яр читендә сулар чайкала.
Каңгылдаша канатларын җәеп,
Сөенүдән бар да чаң кага.

Ак болытлар кәрваннары күктә,
Өнсез калып, тоташ агыла.
Ямьле җәйләр нигә бик тиз уза,
Төрле уйлар килә аңыма.

Күл өстендә акчарлаклар оча,
Эндәшмәде, әйтми серләрен.
Яр өстендә үскән камышлары
Башын кагып бирә сәламен.

Күзләремне текәп офыкларга,
Кулларымны куям кашыма.
Саубуллашып китәм дигән мәлне
Чал дулкыннар килә каршыма.

Китәлмичә калдым күл буенда,
Бер юксыну хисе кичереп.
Үзем белән барын алып китәм,
Күңел түрләренә күчереп.

## Төн пәрдәсен яба

Шәфәкъ нуры алсуланып балкый,
Тынып кала сайрар кошлар да.
Үз бизәген, чагу төсен алган
Җирдә аунап яткан ташлар да.

Җиләс җилләр килеп агачларның
Яфракларын сөеп тирбәтә.
Гармун моңы чыңлый, җыр тавышы
Ишетелә кайсы төбәктә.

Кызлар сыман купшы бизәнгән дә
Җәй аенның ямьле кичләре,
Җанга күкрәү сала илаһи көч,
Тезгенләми ярсу хисләрне.

Төн пәрдәсен яба тирә-юньгә,
Шәфәкъ уты җирдә йотыла.
Сәхрә-кырлар бар да тыныч кына
Тала инде тирән йокыга.

Тын кичләрне күңел күтәп ала,
Могҗиза да бардыр бу чакта.
Тормыш дәвам итә башкачарак,
Утлар сүнми яна учакта.

## Хәтер капчыгымда

Берәм-берәм хәтер капчыгымны
Ефәк тасма белән бәйләдем.
Табышым бар, югалтулар да күп,
И, язмышым, шулдыр бүләгең.

Каз бәбкәсен саклап йөргән чаклар,
Буразналар ярган атларым.
Хәтер капчыгымда күптән ята
Тәүге тапкыр язган хатларым.

Гармун тартып узган яшьлегемдә,
Хисләр ташып торды ул чакта.
Барын сагынып хәзер искә алам,
Күптән сүнгән янган учак та.

Үткән еллар, айлар, көннәр, төннәр
Корыч чылбыр булып тоташкан.
Дуслар, ятлар, шатлык, кичерешләр
Соңгы чиктә бергә катнашкан.

Моңга чумган көзге урман төсле,
Күңелләрем тулып уйланам.
Төшләремдә үткәннәрне күреп,
Мин йокымнан көлеп уянам.

## Җиде якка юл ята

Ир-егетләр баскан юл чатына,
Кая китсәләр дә — ирекле.
Күрәчәкне юллап күрәсеңдер,
Ирек куя язмыш бу тикле.

Җиде якка җиде юл сузылган,
Теләгәнен сайлап аласың.
Нинди табыш, нинди һәлакәткә
Очраштырмас адәм баласын?

Юллар төрле, берсе илтә данга,
Икенчесе аның афәткә.

Күк артына ыргытмаслар әле
Безгә тигән олы бәхетне.

Дәрәҗәгә, данга менәлмәдем,
Юл газабын бары күрсәттең.
Дусларыма хәтта сиздермәдем,
Юан башы төште күсәкнең.

Гомер йомгакларын юллар сүтә,
Күңел күнә, йөрәк төшенә.
Ай тотарга булган арыслан күк,
Ир-егетне диңгез кичерә.

## Күргәннәрем төш кенә

Гомер үрләренә менеп җитәм,
Сәер тынлык били җанымны.
Әллә күптән мине генә көткән,
Мөлаем да, үзе ягымлы.

Йөрәк тыныч, ут йотмыймын башка,
Борчуларым мине читләде.
Җил-яңгырлар тими, бар да көйле,
Җирдә калмый дөнья чүпләре.

Көнчелләр дә, гайбәтчеләр дә юк,
Бәхет белән шатлык бер сафта.
Рәнҗетмиләр, кимсетмиләр бүтән,
Гамьсез түгел беркем бу чакта.

Мендәремә башны куеп ятам,
Черем иткән вакыт кичкенә.
Бу тормышта яшәү нинди рәхәт,
Күргәннәрем бары төш кенә.

## *Казлар*

Казлар йөри болын буйларында,
Кыяк үлән ашап чемченә.
Төркем-төркем ак болытлар кебек,
Бер урында тормый, күченә.

Каңгылдаша канатларын кагып,
Каурыйлары туза җилләргә.
Авыл карчыклары чыбык тотып,
Су буена килә җәйләрдә.

Тәгәрәшеп үсә бәбкә казлар,
Дөнья рәхәтенә тарыды.
Кендекләре җиргә береккәнме,
Бик тирәнгә төшә тамыры.

Өметләре күкрәп бөреләнсен,
Күзаллыймын килер көзләрне.
Шаулы өмә узар һәрбер йортта,
Буй җиткергән күрше кызлары.

Өмәләрдә гармун уйнатырлар,
Чыңлап китәр көмеш телләре.
Төш күрсәк тә, яхшылыкка юрыйк,
Кабул булсын яшьләр теләге.

Казлар җилкенгәндә канат кагып,
Торып кала күзләр карашы.
Хыяллардан бәлки башланадыр
Чын тормышка илтер юл башы.

## И, туган җир

Сакат тауларына бөркет куна,
Буй суына төшә аккошлар.
Туган җирем урман-кырларга бай,
Матур гомер кичә якташлар.

Кыр өсләре игеннәргә тулы,
Балкып яна грэс утлары.
Заманында монда кешнәп йөргән
Бабайларның өер атлары.

Үз вакыты җитеп, язлар килгән,
Яңгыр яуган, яшен яшьнәгән.
Ата-бабам изге туфрагына
Гел генә табынып яшәгән.

И, туган җир, биек тауларыңнан,
Якты таңнарыңнан танырмын.
Сиңа булган мәхәббәтем сүнмәс,
Бик тирәндә ята тамырың.

## Гел кояшлы көннәре

Җәй көннәрен юксынырмын,
Каршы барам йөгереп.
Басуларны төштә күрәм,
Арыш җиткән өлгереп.

Тургай җыры хушландыра,
Илһам, шөһрәтләр тоям.
Баскан туфрак җылысына
Башымны җиргә куям.

Җәй аеның яктылыгы,
Ямьнәре аның тансык.
Кая ашыга туктаусыз,
Гомер чишмәсе ташып?

Ел мизгелләрен барлыймын,
Юксындырыр күпләрне.
Юлдаш булсын сукмагыма
Гел кояшлы күкләре.

## Туган як — горурлыгым

Тау-кыялар башын сузган биек,
Нарат урманнары иңендә.
Хозурлыгы аның куандыра,
Горурлыгым бит ул минем дә.

Уйсулыклар, болын, сәхрә-кырлар
Үз бизәген тапкан, үз төсен.
Гүзәллек бар монда, сафлыгы да,
Җитә гашыйк итәрлек көчең.

Юмарт туфрагының уңышы мул,
Хәзинәле җирнең катламы.
Бу җирләрдә уңган халык яши,
Эшчән, тырыш, бар да мактаулы.

Туган якның яме, нуры сүнмәс,
Табигате күркәм, сөйкемле.
Күкрәп үсәр оҗмах гөлләре дә,
Әкияттәге дөнья шикелле.

Илләр гизеп, ерак юллар йөрдем,
Күрдем кош кунмаган җирен дә.
Гомер чишмәм синдә гөрләп ага,
Миңа назлы искән җилең дә.

## Басуларда йөрим

Басуларга чыгып урап кайтам,
Иген кырын якын, иш итәм.
Бөтен шикләремнән арынамын,
Тургайларның җырын ишетәм.

Игенчеләр җир хәстәрен күрә,
Ашлыклары уңар, иншалла.
Тирләр түгеп, көчен кызганмый да,
Уңыш алырына ышана.

Көткән чакта яңгыры да яумый,
Кирәксезгә коя чиләкләп.
Икмәкләргә мул чагы да булды,
Ачлыгы да килде сирәкләп.

Авыл кешеләрен, җил иссә дә,
Хафасына сала басулар.
Бу табигать көйсез кияү кебек,
Борчылдыра җанны, ачу бар.

Туфрак алып учларыма салам,
Юмартлыгын мәңге сакласын.
Игенченең изге әманәте,
Өметләре аның аклансын.

## Дулкыннар тынып кала

Бишегендә яткан бала төсле,
Дулкын кочагында тирбәләм.
Колачларын җәеп, акчарлаклар
Очып үтә минем тирәмнән.

Ярсу дулкын, аргамаклар кебек,
Ярларына сыймый дулады.
Кыя ташларына башын салып,
Көчсезлеген белеп улады.

Иркенлекне, чиксезлекне тели,
Дулкын ярларыннан чыгарга
Бар гайрәтен җыеп ашкынса да,
Туры килеп бетми чамага.

Су төбенә төшкән кебек була,
Күз алдында дулкын йотыла.
Яр буйларын тынлык биләп ала,
Әйтерсең лә тала йокыга.

Дулкын гомере дә мизгел генә,
Яшен ташы сыман тиз сүнә.
Үз хәленә кайта төшенгәчтен,
Ярларына туктап тез чүгә.

## Яшен

Күк гөмбәзләрен тетрәтә,
Яшеннәр чатнап уйнап.
Офыклардан аваз килә
Ерак галәмнәр буйлап.

Биек таулар тетрәнделәр,
Аккан сулар чайкалды.
Шомлы күкрәү авазына
Бар табигать тын калды.

Гайрәтен, көчен күрсәтеп,
Яшен яшьнәп уйнады.
Котын очырып җанымның,
Камчылый бар дөньяны.

Галәм битараф калмады,
Күкрәүләр тавышына.
Хөкемен чыгара тагын
Кемнең соң язмышына?

## Оран сала әтәчләр

Таң уяныргa өлгерми,
Әтәчләр оран сала.
Сәгатен дә кичектерми,
Үзләре белә чама.

Әтәчләр тынып тормады
Иртәсен дә, кичен дә.
Вазыйфасын үтәп яши,
Кызганмыйча көчен дә.

Әтәчләрнең үз дөньясы,
Башкарган, кылган эше.
Ил чигендә сакта торган
Кыю солдатлар төсле.

Затлы әтәчләр нәселе,
Горур, уяу, сөйкемле.
Авылда курку белмәгән
Ир-егетләр шикелле.

## Җир җиләкләре пешкән

Алсуланып, телгәшләнеп,
Җир җиләкләре пешкән.
Татлы хуш исләр сибелә,
Ширбәтле сулар эчкән.

Таң нурларына коена,
Чык суында юына.
Тугайлар буйлап әйләндем,
Гөлләр үскән юлыма.

Җиләкле ямьле җәйләрем,
Авыз иттем җимешен.
Бай туган җир хәзинәсе,
Миңа тигән өлешем.

Хозурлыгы тугайларның
Җәннәт бакчасы сыман.
Җир җиләкләре пешкән мәл,
Сәхрә-кырларга чыгам.

## Йолдызлар яңгыры

Август төнендә юлыктым
Йолдызлар яңгырына.
Галәм түреннән сибелеп,
Бар җиргә ябырыла.

Балык күк ялтырап китә,
Метеормы финишта?
Күк йөзендә күп могҗиза,
Канат җәйгән фәрештә.

Күк чөйде көмеш тәңкәсен,
Юмартлыгын күрсәтте.
Ай-йолдызлар бар да бергә
Шоу-тамаша күзәтте.

Мин бу төнгә гаҗәпләнеп,
Сихерләндем бер төсле.
Җир галәмгә тартыламы,
Әллә күк түбән төште?

*Ф.-гә*

Карашың шундый мөлаем,
Карашың синең назлы.
Күңел бозларын эретә,
Хәтерләтәсең язны.

Яшеннәр яшьнәтәсеңме,
Карашларың көйдерә.
Йөрәкне сүнмәс ут алды,
Мәхәббәтең сөйдерә.

Давыллар уятыр төсле,
Карашың синең серле.
Елның бөтен фасылы бар,
Буласың ничә төрле.

## *Хезмәт сөйдек*

Без дә агарттык дөньяны,
Матурладык, төзәттек.
Битарафлык күрсәтмәдек,
Уртасыннан күзәттек.

Җаныбызны фида кылдык,
Гүзәллеккә табынып.
Искән җилгә йөз куябыз,
Егылсак та абынып.

Изге теләктә яшибез,
Дөнья кадерен белеп.
Зарланмадык, хурланмадык,
Хезмәт сөйдек иң элек.

Иҗат үрләренә табан
Гомер буе үрләдек.
Кадерли белмәгәннәргә
Әрсезләнеп йөрмәдек.

Яшәү шатлыгын кичердек,
Ашкындырып йөрәкне.
Юатты да, җырлатты да,
Тормыш үзе өйрәтте.

## Җырладык та биедек

Яшьлек дәрте ашкындыра,
Җырлыйбыз да биибез.
Уйнап-көлдек, күңел ачтык,
Дөнья фани — белмибез.

Сизми, белми дә калырбыз,
Шатлыклы көн тиз үтәр.
Яшьлек белән хушлашырга
Вакытлар килеп җитәр.

Күңелдә каен аклыгы,
Иңдә талмас канатлар.
Без йөргән гөл бакчасында
Сандугачлар кунаклар.

Тансык иттек кызык күреп,
Ярсыганда агымсу.
Елмаеп атты таңнар да,
Йөрәкләр тибә ярсу.

Яшьлек кочагына алды,
Хозурландык, сөелдек.
Җилеп үтәр бу мизгелләр
Мәңгелек күк сөендек.

## *Еллар сыман озын көткән көнем*

*В. К.-га*

Еллар сыман озын көткән көнем,
Айлар кебек һәрбер минутым.
Очрашырга сүз куешкан идек,
Күрешергә, ахры, оныттың.

Әйткән антың, биргән вәгъдәң калды,
Барысыннан нигә танасың?
Борчылмыйча гына үткәннәргә,
Тыныч күңел белән каласың?

Алдадың да үзең, алдандым да,
Булды, ахры, төрле чакларым.
Сиңа булган яшьлек мәхәббәтем
Күпме еллар тугры сакладым.

Сагынганда карыйм юлларыңа,
Ул юллардан хәзер килмәссең.
Зәңгәр чәчәк тотып кулларыңа,
Төшләремә генә керәсең.

Моңсуланып йөргән минутлар бар,
Андый хисләр белән исермик.
Бергә булган шат көннәрне инде
Бер булса да искә төшерик.

Тиңсезләргә тиң табыла бит ул,
Кыюсызлар үзенә иш итә.
Ятлар сүзен аска куеп булсын,
Күрешергә кирәк ничек тә.

Горурлыктан артык газапландык,
Уйланмаган эшкә чынладык.
Шатлыктарга әллә түзәлмәдек,
Кайгыларга инде чыдадык.

## Яратам икән

Җан өшиме, калтырана,
Керәмме әллә көзгә?
Ничек ышанып бетәсең,
Яратам, дигән сүзгә.

Сиңа өзелеп карыймын
Шаян яшьлегем аша.
Беркемгә дә сиздермәдем,
Күңелне ник шом баса?

Күреп сокландым тәүдә мин,
Йөзеңдә уйный нурың.
Йөрәгемнең иң түрендә
Аласың изге урын.

Яндырсаң да, көйдерсәң дә,
Җәзалап йөрдең күптән.
Икеләнми, төшендем мин:
Яратам, сөям икән.

## Сүнмәсен өмет учагым

Кабынды күңел түрендә
Өмет учагым.
Йолдыз булып бер балкырмын,
Минем шул чагым.

Дөрләп янам шәм шикелле,
Давылда, җилдә.
Гауга, алыш беткәне юк
Мәңге бу илдә.

Хәтәр заманда туганмын,
Күптән аңладым.
Максатыма юл ярамын,
Тормыш, алдадың.

Хезмәт җимешен җыямын,
Шатлык кичерәм.
Яшәү хакы арзан түгел,
Таулар күчерәм.

Тормыш адым саен сыный,
Тоямын көн дә.
Өмет ялкыны сүнмәсен
Гомергә миндә.

## Мәхәббәтне кем дә татыган

Тәрәзәңдә якты утлар балкый,
Күктән алып айны элдеңме?
Ут яктысы ак җәймәсен җәйгән,
Мин киләсен әллә белгәнме?

Төнме, көнме — аерып торганым юк,
Син яшәгән йортка еш киләм.
Вакыт белән бер дә исәпләшмим,
Барсына хәзер мин күнәм.

Сизмисең дә әле һаман булса,
Магнит сыман сиңа тартылам.
Сүз кушарга кыюлыгым җитми,
Мәхәббәтне кем дә татыган.

Сөю ялкынында моңсуланып,
Гашыйк газапларын кичердем.

Диңгез кебек тирән уйларыма
Ялгызымны гына төшердең.

Бер чик куялмадым хисләремә,
Йөрәгемдә саклыйм моң-зарны.
Белмисең дә янып-көюемне,
Бу дөньяда минем барымны.

## *Гармуным кулларымда*

Гармун дустым, синең белән
Яшь чактан ук танышмын.
Дәртле, моңлы, җырлы иттең
Гомеремнең агышын.

Икәү бергә күп йөрдек бит
Мәҗлесләргә, туйларга.
Көмеш моңыңа көнләшә
Сандугач та, тургай да.

Йөрәк серемне сөйләтәм
Гармуным телләреннән.
Мин төшсәм дә алып чыга
Хәсрәт, уй күлләреннән.

Кайда йөрсәм дә, гармунны
Калдырмадым, куймадым.
Сәхрәләрдә, урамнарда
Өздерепләр уйнадым.

Талпынсын, кагынсын әле
Туган җирдә, талларда.
Җыр белән гомер кичерәм,
Гармуным кулларымда.

## Кызларның мөлаем карашы

Урам буйлап кызлар килә,
Очрадылар каршыма.
Тыныч кына узып булмый,
Күз төшерәм барсына.

Наз, дәртлелек, чибәрлектән
Кызлар мәхрүм калмаган.
Карашлары җилкендерә,
Моны күпләр аңлаган.

Кызларның якты карашы
Карны-бозны эретә.
Онытыла күңел борчуы,
Кайнар хисне терелтә.

Мин, әйтерсең, кош баласы,
Талпынам, канатланам.
Кызлар күрсәм сүз кушамын,
Аларны караталам.
Мин әле яраталам.

## Таң атар мәлдә

Офыкта таң уянмаган әле,
Сайрар кошлар какмый канатын.
Төн пәрдәсен япкан җир өстенә,
Бар табигать сакта тора тын.

Анам кебек, җирем бик сак йоклый,
Яфрак кыштырдасын — сискәнә.
Галәм киңлекләре серен ачмый.
Җил иссә дә, кинәт шикләнә.

Тау астында көмеш чишмәләрем,
Җырын суза көнне каршылап.
Аяз күгем, таң сызылып атар,
Имин тора илем, иншалла.

Бал кортлары очар иртә белән,
Җирнең чәчәкләре елмаер.
Иген басулары шаулаганда,
Шатлык тоеп, күңел юаныр.

Алсу таңны көтеп аттырамын,
Төн карасы җирдә эресен.
Килер көнем нинди булыр икән,
Йокым килми, уйлыйм төрлесен.

## Август иртәсе

Август иртәсенең яктылыгы,
Җиләслеге кала исемдә.
Шаулап торган сары дулкын уйный
Иген басулары өстендә.

Чык ялтырый яшел үләннәрдә,
Җил тарата алма исләрен.
Иртәнге нур уйный — күз камаша,
Канатланды кайнар хисләрем.

Күкләр аяз, яшеннәре яшьнәп,
Күкрәүләре узган кай якка?
Назлар, ямьнәр алып килгән көнем,
Кошлар моңы керде колакка.

Сокландыра зәңгәр иртәләрең,
Күз карашым ерак йөгерде.
Бакчаларда чияләрем пеште,
Игеннәрем кырда өлгерде.

## Гармун йөри урамнарда

Шәфәкъ батты,
Төн пәрдәсен япты,
Чык бөртеге кунды гөлләргә.
Яфрак кына кайчак калтырана,
Ай шәүләсе төште күлләргә.

Ялгыз каен
Күл буенда тора
Маңгай бөдрәләрен таратып.
Гармун уза, гармун уйнап йөри,
Авыл урамнарын уратып.

Ул күтәрә күңел пәрдәләрен,
Чиртеп үтә йөрәк кылларын.
Ямьләндерә яшел тугайларны,
Җанландыра иген кырларын.

Уйландыра гармун, моңландыра,
Ташкан хискә бирелеп торамын.
Бар иде бит шулай
Гармун уйнап,
Узган чаклар авыл урамын.

## Юлаучыга юлдаш булам

Тауга менсәм тау буласым килә,
Моңы булам аккан чишмәнең.
Күккә карыйм тәрәзәмне ачып,
Йолдыз булып балкыйм кичләрен.

Мин камышы булам зәңгәр күлнең,
Дулкыннарын ярда кочармын.

Мин шоңкары булам кыяларның,
Офыклардан биек очармын.

Яз чәчәге умырзая булам,
Җиргә якты бизәк өстәрмен.
Кышы, язы, җәе, көзе булам,
Күз камашкан төрле төстәмен.

Кешеләрнең мин шатлыгы булам,
Мирас итеп барын өләшәм.
Кардәшләрем сыман якын күрәм,
Сәлам биреп, сезгә эндәшәм.

Юлаучыга юлдаш булып барам,
Маяк булам карлы юлларга.
Көмеш кыңгыраулар кебек чыңлап,
Җырым барсын ерак елларга.





# ЖЫРЛАР

*Жир-анабыҙ, җәннәт баҡчасы күк,*
*Асыл гөлләр белән биҙәлсен.*
*Кылган эшләребеҙ үрнәк булсын,*
*Ай, йолдыҙлар күктән күҙләсен.*

## *Очрашырбыз әле*

Күңел юксынуым басылырмы,
Күз нурларын алган назлар бар.
Очрашырбыз әле,
Очрашырбыз,
Киләчәктән көткән язлар бар.

Еракларга юллар чакырып тора,
Сабырланмый, җаным, нишләдең?
Сагындырдың мине,
Сагындырдың,
Ашкындыра кайнар хисләрем.

Өметләрем пар канатлар куя,
Күрешү сәгатьләрен тизләтеп.
Ялгышыммы әллә,
Язмышыммы,
Мөмкин булса икән төзәтеп.

Йөрәгемә урын табалмадым,
Кабатлана моңсу көннәрем.
Белеп булса икән,
Белеп булса,
Бу дөньяда язмыш телләрен.

## Гомерләр уза икән

Ага сулар, ага сулар,
Белмим, ага кайларга.
Гомерләр уза сизелми,
Төшәм тирән уйларга.

Кушымта:

*Аккан су да, искән җил дә*
*Кисәтә гомерләрне.*
*Үкенечкә кала икән,*
*Сызлата бәгырьләрне.*

Җирнең асыл бизәкләре,
Күрәмен, тоныклана.
Ярсыган гөрләвекләр дә
Бермәлне тынып кала.

Кушымта.

Исә җилләр, исә жилләр,
Юл ала еракларга.
Күңелләр дә сагышлана,
Тынгысыз йөрәкләр дә.

Кушымта.

## Игенче җыры

Ямьле дә соң, матур да соң
Безнең авыл,
Безнең авыл кырлары.
Кыр өстендә игенчеләр
Каршы ала таңнарны.

К у ш ы м т а.

*Таңны шәфәкъка ялгаган*
*Авылның уңганнары.*
*Мактап җырларыма кушам*
*Мул уңыш алганнарны.*

Тук башаклар җилдә уйный,
Дулкынлана,
Дулкынлана, тирбәлә.
Игенче хәзмәте белән
Мактала бар телләрдә.

К у ш ы м т а.

Җир хәстәре иңнәремдә,
Хезмәт дәрте,
Хезмәт дәрте кабына.
Уртаклаша шатлыкларын
Игенчеләр табында.

К у ш ы м т а.

## Язмышлар уртак

Татар-башкорт ике туган,
Язмышлар уртак бергә.
Кардәшлек, дуслык хисләре
Сүрелмәсен гомергә.

К у ш ы м т а:

*Табыннар корып яшәдек,*
*Гомерләр бергә уза.*

*Беребез курай уйнаса,*
*Беребез гармун суза.*

Уллар-кызлар үстерәбез,
Кодалар булып йөрик.
Илләр иминлеген саклыйк,
Хәстәрен бергә күрик.

Кушымта.

Авыр еллар, озын юллар,
Бергә җиңел үткәрдек.
Зарланмыйча, тормыш йөген
Иңебездә күтәрдек.

Кушымта.

## Чәчкәләргә сулар сибәм

Бакчаларда сулар сибәм,
Гөл-чәчкәләр шиңмәсен.
Тормышыма ямь өстәсен,
Күз нурларым сүнмәсен.

Кушымта:

*Гомерләр уза сизелми,*
*Ашыгып еллар үтә.*
*Туган җирне матурлыйммын,*
*Яшьлегем дәвам итә.*

Якын дуслар юксындыра,
Моңсу ата таңнарым.
Күңел юанычын табам,
Кошлар җырын тыңладым.

Кушымта.

Чәчкәләрдә күз карашым,
Татлы хуш исләр сибә.
Яшьлек хисләрен уята,
Йөрәгем ярсып тибә.

Кушымта.

## Җилләр дә каршы исә

Очар канатларым талды,
Юлларым адаштырды.
Вәгъдәләшкән сөйгән ярым
Ятларга алмаштырды.

Кушымта:

*Күрәчәгем, язмышым шул,*
*Төзәлмәс йөрәк ярам.*
*Җанымны өшетеп искән*
*Җилләргә каршы барам.*

Бәхетемә киртә салдың,
Йөземне сагыш сарды.
Сөйгән ярым хыянәте
Сүнмәс утларга салды.

Кушымта.

Хәтердә калыр гомергә,
Су буе, айлы кичләр.
Сөеп сөелер чакларым,
Сүнмәс, сүрелмәс хисләр.

Кушымта.

## *Бүген туган көнең*

Бүген синең туган көнең,
Гомерең иртәләре.
Кояш көлә, жилләр исә,
Бар дөнья иркәләде.

К у ш ы м т а:

*Гомер сукмакларың синең*
*Тормыш үрен үрләсен.*
*Озак яшә картаймыйча,*
*Яшьлек дәрте сүнмәсен.*

Тормыш кочагына алып,
Иркәләп сөйде назлап.
Әниең бәхет теләде,
Күрмичә яшә газап.

К у ш ы м т а.

Фәрештәләр канат җәяр,
Афәтеннән сакласын.
Кылган матур эшләреңә
Бар кеше дә соклансын.

К у ш ы м т а.

## *Яшьлегемә кайтам*

Җиккән атлар ярсып кешни,
Юлга төште күзләрем.
Яшь чакларны хәтерләтте,
Каршы алам, түзмәдем.

К у ш ы м т а:

*Көмеш кыңгыраулар моңы*
*Ишетелде ерактан,*
*Яшьлегемә алып кайттың,*
*Сагышларны таратам.*

Атлар чаба җил уйнатып,
Йөрәгем аша үтте.
Шатлыклы кичерешләрем,
Сагынып күңел көтте.

К у ш ы м т а.

Онытылмаслык бу көннәрем
Татлы төш булып калсын.
Киләчәккә якты хисләр
Мине озата барсын.

К у ш ы м т а.

## Төшләремә керәсең

Ак күлмәгеңне киясең,
Төшләремә керәсең.
Борчыласың, юксынасың,
Уйлыйсыңдыр, күрәсең.

Каеннар серен сөйләде,
Чуклы шәлен таратып.
Төшләремә гел керәсең,
Сөю хисен яңартып.

Яшьлек күкрәүләре ерак,
Кай якларга чигенде.

Әллә язмыш адаштырды,
Күрешергә соң инде.

Бергә йөргән сукмаклардан,
Үткәннәрдән киләсең.
Тынгысызлап күңелемне,
Төшләремә керәсең.

## Сөеп сөеник әле

Яшь гомер әрәм узмасын,
Сөеп сөеник әле.
Кошлар да парын табыша,
Язның да ямьле мәле.

Кушымта:

*Йөрәкләргә күпер салыйк,*
*Якынайтып араны.*
*Сөю хисе күңелләрне*
*Моңнарына урады.*

Мәхәббәт бәхет китерә,
Куаныч, шатлык бирә.
Өметләнеп көткән көнем
Алдан төшләргә керә.

Кушымта.

Гомер юлына юлдаш бул,
Җигеп ярсу атларны.
Тормыш маягы булаек,
Көнләштерик ятларны.

Кушымта.

## *Иртәләрем, кичләрем*

Кая китте шат көннәрем,
Кемгә карап юанам.
Йөрәгемә тынгы тапмыйм,
Йокылардан уянам.

Кушымта:

*Нигә моңсу була икән*
*Иртәләрем, кичләрем.*
*Гомер көзләренә керәм,*
*Ялгыз башым нишләрмен.*

Күз алларым томалана,
Эчкән сулар болгана.
Болай моңсуланмас идем,
Янда дуслар булганда.

Кушымта.

Иртән, кичен кошлар сайрап,
Сагышымны көчәйтә.
Борчуларым йөзгә чыккан,
Күргән бер кеше әйтә.

Кушымта.

## *Зәңгәр күзләр*

Күзләреңнән нурлар ташып ага,
Хәтерләтеп зәңгәр дәрьяны.
Белмим нинди көчләр гашыйк итте,
Оныттырып бөтен дөньямны.

Мин адашам күзләреңә карап,
Серлеләр дә алар, тирән дә.
Атар таңнар кебек балкып тора
Юк аларга башка тиңнәр дә.

Ак җилкәндә йөзәм дәрья суын,
Җилләр исәр кайсы якларга?
Синең зәңгәр күзләреңне сөям,
Серләр итеп саклыйм ятларга.

## *Укытучым*

Мөлаем, якты карашың,
Тойдым йөрәк тибешен.
Гомер буе шәфкатеңне
Онытмаска тиешмен.

Кушымта:

*Укытучым, укытучым,*
*Маяк син тормышымда.*
*Мине язмыш очраштырды*
*Гомерем агышында.*

Күңелемне нурга төрдең,
Мәңге сүнмәс кояшым.
Җирдә бөтен гүзәллекне
Гел үзеңә җыйгансың.

Кушымта.

Тормыш юлына чыгардың,
Алып менден үрләргә.

Олы шатлыклар юлладың
Безнең килер көннәргә.

Кушымта.

## *Яшьлек хатирәсе*

Юлларыма яңа юл кушыла,
Елларыма еллар өстәлә.
Туган көннең шаулы тантанасы
Бергә җыя безне өстәлгә.

Маңгай бөдрәләрен сирәкләтеп,
Чәчләремне еллар агарта.
Табыннарда безнең җырлаган җыр
Яшьлек хатирәсен яңарта.

Узган язлар хәзер төшкә керә,
Сагышына сала көзләр дә.
Күктә янган соңгы йолдыз кебек,
Яшьлек дәрте калды күзләрдә.



## *Эчтәлек*

*Автор турында белешмә...* . . . . . . . . . . . . . 3

**Шигырьләр**

Үз җиремдә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
Зарланмыйча яшик . . . . . . . . . . . . . . . . 8
Кешеләргә булсын кирәгем . . . . . . . . . . . 8
Дөнья ямен җибәрмик . . . . . . . . . . . . . . 9
Хезмәт дәрте бирә . . . . . . . . . . . . . . . . 10
Киләчәккә дәшәм . . . . . . . . . . . . . . . . . 11
Күзен ача тәрәзәләр . . . . . . . . . . . . . . . 12
Җырларым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
Ышанасы килә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Каршы барам искән җилләргә . . . . . . . . . 14
Язмыш сынавы . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15
Йөрәк серен саклый . . . . . . . . . . . . . . . 15
Башкортстан җире . . . . . . . . . . . . . . . . 16
Дөньяда кунак кына . . . . . . . . . . . . . . . 17
Мин — хыялый кеше . . . . . . . . . . . . . . . 18
Дөнья чикләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
Илем-көнем калсын имин . . . . . . . . . . . . 19
Җирем сабыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Сораулар көтә җавабын . . . . . . . . . . . . . 21
Офык аша уза юлларым . . . . . . . . . . . . . 22
Чияләр пешкән . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
Язмыш кулындамын . . . . . . . . . . . . . . . 23
Тормыш мәйданы көтә . . . . . . . . . . . . . . 24
Сабан туе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
Бөркет юлларына тиң . . . . . . . . . . . . . . 26
Дөнья иминлеген сакларга . . . . . . . . . . . 27
Вакыт чикли . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 28

Яратып яшим . . . . . . . . . . . . . . . . 28
Заман чыныктыра . . . . . . . . . . . . . 29
Үз шөгыле . . . . . . . . . . . . . . . . . 30
Җиремә сөенәм . . . . . . . . . . . . . . 31
Урман кочагында . . . . . . . . . . . . . 32
Йокыларың калды бүленеп . . . . . . . 32
Иминлекне яклап . . . . . . . . . . . . . 33
Кешечә яшә, диләр . . . . . . . . . . . . 34
Атам йорты көтә . . . . . . . . . . . . . 35
Агачларда бөре ачыла . . . . . . . . . . 36
Үсегез, тирәкләрем . . . . . . . . . . . . 37
Хезмәт кешесе . . . . . . . . . . . . . . 38
Дусларым була терәк . . . . . . . . . . . 38
Күңелемдә — жир бизәге . . . . . . . . . 39
Заман . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 40
Урман юлы . . . . . . . . . . . . . . . . 40
Авылым чишмәсе . . . . . . . . . . . . . 41
Кулларымны канат итәм . . . . . . . . . 42
Көч табам . . . . . . . . . . . . . . . . . 43
Озак яттың авырып . . . . . . . . . . . . 44
Кояшым да, аем да бул . . . . . . . . . . 45
Мәхәббәт күбәләгем . . . . . . . . . . . . 45
Хатларымда — йөрәк җылым . . . . . . . 46
Син — язмышым . . . . . . . . . . . . . . 47
Туган җирдә мәхәббәтем . . . . . . . . . 48
Кеше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 49
Игенче . . . . . . . . . . . . . . . . . . 50
Май яме . . . . . . . . . . . . . . . . . 50
Таң ата . . . . . . . . . . . . . . . . . . 51
Юллар озая . . . . . . . . . . . . . . . . 52
Күпер салам . . . . . . . . . . . . . . . 53
Күл өстендә ак томан . . . . . . . . . . 54
Егет чакта . . . . . . . . . . . . . . . . 55
Бәйрәм сые өстәлдә . . . . . . . . . . . 55
Әкият итеп сөйләрлек . . . . . . . . . . 56
Авылым . . . . . . . . . . . . . . . . . 57
Дөнья һаман тыныч түгел . . . . . . . . 58
Үкенечле булмасын . . . . . . . . . . . . 58
Халык күңелендә син (*М. Кәрим истәлегенә*) . . . . 59
Гел бергә (*Х. Туфан истәлегенә*) . . . . . . . 60
Игеннәрнең үсмер чагы . . . . . . . . . 61
Тәрәзәңдә таң нурлары . . . . . . . . . 62
Бер карашың җитә . . . . . . . . . . . . 62
Үз кардәшем . . . . . . . . . . . . . . . 63
Таң уянды . . . . . . . . . . . . . . . . 64

Авылым кичләре . . . . . . . . . . . . . . . 65
Оныта алмассың бу якларны . . . . . . . . . 65
Ел фасылы чылбырында . . . . . . . . . . . 66
Уйлар дәрьясында . . . . . . . . . . . . . 67
Хезмәт куанычлы . . . . . . . . . . . . . . 67
Көнем уза басуларда . . . . . . . . . . . . 68
Юллар дәшә . . . . . . . . . . . . . . . . 69
Гаделсезлек җирдә булмас . . . . . . . . . 70
Табигатьнең кодрәт көче . . . . . . . . . . 70
Йокыга талам . . . . . . . . . . . . . . . 71
Төрле тарафларга юл уза . . . . . . . . . . 72
Кыш сулышы . . . . . . . . . . . . . . . . 73
Дүртьюллыклар . . . . . . . . . . . . . . 74
Кайгы көтмәгәндә килә . . . . . . . . . . 77
Тамырыбыз — тирәндә . . . . . . . . . . . 78
Дулкыннар уйный . . . . . . . . . . . . . 79
Көзге җилләр . . . . . . . . . . . . . . . 79
Торналар чыккан юлга . . . . . . . . . . . 80
Вакытым юк . . . . . . . . . . . . . . . . 81
Уйландыра төрлесен . . . . . . . . . . . . 82
Туган төяге көтә . . . . . . . . . . . . . 82
Авыл таралмы? . . . . . . . . . . . . . . 83
Яшел сукмакларым . . . . . . . . . . . . . 84
Ужымнарга карыйм . . . . . . . . . . . . . 85
Ышанам халыкка . . . . . . . . . . . . . . 85
Җирдә алыш бара . . . . . . . . . . . . . 86
Аз гына хаталансаң . . . . . . . . . . . . 87
Диңгез . . . . . . . . . . . . . . . . . . 88
Юллар эзләрсең . . . . . . . . . . . . . . 89
Кемнең мәхәббәт язы . . . . . . . . . . . 89
Көтеп яшим . . . . . . . . . . . . . . . . 90
Ай сукмагы буйлап . . . . . . . . . . . . 91
Торналар тавышы . . . . . . . . . . . . . 92
Урам матурлана . . . . . . . . . . . . . . 92
Кайда әниләрнең яшь чагы? . . . . . . . . 93
Ашыкмагыз әле . . . . . . . . . . . . . . 94
Кеше керә бәхәскә . . . . . . . . . . . . 95
Кыр казлары китә . . . . . . . . . . . . . 96
Юлларда гомер уза . . . . . . . . . . . . 97
Моң алам . . . . . . . . . . . . . . . . . 97
Карлыгачлар оя кора . . . . . . . . . . . 98
Унҗиденче язың . . . . . . . . . . . . . . 99
Кемгә ачу сакларга? . . . . . . . . . . . 100
Диңгез ярында . . . . . . . . . . . . . . 101
Сукмак буйлап киләм . . . . . . . . . . . 102

Көз сарысы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 102
Авылым яме . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 103
Югалтуларым күп булды . . . . . . . . . . 104
Су буенда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 105
Күптән сүнгән учаклар . . . . . . . . . . . 105
Таулар гына очрашмый . . . . . . . . . . . 106
Көнлисең . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 107
Шөгыль таптым . . . . . . . . . . . . . . . . . 108
Расланмады төшләре . . . . . . . . . . . . . 109
Чишмә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 110
Йөгереп уза көннәр . . . . . . . . . . . . . 111
Кызлар тавы . . . . . . . . . . . . . . . . . . 111
Вокзал тулы халык . . . . . . . . . . . . . 112
Бәхәсләшмик әле . . . . . . . . . . . . . . . 113
Авылның үз матурлыгы . . . . . . . . . . . 113
Күреп сөйләшәсе килә . . . . . . . . . . . 114
Ташу сулар ага . . . . . . . . . . . . . . . . 115
Җир-анам яңгыр көтте . . . . . . . . . . . 116
Йөрәктә саклыйм . . . . . . . . . . . . . . . 117
Күк пәрдәләрен ачты . . . . . . . . . . . . 117
Хөкемеңне сизеп киләм . . . . . . . . . . . 118
Җаным җыр теле . . . . . . . . . . . . . . . 119
Яшәү серләрен саклый . . . . . . . . . . . . 120
Кышкы урман . . . . . . . . . . . . . . . . . 120
Ялгызлыгым кисәтә . . . . . . . . . . . . . 121
Җәйләр ямьле . . . . . . . . . . . . . . . . . 122
Булдыксызга санама . . . . . . . . . . . . . 123
Давыл ачты тәрәзәмне . . . . . . . . . . . 123
Төрле чак була . . . . . . . . . . . . . . . . 124
Үткән белән арам өзелми . . . . . . . . . 125
Сөенәм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 126
Чын сөю бар . . . . . . . . . . . . . . . . . . 126
Таныш сукмакларым . . . . . . . . . . . . . 127
Әйтер сүзләрем калды . . . . . . . . . . . . 128
Гомер мизгелләре . . . . . . . . . . . . . . 129
Танып . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 129
Син йоклыйсың . . . . . . . . . . . . . . . . 130
Адаштым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 131
Гомер уза . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 132
Көйсез булды заманасы . . . . . . . . . . . 132
Шагыйрь дуска . . . . . . . . . . . . . . . . 133
Якты күл . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 134
Җилләр уйный . . . . . . . . . . . . . . . . 135
Мин үземчә яшим . . . . . . . . . . . . . . . 135
Матур чак ерак калды . . . . . . . . . . . 136

Дим ярында . . . . . . . . . . . . . . . . . . 137
Иялəнми авыл баласы . . . . . . . . . . . . . 138
Йолдызлар сəламли . . . . . . . . . . . . . . 138
Əти, киңəшеңə мохтаҗмын . . . . . . . . . . 139
Хөсетлек кылучылар . . . . . . . . . . . . . . 140
Яшəү мизгеле төш кенə . . . . . . . . . . . . 140
Йөземне җилгə борам . . . . . . . . . . . . . 141
Сер бирмəдем . . . . . . . . . . . . . . . . . 142
Тынлык белəн сөйлəшəм . . . . . . . . . . . . 143
Күп югалту күрдем . . . . . . . . . . . . . . 143
Тугры калам антыма . . . . . . . . . . . . . . 144
Яшəү көче . . . . . . . . . . . . . . . . . . 145
Казлар юлы . . . . . . . . . . . . . . . . . . 145
Җирдə яфрак тузына . . . . . . . . . . . . . . 146
Көз бизəге . . . . . . . . . . . . . . . . . . 147
Яңгыр да, кар да ява . . . . . . . . . . . . . 147
Күрми китəм аулак өйлəрне . . . . . . . . . . 148
Тəрəзəмə боз каткан . . . . . . . . . . . . . 149
Кышкы төн . . . . . . . . . . . . . . . . . . 150
Егылсам, еламадым . . . . . . . . . . . . . . 151
Жырларыңны, əни, ишетəм . . . . . . . . . . . 151
Гомернең канатлы чагы . . . . . . . . . . . . 152
Дөнья гашыйк итте . . . . . . . . . . . . . . 153
Сəфəр чыксам . . . . . . . . . . . . . . . . . 153
Күңелемнең язы, назы бар . . . . . . . . . . . 154
Чəчлəреңне җил тарады . . . . . . . . . . . . 155
Чибəр кызга күз төшермим . . . . . . . . . . . 156
Сине һаман яратам . . . . . . . . . . . . . . 156
Куллар сузам биеклеккə . . . . . . . . . . . . 157
Игелекле эшлəр кылсам . . . . . . . . . . . . 158
Килсə көчемнəн . . . . . . . . . . . . . . . . 159
Безме җирнең кендеге? . . . . . . . . . . . . 160
Бетми күңел ваклыгы . . . . . . . . . . . . . 160
Килер көннəр ничек булыр? . . . . . . . . . . 161
Битараф булып яшисең . . . . . . . . . . . . . 162
Көтмəгəндə җир шуыша . . . . . . . . . . . . . 162
Шөгылемне алмаштырмам . . . . . . . . . . . . 163
Авыл, шəһəр арасы . . . . . . . . . . . . . . 164
Максат куйган карарым . . . . . . . . . . . . 165
Карлар яуса да . . . . . . . . . . . . . . . . 165
Төрле хəллəр була . . . . . . . . . . . . . . 166
Көтеп алам . . . . . . . . . . . . . . . . . . 167
Галəм карашы . . . . . . . . . . . . . . . . . 168
Бөрелəр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 168
Кабул итəм . . . . . . . . . . . . . . . . . . 169

Җиңү көне . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 170
Җирем бәйрәм итә . . . . . . . . . . . . . . . . 171
Бәйрәм тантанасы . . . . . . . . . . . . . . . . 171
Мин көтәм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 172
Кош тоталсаң . . . . . . . . . . . . . . . . . . 173
Ант иттем, вәгъдә бирдем . . . . . . . . . . 174
Хисләр ташкыны . . . . . . . . . . . . . . . . . 175
Күл буенда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 176
Төн пәрдәсен яба . . . . . . . . . . . . . . . . 177
Хәтер капчыгымда . . . . . . . . . . . . . . . . 177
Җиде якка юл ята . . . . . . . . . . . . . . . . 178
Күргәннәрем төш кенә . . . . . . . . . . . . . 179
Казлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 180
И, туган җир . . . . . . . . . . . . . . . . . . 181
Гел кояшлы күкләре . . . . . . . . . . . . . . 181
Туган як — горурлыгым . . . . . . . . . . . . 182
Басуларда йөрим . . . . . . . . . . . . . . . . 183
Дулкыннар тынып кала . . . . . . . . . . . . . 183
Яшен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 184
Оран сала әтәчләр . . . . . . . . . . . . . . . 185
Җир җиләкләре пешкән . . . . . . . . . . . . . 185
Йолдызлар яңгыры . . . . . . . . . . . . . . . 186
«Карашың шундый мөлаем...» (*Ф.-гә*) . . . . . . 187
Хезмәт сөйдек . . . . . . . . . . . . . . . . . 187
Җырладык та биедек . . . . . . . . . . . . . . 188
«Еллар сымак озын көткән көнем...» (*В. К.-га*) . 189
Яратам икән . . . . . . . . . . . . . . . . . . 190
Сүнмәсен өмет учагым . . . . . . . . . . . . . 190
Мәхәббәтне кем дә татыган . . . . . . . . . . 191
Гармуным кулларымда . . . . . . . . . . . . . 192
Кызларның мөлаем карашы . . . . . . . . . . . 193
Таң атар мәлдә . . . . . . . . . . . . . . . . . 193
Август иртәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . 194
Гармун йөри урамнарда . . . . . . . . . . . . 195
Юлаучыга юлдаш булам . . . . . . . . . . . . 195

## *Җырлар*

Очрашырбыз әле . . . . . . . . . . . . . . . . 199
Гомерләр уза икән . . . . . . . . . . . . . . . 200
Игенче җыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . 200
Язмышлар уртак . . . . . . . . . . . . . . . . 201
Чәчкәләргә сулар сибәм . . . . . . . . . . . . 202
Җилләр дә каршы исә . . . . . . . . . . . . . . 203
Бүген туган көнең . . . . . . . . . . . . . . . 204

Яшьлегемә кайтам . . . . . . . . . . . . . . . . . 204
Төшләремә керәсең . . . . . . . . . . . . . . . . . 205
Сөеп сөеник әле . . . . . . . . . . . . . . . . . 206
Иртәләрем, кичләрем . . . . . . . . . . . . . . . 207
Зәңгәр күзләр . . . . . . . . . . . . . . . . . 207
Укытучым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 208
Яшьлек хатирәсе . . . . . . . . . . . . . . . . 209

Литературно-художественное издание

**СУФИЯРОВ Фарит Суфиярович**

**УРАГАН ЧУВСТВ**

Стихи, песни

*(на татарском языке)*

Редакция мөдире *Ринат Камалов*
Мөхәррире *Динә Морзакаева*
Рәссамы *Ләлә Гаянова*
Бизәлеш мөхәррире *Азат Мөхтәруллин*
Техник мөхәррире *Венера Абдрахманова*
Корректоры *Гөлшат Абдуллина*

Басарга кул куелды 20.03.09. Форматы 70 x $90^1/_{32}$. Офсет кәгазе. Петербург гарнитурасы. Офсет ысулы белән басылды. Шартлы басма таб. 7,90. Шартлы буяу отт. 8,5. Исәп-нәшер таб. 7,81. Тиражы 2000 данә. Заказ № 90364.

Башкортстан Республикасының Зәйнәб Биишева исемендәге Башкортстан «Китап» нәшрияты дәүләт унитар предприятиесе.
450001, Уфа, Левченко урамы, 4а.

Әзер файлдан басылды.

Башкортстан Республикасының «Белая река» нәшрияты» дәүләт унитар предприятиесе.
450078, Уфа, Киров урамы, 109.

Намусымны саклыйм тап төшерми,
Хезмәт бары яшәү терәгем.
Мин башымны горур йөретермен,
Кешеләргә булса кирәгем.